

ШӘҮКӘТ ГАДЕЛША

# Аучы җыры



## Шигырьләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84 (2Рос=Тат)—5
Г 15

**Гаделша Шәүкәт**

Г 15 Аучы җыры: Шигырьләр. — Казан: Тат.кит.нәшр., 2004.— 383 б.

Себер татары, Төмән төбәгендә туып-үскән шагыйрь Шәүкәт Гаделша бары тик үзенеке генә булган поэтик сурәтләр аша себер татарларының тормыш-көнкүрешен, Себернең гүзәл табигатен ачып бирә.

ISBN 5-298-01377-5 © Татарстан китап нәшрияты, 2004

# Җирсу

*(Ырулар рухына шигъри дога)*

Шәүкәт Гаделша дигән шагыйрьнең иҗатын беренче шигырьләреннән алып күзәтеп барам. Әлеге шагыйрь, беркемгә дә охшамаган гаять үзенчәлекле иҗаты, темалары һәм иҗат алымнарының яңалыгы белән үзенә җәлеп итте. Шигърияткә ул җиңел генә килде дип булмый, ул аңа «кайта-кайта» килде дияр идем. Чөнки, студент елларында ук үзенчәлекле шагыйрь килә дип көткәндә, кинәт, башлангыч «мирасын» төяп, үзенең Төмәненә, аның урман-күлләре, җәнлекләре дөньясына кайтып китте. Әмма бу «югалу» тикмәгә генә булмаган икән, шөкер. Шәүкәт Гаделша бу юлы әйтерсең лә Себер Иленең зәңгәр урманнарын, җәнлекләре дөньясын, могҗизалы төннәрен, нәсел-ыруының фатихасын, йолаларын, гаять бай халык иҗаты мирасын төяп кайтты! (Бу урында шагыйрь өчен «кайту»мы, «килүме» булгандыр?) шигърияткә булгач, әлбәттә, «кайту» була инде! Аның «Ярык мөгез» дигән беренче шигырьләр китабында күңелгә тирән уелып кергәне үтә дә кыен язмышка тап булган болан образы иде. Шәүкәт Гаделша, уеннан уймак дигәндәй, үзе дә сизми калып бугай, реаль күзәтүләрен гомумиләштереп, боланның классик образын тудыра алды. Анда: «Йөгерә ата болан, куакларны ярып; җанына тынгы бирми мөгездәге ярык. Җил иссә, кубыз булып суза башлый ярык, ана болан чакырган авазлар чыгарып...»

Менә шул табигый инстинкт чакыра, куа, газаплый болан бәгырькәйне! Ниһаять, ул чакыру авазын куып тоталмыйча егыла. Нинди фаҗига! Шагыйрь бу образдан гаять оста файдаланып, шигырьне көтелмәгән гомумиләштерү белән очлап куя — үзен шул болан үгезенә тиңләп: «шул үгез хәлендә бит, дуслар, мин үзем дә. Ахыры, ярык булган хыял-мөгезем дә!» — дигән тирән мәгънәле фәлсәфи нәтиҗә ясый. Шагыйрьнең мондый табышлары кайбер шигырь сөючеләрнең күзләренә чалынмый калмады, әлбәттә. Әмма мондый табышлар Шәүкәт Гаделша иҗатында ялгызак түгелләр, алар — бихисап. Моннан исә әлеге иҗатка игътибар күбрәк кирәклеге аңлашыладыр.

Соңрак дөньяга килгән «Ядрә тигән», «Сөмән кадыйм», «Җилгә моң дыңгычлыйм» дигән шигырь китапларын да укучылар күрми калмагандыр. Шигырьләренең уникальлелеге, алардан яңача сурәт, аһәң, сурәтләү чараларының байлыгы — үзе бер кабатланмас поэтик дөньяны тудыра. Әлбәттә, шигъри сурәт эчке халәттән туа. Әмма тышкы форма ул әле бары бизәк кенә. Әгәр дә без Шәүкәт Гаделша дигән шагыйрьнең иҗат хосусиятен, аның асылын аңларга-аңлатырга телибез икән, иң элек ул яшәгән мохиткә үтеп, шул җисми вә рухи дөньяны аңларга тиеш булабыз. Чөнки, һәр мохитнең, тирәлекнең үз тормышы, үз биокыры барлыгын, ә моның шагыйранә шәхес психологиясенә тирән йогынтысы зур икәнлеген исбатлап торасы юк: әйтик, сандугачның сайрый торган үз талы бар икән, ул да яраткан тирәлегендә генә сайрый. Табигатенә карап моңы үзгәрә сыман. Себер, Төмән яклары бездәгедән кырысрак, әмма мул табигатьле, аның үз куены, үз моңы... Минем табигый кыргый мохитнең күңел-хис дөньясына тәэсирен Төньяк Казагыстанның язгы ярсу болганчык Иртешенә карап уйланып утырганда тойганым-кичергәнем бар. Иртеш, Тубыл елгалары — олуг тарих үзәне! Кошлар язмышыдай татар халкының гомерлек миграциясе кайдан килә? Русиянең борынборыннан килгән колониаль сәясәтенең кыргый «җимешләре» болар. Вак милләтләрне, бу очракта татарларны таркатып, даими күчереп утыртып, аларны бер төбәккә туплап, үзенә бер «көтүлекләр» ясап, шул рәвешчә табигый «ау зоналары», «тыюлыклар»га охшаш резервацияләр булдыру аркасында килеп чыккан болар. Моннан исә патша режимы күзәтчеләренә ошбу милләткә «күз-колак» булып тору күпкә ансатлаша. Мондый резервацияләргә бары төрле миссионерлар гына кыю үтеп керә алган. Урман-күлләр-сазлыклар куенында утырган Себер татарлары җирлегендәге төрле серле-серле, мәҗүсилеккә якын атамалар, ырымнар, тотемнарга табынулар әнә шул ыруглыкка якын яшәештән барлыкка килгәндер. Татар гомер-гомердән җир асларына төшеп эшләгән, мартен ялкыннарына руда белән бергә кергән, Демидов металл заводларында, алтын приискаларында бил бөккән, Петр патша заманында лашманчы булып кораб төзелеше өчен имән урманнарын кисеп тураган, Петербургның нигезенә татарның сары сөякләре түшәлгән. Тарих кая китсенди? Шунысы да бик мөһим бу урында: шагыйрь Шәүкәт Гаделшаның атасы ягыннан бабасының сөрелгән Казан татары булуы, әнисе ягыннан бабасының исә Себер ханнары нәселеннән килеп чыгуы мәгълүм шәҗәрә әнә шундый. «Җан тартмаса да, кан тарта»,— ди халык. Шәүкәт

Гаделша моны сизеп яши, әнә шуңа да аның Себер ханы Кучум кебек, туган туфрагына аяк терәп яшәргә, горурланып сөйләшергә хакы бар! Моңа мисаллар аның иҗатында тулып ята. Аның лирик герое һәрчак юмарт холыклы, кешеләргә ярдәмчел:

Бирәм соңгы серәнкәне,
Соңгы телememне.
Күрәм кеше күңелләрен,
Тыңлап күңелемне.
Кызганмыйм да, үкенмим дә,—
Рәхәтләнеп калам.
Себер татарларын шулай
Яраткан бит Аллам.

Шагыйрь үз ягын, үз тарихын белә генә түгел, ул аны һәр күзәнәге белән сиземли, тоя. Шагыйрьнең рухи табигатен ул яшәгән табигатьтән аера алмыйсың. Шагыйрь табигатьне «өстән» яки «тышкы яктан» гына тасвирлаудан ерак, үзенең туган төбәген, халкы яшәешен, аның тарихын әледән-әле иҗтимагый-сәяси югарылыкка күтәрә, шигырьләр чынбарлыкка якынлаша, чорның чалымнары күз алдында пәйда була:

Кук томан эчендә «дөп» тә «дөп»,
Тышаулы елгырлар килә кук...
...................................................
Җилфердәп китмәсме сөңгедә
Кучумнең ак кыллы бунчагы.
Болгана каршымда кук томан.
Белмимен: артымы, алдымы?
Атларны чуктереп атланыр
Берәр ир Себердә калдымы?

Шагыйрь табигатьнең яшерен серләрен ачарга омтыла, моны ул булдыра алуына да ышана. Әмма, мәҗусилек калдырырга ярамый дигән кебегрәк нәтиҗә ясый. Шигъри мантыйгын Себернең хуҗасы — чын Себер татары дигән нәтиҗә-фикергә китереп ялгый:

Сизә күңелем, әй, сизә:
Ята монда хәзинә.
Кучумнеңме? Кайсы ханның?
Әйтә алмыйм хәзергә.

Сизсәм дә кайда ятканын,
Теләмим кагылырга.
Иректән мәхрүм хатынның
Ирексез алтыны да.

Әйе, Шәүкәт Гаделшаның иҗаты хакында, шигърияtенең хикмәтле яклары, гомумән, татар поэзиясендә Шәүкәт Гаделша феномены хакында фикерләр дә булмады түгел. Әмма аны өстән-өстән әйтеп китү бер хәл, ә менә чынлап торып әлеге иҗатны фәнни яктан өйрәнү Себер татарларының поэтик тел җәүhәрләрен өйрәнүгә дә зур өлеш кертер иде. Киләчәктә әлеге эш үз галимнәрен дә табар әле, бәлки. Эш җиңеләер: фольклор экспедицияләре белән ерак Төмән төбәкләренә дә барып чыгасы юк — халык иҗаты бизәкләрен шул ук Шәүкәт Гаделшаның иҗатыннан күпләп чүпләргә мөмкин! Чыннан да, шагыйрьнең кайсы гына шигырен алсаң да, hәрберсендә бер табыш, шигъри «орлык», фикри оеткы — шуларның hәркайсы кабатланмас халык авыз иҗаты гыйбарәләренә якын. Фәнни эзләнүләр өчен бу үзенә бер «чирәм җир» кебек әле. Шагыйрьнең hәр шигырендә кешенең рухи халәте табигать халәтенә ярашлы, тәңгәл рәвештә җанлана:

Камышка камыш ышкыла,
Җилсез-нисез ышкыла —
Әйтерсең яшеренеп яткан
Ат табуны пошкыра.

Яки менә әлеге ярашу-тәңгәллекне тагын да җетерәк раслаучы юллар:

И, Казаным!
Шатлык килде!
Аяз күгең охшый бүген
Улын имезеп ләззәтләнгән
Болан күзенә...
И, Казаным,
Кайгы килде...
Аяз күгең
охшый бүген
Чебен күреп киерелгән
Елан күзенә.

Табигать аhәңен, аның психологик сурәтен әнә шулай гаять оста, нечкә тоемлый шагыйрь.

Себернең кыргый табигатен, аның халкын сагынып җирсү — шагыйрь иҗатының төп лейтмотивы. Ул хис-тойгыны, шулардан кабынган шигъри утны шул җир-туфракның бердәнбер аборигены сыман, шигырьдән шигырьгә күчереп кабыза бара, аңа сүнәргә һич ирек бирми! Ә бу ут исә, шагыйрьнең Иҗат Чырагына әйләнеп, отыры көчәя генә бара.

Шәүкәт Гаделшаның ике рухи төбәккә — Казанга һәм Төмәнгә тартылуы бик тә табигый хаҗәт:

Кайсы якта черегән
Ыруымның казыгы?
Яшьнең иң гөнаһсызын
Кайсы якка агызыйм?
...Казан, Төмән арасы —
Мәгънәм минем, канатым...

Шагыйрь иҗатындагы тагын бер характерлы вә әһәмиятле якны: аның хис-тойгыларының импульсив булуын, әмма нәкъ әнә шул ягы белән кыйммәтле икәнлеген әйтергә кирәктер: чөнки аларда табигый информация мул. Икенче төрлерәк, образлырак итеп әйтсәк, «иләнмәгән, кисәкле алтын, самородок» кайчак мохитне, тарихилыкны ачыграк чагылдыру сәләтенә ия. (Бу очракта, әлбәттә, Себер татарларының яшәешен, ырым-йолаларын, иҗатын, тарихын ачу ягыннан.)

Шәүкәт Гаделшаның иҗаты хакында язган кайбер мәкалә авторлары аның мәҗүсиләргә хас тасвирына игътибар иттеләр. Минемчә болайрак: һәрбер шагыйрьдә азмы-күпме мәҗүсилек рухы яши. Чөнки шагыйрь Табигатькә башкаларга караганда да күбрәк бәйле. Ул аның иҗатына, яшәешкә азык бирә. Ул илаһиятне, шигъриятне турыдан-туры Ходай Бакчасы булган Табигать-Анадан ала. Аны шагыйрьнең Музасы дигәннәр. Муза, музыка, аһәң!..

Шагыйрьнең аһәңнәрен тыңлыйк:

Яшь торна оча алмый,
Тилмерә үзәндә.
Тәпие чорналган
Энәле үләнгә...
...Йөгерә ач төлке
Торнаны кабарга.
Алдарак мин чабам —
Коткарып калырга.

Яисә менә гаҗәеп тыгыз, гыйбарәгә якын халәт:

Чумышалар балыклар:
Алтын, көмеш төсләләр.
Кичә баткан бәхетне
Бик тырышып эзлиләр.

Шагыйрь табигатьне — агачларны, суларны, хәтта ташларны җанландыра, илаһилаштыра. Менә шигъриятнең үзеннән үк туган тотемнар белән эш итү ысулы килеп чыга инде. (Бу яктан чын Табигать уллары булган Америка индеецлары яшәешенә ишарә дә җиткән.)

Табигый ки, цивилизациядән никадәр ерагаеп, табигатькә шулкадәр сыенып яшәсәң, бу сыйфатларның тагын да көчәюен исбатлап та торасы юк.

Шунысы куанычлы: татар шигъриятендә өр-яңа, гаять үзенчәлекле, уникаль шагыйрь Шәүкәт Гаделша китаптан китапка үсә, ныгый, тирәннән ачыла, укучысына якыная бара. Аның тынгысыз карашы, тәвәккәл сунарчы кебек, ерак-еракка, яңа иҗат офыкларына төбәлгән. Һичшиксез, шагыйрь шул офыкларга барып җитәр, яңа биеклекләргә менәр дип ышанам. Чөнки аның мөмкинлекләре моңа ышандыра алырлык.

Укучы хөкеменә тәкъдим ителгән ошбу сайланмалар рәвешендә дөнья күргән яңа җыентыгы шагыйрьнең гомер тәҗрибәсенә, тынгысыз олы хезмәтенә нигезләнгән беренче күләмле китабы. Иҗади эзләнүләр нәтиҗәсе булып дөньяга китап тууы — Шагыйрьнең тууы кебек күркәм вакыйга, иҗат бәйрәме ул!

Шәүкәт Гаделшаның шигърияте легендалар вә дастаннар иле — Себернең җир-суына, урман-күлләренә, киек-җәнлек дөньясына, ыруглары рухына Шигъри Дога булып ишетелә! Киләчәктә мондый игелекле шигъриятнең кайтавазлары буласына да шигем юк.

*Роберт Әхмәтҗан,*
Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

# ЯРЫК МӨГЕЗ



# Урманда

Югалды барыр ноктам.
Сүнде соңгы өмет.
Качып ятам урманда,
Кайгырып, яшем түгеп.
Салкын кыш наратларны
Йомычкалый, телә.
Йөрми җәнлек, очмый кош —
Оясында үлә.

Учак ягарга куркам,
Кеше кермәсен дип.
Дөнья хәлен, ил хәлен
Сөйли күрмәсен дип.
Кайчагында тәрәзәдән
Бүре танавын суза.
— Кер әйдә, кер,— дим,— ташлан! —
Гомерем тиккә уза.

## Мөгездәге ярык

Йөгерә ата болан
Куакларны ярып:
Җанына тынгы бирми
Мөгездәге ярык.

Җил иссә,
Кубыз булып
Суза башлый ярык,
Ана болан чакырган
Авазлар чыгарып.

Ата болан түземсез,
Аңларга теләми;
Сөяркә бик якын дип,
Йөгерә эзләнеп.

Ә җилләр — үчле, исте
Бер дә туктамыйча.
Үгез егылды арып,
Куып тоталмыйча.

...Шул үгез хәлендә бит,
Дуслар, мин үзем дә.
Ахры, ярык булган
Хыял-мөгезендә.

## Йөз яшьлек аучы

Йөрәкне суытып,
Бүреләр уламый.
Каенны селкетеп,
Көртлекләр уйнамый.

Куяннар йөгерми,
Яшь талны кимерми.
Аръякта аланда
Пошилар күренми.

Чинатып тычканны,
Төлкеләр казынмый.
Җир йөзе мәгънәсез,—
Бер эз дә язылмый.

Сызгырмый, кычкырмый —
Урманы тып-тыныч.
Үлем берни түгел,
Шул тынлык — куркыныч!

Кем әйтә елауны
Оныта йөз яшьлек?
Яшь тама, эре яшь,
Ак карны чылатып.

Йөз яшькә җиткереп
Язмышы көлгән бит.
Урманы-дөньясы
Алдарак үлгән бит...

* * *

Бер урамда
Тыныч кына
Йөри идем.
Кинәт...
Балкыш!!!
Көлеп барган
Кызны күрдем.
Боз булсам мин,
Шул минутта
Эрер идем.
Һәм артыннан
Гөрли-гөрли
Йөгрер идем.
Яктырак көл,
Язгы кояш,
Күз камашсын,—
Кара күзен
Йома-йома
Кыз адашсын.
Ул, адашып,
Туган йортын
Табалмасын.
«Булышыйм»,— дисәм,
Мине кире
Кагалмасын.
И зәңгәр күк,
Чәчәк булып
Коел әле!
Юлына синнән
Койма корып
Куйыйм әле.

Нинди кыз ул —
Әллә бәхет?
Аңым җитми...
Яз җылысын,
Көн яктысын
Алып китте...

# Ике халәт

И, Казаным!
Шатлык килде!
Нинди генә рәхмәтләрем
Әйтим үзеңә!

Аяз күгең
Охшый бүген
Улын имезеп ләззәтләнгән
Болан күзенә.
И, Казаным!
Кайгы килде...
Нинди генә усал сүзләр
Әйтмим үзеңә?

Аяз күгең
Охшый бүген
Чебен күреп киерелгән
Елан күзенә.

* * *

Әти миңа
Ат бирде:
— Авылларга
Чап,— диде,—

Матур кызны
Тап,— диде,—
Өйгә алып
Кайт,— диде...

Яхшы иде
Ул атым.
Җил, давыллар
Уйнаттым.

Авыл саен
Мин чаптым.
Чыбыркыны
Шартлаттым:

Ком-тузанны
Кузгаттым,
Эт-мазарны
Таптаттым.

Күп матурны
Мин таптым,
Ләкин бар да
Баш тартты.

Хәлдән тайды
Шук атым.
Җәяү генә
Мин кайттым.

Кызганды да
Баласын,
Әти бирде
Балтасын:

— Менә хәзер
Атла син,
Өйләнмичә
Кайтма син.

Җиңел иде
Ул балта,
Иple иде
Ул балта.

Авыл саен
Мин киттем.
Өй салышып
Тир түктем.

Күпләр: «Кияү
Бул!» — диләр,
Үз кызларын
Димлиләр.

Сылу кызлар
Күз кыса,
Җае чыкса,
Сүз куша.

Ә мин үбәм,
Шатланып.
Әтиемнең
Балтасын.

Ә хатынны? —
Кайткачтын.
...Тыныч кына
Атласын...

## Яшь карчыга

Тузгып оча бүген яфраклар —
Сары, алсу, яшел түшлеләр.
Агачка кунган карчыганың
Ачы кычкыруы ишетелә.

Тыпырчына табыш тырнакта,—
Кош дип күпме яфрак аулаган!
Ярсып чукый түшен карчыга —
Алданганын, ахры, аңлаган.

Күрдем дә мин яшь бичараны,
Канатканчы ирен тешләдем.
Хәтерем кычкыргандай булды:

— Ничек яшим?
Ничек яшәдем?

# Сазлык

Мулла бабам куылганда
Алтынын күмгән, имеш.
Чалдон бабам ачтан үлгән,
Камыш чәйнәгән килеш.

Болай да суык көз көнен
Суыта алтын төсе.
Кабыргама охшый камыш,—
Сөяк шакылдый төсле.

Сәер тынлык, упкын булып,
Мине суырыр кебек.
Әллә нинди олы җаннар
Сикереп торыр кебек,

Елар алар үкерешеп,
Акылдан яздырганчы.
Мине ямлап талашырлар,
Йөрәгем ярылганчы.

Мондый сазлар бераү микән,
Күп микән? Кемнәр белә?
Бәхет басармы халыкны
Шундый сазлыклы илдә?

* * *

Күзнең киеренке минутлары,
Тузгып ага кызу болытлары.
Йөгереп китәр идем артларыннан
Аермыйча агын карасыннан.
Агалар шул, агачларга сыенып,
Нидер урлап качкан карак сыман.
Оча кошлар, берсен-берсе узып,
Җилгә канатларын каты сугып.
Йөгереп китәр идем, аермыйча
Җырчы кошын ала каргасыннан;
Каурый тузгып кала, ашыгалар
Коты очып качкан качак сыман.
Йөгереп кенә китәр идем лә мин,
Кузгалырга нидер җитеп бетми;
Әллә Казан тәмам тоткын итте,
Әллә Себерем онытты инде?

* * *

Орынды да яфрак миңа
Төште кызның беләгенә.
Танышыйк дим, каршы килмик
Алтын яфрак теләгенә.

Ә кыз китте, карамады,
Җил тузынып яфрак коя.
Тал очында уйный йодрык —
Кош калдырган кара оя.

* * *

Авыру чебеш күк боегып,
Тәрәзәмдә ай ята.
Мин һаман ялгыз башым,—
Төне буе уйлата.
Саташамын,
Уйларымда
Кеше төсе калмады;
Шыксыз дала, караңгы күл
Күз алдымны камады.
Кар астыннан капкын булып,
Үз-үземә күренәм.
Җәнлек басса ябылмый ул,—
Тимерләре күгәргән.
Йә, югалган ятьмә булып,
Тонык күлдә болганам.
Эләккән балык ычкына,—
Җепләр черек, чуалган.
Кая барыйм, ниләр булыйм,—
Онытылган, ташланган.
Аерылганны аю түгел,
Авыр уйлар ашаган.

r

* * *

Ике ярдан
Икәү барабыз,
Төнбоеклы
Тын күл —
Арабыз.
Синең якта
Йөзә аккошлар,
Яфракларда
Көмеш балкышлар,
Сиңа кагынып
Уйный яшь болан;
Шатлык белән
Тулган бар җиһан.
Аһ, йөрәгем!
Ничек ярсына!
Чыгар идем
Йөзеп каршыңа;
Төнбоеклар
Сынар, егылыр,
Син сыйпаган
Болан юк булыр...
Яфракларда
Сүнәр балкышлар,
Каңгылдашып
Качар аккошлар;
Бер пышылдау —
Безнең арабыз.
Тик карашып
Кына барабыз,
Дулкын күлдә
Кайчан күренер?
Кайсы ярдан
Башлап йөгерер?

* * *

Әй, язмышым, кызып килә торгач,
Нинди серле төнгә килеп чыктык!
Аягымда — былтыр кигән чаңгы,
Кулларымда — былтыр тоткан мылтык.

Маңгаема былтыр чыккан тирләр
Яңа елның карларына тама.
Былтыр арган аякларым, тәнем
Йокы сорап кайнар утта яна.

Бик тә йоклар идем, иреннәргә
Орынганчы язның җылы бите,—
Былтыр куып килгән җәнлеккәем,
Яңа елга кереп, качып китте!..

## *Җиде торна*

Кара әле ерак кырга —
Йөри анда җиде торна.

Вакыт җитсә, оя корып,
Яңа буын чыгарырга;
Кайсы очар сагыш коеп,
Көне-төне кырдан кырга?

Бәхетлеләр, саз тетрәтеп,
Яшь торналар очыртканда,
Кайсы торна түшен чукыр,
Канат кыйнар чытырманда?

Әнә алар сагайдылар...
Йә, әйт, кайсы ялгыз торна?
...Җавап тапканга кадәрле:
«Аерыл»,— дип ашыктырма.

* * *

Ботаксыз наратны
Бик дәртләнеп
Чукый тукран.
Ә мин сөйгәнемне
Җырлар җырлап
Көтеп утырам.

Икенче агачны
Бик тырышып
Чукый тукран.
Ә мин сөйгәнемне
Бик сагаеп
Көтеп утырам.

Өченче агачны
Тыз-быз килеп
Чукый тукран,
Ә мин сөйгәнемне
Кайгы йотып
Көтеп утырам.

Нигә соң килми ул,
Нигә һаман
Ялгыз утырам?
Агачларны түгел,
Йөрәгемне
Чукый тукран.

# Болан күзе

Күл буенда уйный
Сабый болан.
Аның күзләренә
Дөнья тулган.

Ап-ак болыт,
Кояш,
Яшел үлән,
Чишмә,
Чык сафлыгы иңгән.

Кинәт мылтык шартлый,
Яңгырый урман!
Кан чәчрәтеп ава
Сабый болан.

Урман итәгендә
Ана болан.
Аның күзләренә
Ниләр тулган?

Күрә алсагыз әгәр:
Кайгы, яшь юк,—
Дөньябызны йотарлык бушлык!

## Март төне

Карга чумып йоклый авыл,
Күктә чәчрәп ай яна.
Сузып-сузып ыңгыраша
Аргы очта яшь тана.

Боргаланып, тыңлап ята
Яшь җилкенчәк, картлары.
Дер селкенә
үгезе булган
Хуҗаларның абзары.

Түбәләрдә дәртле тетрәү,—
Мәче туе тәгәри.
Усал карчык таяк тотып
Йөгерә өе тирәли.

Тәрәзәгә маңгай терәп,
Күрше бабай сөйләнә:
— Карчык акылыннан язган —
Язга каршы селтәнә...

# Аучы зары

Авылның бер бозавын аю ботарлаган иде. Аюны атарга мәҗбүр ителгән күршемнең зарын һаман оныта алмыйм.

Аргы очта инешнең
Суын син эчтең.
Бирге очта инешнең
Суын мин эчтем.

Ул ягында урманның
Син уйный идең.
Бу ягында урманның
Мин уйный идем.

Үстек без — туган якның
Ике баласы.
Икебезгә бер кояш —
Яшәү Алласы.

Туган якны сөйдек без,
Ерак китмәдек.
Син миңа, ә мин сиңа
Бер дә тимәдек.

Сыкрап тора күңелем,
Белсәң иде син.
Сине эзлим мин бүген,
Белсәң иде син.

Иңенә мылтык асты
Авыл картлары.
«Син — сунарчы, мәргән»,— дип
Мине мактады.

Кач миннән, кач, зинһар,
Кач син, якташым,
Мин белмәгән якларга.
Тапмый адашыйм.

Кызарган бит офыклар,—
Әллә каныңмы?
Ыңгырашып куя таң,—
Әллә җаныңмы?

Миннән ерак син качсаң,
Аталмыйча мин кайтсам,
Халык аңлармы?

Табарга иде сиңа,
Егарга иде сиңа
Минем тананы,
Минем тананы...

* * *

— И Вәлиш, Вәлиш,
Сине көтәм,
Карлар көрим,
Чыгып иртән.

— И Камиләкәй,
Синсез туңам.
Тышка кара,—
Кыш бит, буран!..

Чыккан идем,
Барыйм, диеп:
Чаңгым сынды,
Төпкә тиеп.

— И Вәлиш, Вәлиш,
Сине көтәм.
Чәчәкләргә
Керфек төртәм.

— И Камиләкәй,
Сагыш ашыйм...
Тышка кара:
Яз бит — ташкын.

Чыккан идем,
Сине сагынып;
Көймәм батты,
Ташка сугылып...

— И Вәлиш, Вәлиш,
Сине көтәм;
Тәрәзәләрне
Кат-кат сөртәм.

— И Камиләкәй,
Синсез авыр.
Тышка кара,—
Җәй бит — яңгыр!..

Кочмак идем
Кабат-кабат,
Пычракта
Текәнде* ат.

— И Вәлиш, Вәлиш,
Нидер сизәм,
Куркам төннән,
Куркам көннән.
Куркам сүздән,
Куркам күздән.
Көтәм, көтәм,
Һаман көтәм.
Көтүемнән
Куркып көтәм...

* *Текәнде* — сөртенде.

* * *

Авылдашларым җылым тарта,
Күл буена җыйналып.
Кулларымны тыгып кесәгә,
Читтә торам, оялып...

Урам уртасыннан каршыма
Килә авыл картлары.
Кулларымны тыгып кесәгә,
Тар тыкрыкка атладым...

Зәңгәр күзле сабый чирәмдә.
Эх! Башын сыйпап үтәргә!
Кулларымны тыгып кесәгә,
Сөялдем мин киртәгә...

Нишләргә? Куллар шома, хәлсез,
Үлгән чабак төсендә.
Шундый куллар белән кайтканны
Монда халык чит итә.

* * *

Болан баскан эзләргә
Су җыела башлады.
Чаңгыларын сунарчы
Чормасына ташлады.

Кара карга күкрәге
Күзге булып ялтырый.
Аю яткан җиреннән
Кул чыгарып кар тырный.

Як-ягына каранып,
Егет коча көймәсен.
Кабат-кабат коча ул,—
Кызы гына сизмәсен.

* * *

Улы карт анасына хат язды:
«Әгәр көннәр артык кызу булса,
Кара көйсә, шиңсә һәр ягың,—
Җыяр идем, әни, синең өчен
Аккошларын бөтен дөньяның.

Очар иде алар баш очында,
Тезелешеп, салмак тирбәлеп.
Кочар иде сине, назлар иде
Ак канатның йомшак җилләре.

Әгәр көннәр артык салкын торса,
Төбе катса тирән Тоболның,—
Җыяр идем, әни, синең өчен
Төлкеләрен туган ягымның.

Туннарыннан иркен чатыр ясап,
Яшерер идем сине җилләрдән.
Шул җылыга, әни, җырчы кошлар
Килер иде ерак илләрдән...»

Ялгыз ана кыска җавап язды,
Күз яшенә хатын чылатып:
«Ишектәге тотка төште, улым,
Каксаң иде шуны бер кайтып...»

* * *

Ерактагы болынга мин
Барган идем кунарга,
Китерим дип саф чәчәкләр,
Син йокыдан торуга.

Әллә язмыш безнең белән
Алдашырга уйлады.
Төне буе күктә яшен
Чуртан булып уйнады.

Ә иртәсен җырчы кошлар
Зарыктырып көттерде.
Мин җыясы чәчәкләрдән
Яшен исе бөркелде.

* * *

Кинәт кенә купты давыл,
Һәм котырды бик хәтәр!
— Кара,— диден,— каен сынар,
Оя тузар, тәгәрәр.

Очты печән богыллары,
Аударылды киртәләр.
— Түзмәс,— диде,— каен сынар,
Оя тузар, тәгәрәр.

Очып китте бар яфрагы,
Сынып бетте ботагы.
Түзде каен, сынмады да,
Ояны да тоталды.

Пышылдадың каушый-каушый,
Күкрәгемә орынып:
— Каен — безнең мәхәббәт бит,
Аны мәңге онытмыйк!

Ә мин, сиңа ышанмыйча,
Тордым моңсу уйланып:
«Нинди көчле мәхәббәт
Корган икән ояны?»

## Язның бер көне

Кояш әле бик түбәндә —
Кашы гына күренә:
Әйтерсең лә, алабуга
Поскан камыш төбенә.

Куркып җилдән, калтыранып
Тынак төтен сузыла.
Дулкын ярга, чуртан булып,
Сирәк-мирәк сугыла.

Бер яшүсмер ишкәк ясый
Шәрә куак артында.
Йомычкалар чабак булып
Тыпырчына, атыла.

Яр буенда балыкчы карт,
Килә нидер әйтәсе.
Кылчыкланган керфекләрдән
Тама балык тәңкәсе.

Була язның шундый көне
Туган якта — Себердә,—
Бер балыгың мең була да
Йөзә башлый туң җирдә.

* * *

Пышылдый Себердә
Бүрән күл камышы:
— Ашыктың, ашыктың...

Пышылдый Казанда
Кабан күл камышы:
— Ялгыштың, ялгыштың...

Ишетәм төннәрен,
Бергә кушам да
Бу ике тавышны:

— Ашыктың, ялгыштың,
Уйный качышлы
Язмышың, язмышың...

* * *

Элек тә бит, самолетлар очса,
Урман торды калтырап.
Әллә туңамы ул, куркамы дип,
Карый идем аптырап.

Реактивлар үкереп керсә хәзер
Туган ягым күгенә,
Урманнарым
жанын биреп яткан
Сугым кебек тибенә...

## Язгы көндә

Тышка чыгып баскан бозау.
Ләззәтләнеп койрык ата.
Сөттәй куе җылы нурга
Юеш борнын кытыклата.

Йөрсәң әгәр хыялланып,
Карамыйча артка-алга,—
Йөгереп килеп ата казлар
Тамгаларын ботка сала.

# *Тундра кызы җыры*

Ак тун кигән кыз ак нартада.
Хорей* болытларга орына.
Чапкан боланнарга дәрт өстәп,
Ненец кызы суза җырын да:
— Эһе-һей-һей!

Бушлыктан соң үрләр артында
Тук боланнар күкне сөзәдер.
Үрләрдән соң бушлык артында
Яшь боланчы мине көтәдер.

Алалмыйдыр күзен офыктан,
Керфегенә кырау кунгандыр.
Кар астында яткан чиядәй,
Иреннәре аның туңгандыр.
— Эһе-һей-һей.

Очыйк-очыйк, боланнарым, һей!
Тетрәсен, күкрәсен тундрам.
Узып китик салкын кояшны,
Сөйгәнемә кояш — мин булам.

---

* *Хорей* — болан куа торган озын таяк.

* * *

Мин үстердем бер үрдәк,
Син үстердең бер үрдәк.

Җилпенде лә үрдәгем,
Очып китте бер күлгә.
Ә синеке уйлана,
Шик туадыр күңлендә.

Зур чуртанлы күлләр бар,
Ятьмә токкан күлләр бар,
Черек сулы күлләр бар,
Мылтык аткан күлләр бар.

Йөзә минем үрдәгем
Төнбоеклы тын күлдә.
Ә синеке әрәм була,—
Кысанлыкта тилмерә.

Ә аларның бергәләп
Уйнаулары бик мөмкин.
Хәтта оя корырга
Уйлаулары бик мөмкин.
...Барыйк әле без бергә
Күл буенда йөрергә.

* * *

Мин сине сөям, дип
Төнбоеклар тездем
Тонык күл йөзенә.
Ак күбәләк кунды
Ак чәчәкләр белән
Язылган сүземә.

Яратмаган булып,
Карамаган булып.
Өзмә үзәгемне;
Ишеттерә алмадым...
Укы — учак булып
Янган сүзләремне.

Дөрес, җилләр иссә,
Зәңгәр күл өстендә
Дулкыннар йөгерер.
Кара күзең синең,
Сүзләремне түгел,
Ак күбекләр күрер.

Начарга юрама,
Карашларың миңа
Ышанган сыман.
Курыкма! Ул сүзләр
Йөрәккә кан белән
Көйдереп язылган.

## Көзге төндә

Очулары — качу түгел,
Эзләнеп тә чыкмаган.
Барасы юл язмыш белән
Яратылган, сыналган.

Бер генәдер шатлыклары —
Күктән күккә сугылу.
Кайгылары да бер генә —
Канат арып егылу.

Соңармыйча оча көтү,
Пыр туздырмый мамыгын;
Кошларныкын түгел,
Кеше
Сагышларын ташый бит...

Авырттырып миләремне,
Күкне кыйный каңгылдау.
Озынрак булса төннәр,
Язар идем акылдан...

## Күп сөйләнсәң

Бар, ахры, шушы күлнең
Серле, тирән урыннары.
Бик дәһшәтле күтәрелеп
Ярга ава дулкыннары.

Яшел төндәй тора камыш,
Күптер балык, үрдәге дә.
Мин куанып шалаш кордым
Җәй көннәрен үткәрергә.

Әмма күрәм, җилләр тынгач,
Күлем бик сай төпле икән.
Уртасына йөгереп кереп,
Карга бөҗәк чүпли икән.

Очратсаммы хәзер инде
Күп сөйләнеп мактанганны,
Сагаямын: искә төшә
Күл буенда алданганым.

* * *

Сердәшләр булганга,
Мин йөрим урманда.
Кычкырам бар көчкә
Сулга да, уңга да.
Яшьлегем, син нинди?
Төсләрең күренми,
Яшьлегем, син кайда,—
Яшердеме тайга?

Агачтан-агачка
Сикерә бер тиен.
Белмәссең, шул тиен —
Яшьлегемдер минем.

Каенда бер кошчык
Сайрый да, бии дә.
Ак зифа каенның
Башкае иелә.
Ник җырлый, ник бии?
Көтәме үз тиңен?
Белмәссең, шул кошчык —
Яшьлегемдер минем...

Тырышып-тырышып
Йөгерә кырмыска.
Оясы еракта,
Аягы бик кыска.
Төртә, йөгертә,
Үзенең зур йөген
Белмәссең, кырмыска —
Яшьлегемдер минем.

Чайкала үләндә
Шат чыклар диңгезе.
Һәр чыкның күзендә
Күрәм мин күк йөзен.
Юк итте диңгезне
Итәге шук җилнең.
Әллә соң шул чыклар —
Яшьлегемме минем?

# *Күз буяу*

Горур-салмак оча бөркет,
Тынып калды үзәнлек.
Җирнең ярык-ерыгына
Кереп качты вак җәнлек.

Хуҗаларча әйләнә ул,
Ник талпынсын аз гына!
Әйтерсең лә зәңгәрлектә
Бөек фикер языла.

Үзен мескен тойган кеше
Соклана да «аһ» ора.
— Их шул бөркет кебек очып
Күктән җиргә багарга!..

Туктагыз, дим, сокланмагыз,
Тырнаклары юк аның!
Куып җитсә — тота алмый,
Очып менсә — куна алмый...

Тырнаклары сынды эләгеп
Капкындагы хәйләгә.
Зәңгәр күктә бөркет түгел —
Гадәт кенә әйләнә.

# Балык шулпасы

Күл буенда учак яна
Кыл-казанны тирбәтеп.
Авылдашлар кыстый мине,
Әйдә берне җибәр, дип.

Эчкән идем бер тустыган,—
Яктырды күз алларым!
Күз кысалар чәчәкләре
Аргы як аланнарның.

Туймадым мин, тагын эчтем,—
Тәнемә йөгерде дәрт.
Йолкып ташлый күрмәсен дип,
Нарат тора дерелдәп.

Өченчене эчкән идем,
Хисләрем чиктән аша.
Җырлап җибәрер бу, дип,
Якташлар пышылдаша.

Исердем бит! Миңа рәхәт!
Оҗмахка кердем кебек.
Бәдәннәре дерелдәгән
Карт идем — булдым егет.

* * *

Җилгә элгән ятьмәләрем
Кипмәс инде бүген дә.
Аксак яңгыр елый-елый
Бии көймә төбендә.

Күпкә китте, кирәк түгел,—
Нинди яңгыр яумасын!
Кош очалмый — канатлары
Чүпрәк кебек манма су.

Чери чәчәк, чери тамыр —
«Өмет күзе чыланды».
Авырый этләр, танауларда
Сүнде кыргый усаллык.

Тук башаклар, кочаклашып,
Түшәлде батккак җиргә.
Чишмәдә чүп, күбек кенә —
Чирканасың эчәргә.

Югыйсә бит бик зарыгып
Көткән идем яңгырны.
Сабак алдым: юмартларга
Хәзер куркып карыймын.

# Хәтер

Пычрак итекләр таптап үтте,
Кошлар агачтан тизәк түкте,
Этләр күтәрде арт аягын,
Кеше дә чүмәште кайчагын.

Сеңде кан, тагын ачы исләр,
Үләксәләрдән сасы исләр.
Барсын сеңдереп үсте үлән,
Һәм чабылды да булды печән.

Кеше канәгать — сәнәк тыга,
Хуш ис, җәй исе гөрләп чыга.
Ә калган исләр кая киткән?
Печән — нәкъ минем хәтер икән...

# Аучы җыры

Мәче кебек
Мырлый урман,
Чаңгыларда
Басып торам.
Мылтык иңгә
Җылы бирә.
Җил көпшәгә
Моңын өрә.

Белдегезме:
Мин — сунарчы,
Сусар атам
Көн узганчы.
Алда бәйрәм
Көтә мине —
Сөйгәнемнең
Туган көне.

Ниятемне
Әйттем иртән.
Көмеш бүрек
Бүләк итәм.
Атмый кайтсам
Әгәр бүген,
Чынлап сөйми,
Йә син, йә мин.
Шикләнмәскә
Кирәк, дидем;
Миндәй мәргән
Сирәк, дидем.
Кар очкыны

Чага күзне;
Күрү кыен
Кирәк эзне;
Сусарым да
Ерак киткән;
Кайсы төпкә
Туктар икән?

Бүген аны
Табалмасам,
Күзгә төбәп
Аталмасам,
Әй, сөйгәнем,
Җаным-иркәм,
Янына мин
Якын килмәм.

Көн яктысын
Каплый болыт,
Ишелә күк
Ак кар булып.
Ак кар күмәр
Сусар эзен;
Адаштырмын
Бәлки үзем.
Нигә бу көн
Киреләнә?
Сөюемне
Белми мәллә?
Әллә иркәм
Сөйми микән,
Минем кебек
Көйми микән?

Менә төн дә
Килеп җитәр.
Көн яктысы
Карга сеңәр.
Тәнем манма
Тиргә батты.
Чаңгыларга
Бозлар катты.
Сусар эзе
Ерак киткән.
Кайсы төптә
Туктар икән?
Ялга чүксәм,
Тора алмам.
Җәзамы бу —
Булмый аңлап.
Әллә кыз да
Минем кебек
Сөя микән
Янып-көеп?
Булыйм, диеп,
Кыйбатрак,
Кача микән
Сусар ерак?
Әллә җәнлек
Сыный инде,
Кызны ничек
Сөюемне...

Бара торгач
Эз югалды.
Иптәш булып

Тик төн калды.
Мин төрлечә
Төнне сүктем.
Үкси-үкси
Әйттем сүзем:
«Нигә мине
Харап иттең?
Сусарыңны
Карак иттең?»
Бәхетемне
Урлап качты.
Күз яшьләрем
Кайнар, ачы.
Бүре кебек
Улап карыйм.
Мылтык атып,
Елап карыйм.
Коелмый төн!
«Сусар, сусар!» —
Елый чаңгы,
Сызлана кар.
Язар идем
Акылдан мин;
Күрәм йолдыз
Атылганын.

Төшкән чакта
Балкып алды,
Нигә миңа
Кадалмады?
Үтергәнче
Кадалмады...

Хәлләремне
Аңламады...
Авылга ул
Сугылгандыр,
Тәрәзәләрдә
Сызылгандыр.
Җан сөйгәнем
Курыккандыр,
Уе минем
Турындадыр.
— Әйдә шуыйк,
Чаңгыларым,
Өйгә кайтыйк
Таң туганчы.
Ә сусарны
Бүтән кумыйк.
Сөйгәнемнән
Бүләк булып
Калсын әйдә
Туар таңга,
Булсын бүләк
Карурманга.

Сусар да пар
Тапкандыр ла;
Шуңа оста
Качкандыр ла.
И сусаркай,
Өметтәшем,
Шаһитлеккә
Сине дәшәм.

Озатып бар
Син алдымнан.
Сиңа бер дә
Мин кагылмам.

Чаңгыларым
Пышлашалар;
Сусар белән
Хушлашалар.

Белдегезме:
Сунарчы мин.
Төн узып көн
Туганчы, дим...

# *Таңын ауда азан ишеттем*

Төнен берни булмагандай
Җайлап кына кызара таң.
Кайсы авылдандыр? Ага
Җылы бөркеп моңлы азан.

Нинди тылсым алыштырды
Тирә-юньнең манзарасын?
Чыршы тора, әйтерсең лә
Яңа мәчет манарасы.

Серле эңгерлеккә чумган
Куакларны, ботакларны
Коръәндәге хәрефләргә,
Сүрәләргә охшатамын.

Укырга дип көчәндерәм
Күзләремне, миләремне.
Оныткамын тумышымнан
Надан, динсез икәнемне.

Айкый азан күңелемнең
Булган бөтен тирәнлеген.
Җиргә сугып ватмак булып,
Мылтыгымны кизәндем мин.

Тонык кына яңгырый азан:
«Яңа заман, яңа заман!»
Ә мин, бүре баласыдай,
Караңгылыкка карыйм һаман.

* * *

— Офыктагы әтәч
Кикригенә кара.
— Кикрик түгел лә ул.
Кояш баеп бара...
— Үлән арасында
Кемдер чалгы кайрый.
— Хәзер кем кайрасын? —
Чикерткәләр сайрый.
— Үләндә уылдык,—
Баканыкы микән?
— Һава алыша бит,
Томаннан чык төшкән...

Көндез уйнап арган
Ике сабый бала,
Киртәгә утырып,
Таңны каршы ала.
Берсе матурлыктан
Матурлыклар таба.
Берсе уйлана да
Шундук кире кага.
Берсе канатланып
Очып китәр сыман,
Икенчесе җиргә —
Киртәгә сыенган.
Сабыйдай көнләшеп,
Качып тыңлап торам.
Күңелемдә кайный
Татлы еламсырау.
Сабыйлар утырган
Кычытканлы киртә
Дөньямны бөп-бөтен
Түп-түгәрәк итә.

* * *

Яфрак бүген коела да коела.
Вакыт бер дә үтмәс кебек тоела.
Өстә күп әле, бик күп яшелләре,
Шатлыгымны шулары яшергәнме?

Зинһар, кошчык, бу урманны читләп үт.
Яфрак катыш ява бүген чикләвек.
Канатларың очмас булып имгәнер,
Кыштан качар өчен алар кирәгер.

Кыш якын да, куанучы күренми.
Песнәк сызгыруыннан урман дерелди.
Күзли карт саескан, кунып иң очка,
Кайгы-мазар чакырырга ул оста.

Йә яфраклар коела да коела,
Әйләнде көн тоташ сагыш туена.
Кара болытларга күңел тартыла,
Елый-елый тырнап, ертып атарга.

Ә яфраклар коела да коела,
Вакыт бер дә үтмәс кебек тоела.
Җанга тынлык юк кына бит, юк кына,
Әллә гомер яфракларым йолкына?..

* * *

Язмышымның дәрьясы —
Казан, Төмән арасы.
Иңнәргә очкан кошның
Канаты мең арасы.

Кайсы сазлык суырган
Сукмагын бабамнарның?
Каенда — сөяк төсе
Күмелеп калганнарның.

Кайсы ягына карап
Минем бабам елаган?
Көнбатыш та, көнчыгыш,
Башка яклар булмаган.

Кыпчакмы мин? Монголмы?
Каһәр суккан татармы?
Кайсы якка кайтам да,
Кайсы якка барамын?

Кайсы якта черегән
Ыруымның казыгы?
Яшьнең иң гөнаһсызын
Кайсы якка агызыйм?

Казан, Төмән арасы —
Мәгънәм минем, канатым.
Эх, үлеп булса икән,
Бар буена капланып...

* * *

Минем караш, кеше булсаң,
Һәрчак ягымлы.
Икейөзсез, яшермәс ул
Усал чагымны.
Булгалыйдыр артык уйчан,
Артык акыллы.
Сабыйланып ала, карый
Яшьләр аркылы.
Балкыса да ул төрлечә,
Сүнмәс бер нуры —
Сөңге кебек үткер, туры
Татар горурлыгы.
Икәү калсак караш белән,
Бик борчылабыз.
Халкым карашыннан элгән
Нәзек бер чыра без.
Сүнәрбезме, сынарбызмы? —
Җавап улымда.
Нинди караш юлдаш булыр
Чыгар юлында?
Үсмәгән әле хыялы
Юлга дәшәрлек.
...Карашымны күзли улым,
Миннән яшереп.

* * *

Урман шәрә, җил туңдыра,
Көттерә кары.
Куянның тун алыштырып
Алданган чагы.
Туң чокырда йомарланып
Калтырый мескен.
Аучы өскә килмәсен дә
Тизрәк көн үтсен.
Сызлый башы, колак, койрык,
Кысып ятудан.
Кузгатсалар, кая качар
Төбәп атудан.
Сукаланган кап-кара кыр
Кая карама.
Аксыл төсләр чакрымнардан
Күзгә кадала.
Йөгергән куянны күрер
Берничә авыл.
Аучы җене кагылганнар
Чорнатып алыр.
Нигә быел ак карлары
Озак көттерә?
Шәрәлектән башкаема
Төрле шом керә.
Үзем ак ниятләр булып
Шартларга торам.
Заман гына кара төстә,—
Шуңардан куркам.
Мин кемең дип, халкым, нигә
Уйланып торам;
Ашыгып тун алыштырган
Куяның булам.

* * *

Тук ялкаулык яшелләнеп
Йоклый инештә.
Ак болыттан битарафлык
Җиргә ишелә.
Су өстендә төтенләнә
Черки-кигәвен.
Ялтырашып балыклары
Чуммый нигәдер.
Салынган эт теле, гүя
Учак кылтырый.
Берәү дә ярга яныма
Килми, утырмый.
Тузанга баткан бал кортын
Алам бармакка.
Юк үчлеге, усаллыгы
Энә кадарга.
Салкын битарафлык аңкый
Эссе тынлыктан.
Ятимлек хисе күңелне
Били, хет сыкта!..
Яшьле керфегемә кунды
Хәлсез күбәләк.
Әйтерсең лә, үзем түгел,—
Кайткан күләгәм.

* * *

Көчәнеше өметнең
Соңгы чигенә җитте.
Таянып күкрәгемә,
Мылтык тынлыкка типте.

Сикерде җиргә төтен,
Очты ядрә сызгырып;
Кичнең нурларын, җилен
Йолкып, өзеп, сындырып.

Ашыккан үрдәкләрне
Чөйде көтелмәгәнлек.
Канатын җәйгән килеш
Берсе төште мәтәлеп.

Каурыйлар — ак фейерверк —
Күктә тузгып калдылар.
Ниһаять, канәгатьлек
Тыпырчына алдымда.

Зәңгәр дары төтене
Тели күк назланырга.
Песи баласы кебек
Аягыма сарыла.

Камышларны селкетеп,
Нәни тәннән җан чыга.
Ник тартыша? Китмәскә?
Әллә тизрәк качарга?

Җан түгел — бәргәләнә
Бер мизгеллек шатлыгым.
Шул мизгелләр өчен дә
Җанымны мин саклыймын.

* * *

Бик зур шәһәр, төн уртасы.
Күктә ярым ай.
Бөрешкән хәер сораучы,
Хәлсез сабыйдай.

Тойгыларым зиһенемә
Никтер үч итә:
Миллион кешелек шәһәр
Охшый чүплеккә.

Үле тынлык. Кар ыңгыраша.
Шундый куркыныч!
Түзмичә киеренкелеккә,
Ачы кычкырдым.

Йөгереп килде тавышка
Кап-кара дәү эт.
Уларга кереште мәхлук
Миңа төбәлеп.

Бик якын, күңелгә якын
Этнең улавы.
Кыргыйларча моңланумы,
Әллә елаумы?

Ерак китеп яңгырый ул,
Сагаеп калам;
Ай артында елый ахры
Борынгы бабам.

Шуңадыр ла акылыма
Тойгым үч итә.
Миллион кешелек шәһәр
Охшый чүплеккә.

* * *

Сорап куйгалый иде,
Керсәк без — малай-шалай.
Туксаны узып барган
Астыртын Исмәкъ бабай.
— Корчаңгы кош очканда
Каурый коеламы?..
— Черек нарат ауганда
Ботагы егыламы?..
Җавап көтмичә, сыйпап
Капкадан сөя иде.
— Сезнең үз туксаныгыз
Туксан бит,— дия иде.
Аңламый идем аны,
Хәзер дә — кырык тулып...
Озак яшәрме мәрхүм,
Әйтәсе фикер булып.
Үземчә картаям мин,
Үземчә фикер йөртәм.
Малай-шалайлар килсә,
Шар ачып өйгә кертәм...
— Йөз яшәрлек каенның
Яфрагына йөз яшьме?
— Малайныңмы, картныңмы
Керсезрәк күз яше?
Җаваплары кирәкми,—
Соравымнан тәм табам.
Малайларның уйланып
Торуына шатланам.
Аркаларыннан сөеп,
Өйләренә озатам.
Һәм мәрхүм Исмәкъ картка
Җавап эзләп баш ватам...

# Карурманда

Мүкләнгән тынлык.
Бүрткән яшеллек.
Пәрәвез җебе —
Аркан ишәрлек.

Кое диимме,
Әллә — яшел төн?
Борынгы урман
Мине яшерде.

Кояш нурлары
Төшә тамчылап.
Ешлыкка эләгеп,
Җилләр талчыга.

Башта уйның юк
Хәтта шәүләсе.
Гүя мин — черек
Агач кәүсәсе.

Кайда син, кайда,
Хәятым җене?
Килгән идем бит
Күрим дип сине.

Әллә качтың син
Куркып заманнан.
Ахры, сине дә
Заман алдаган.

Сиңа да йөзен
Кырыс тотамы?
Йоныңны йолкып,
Кыерсытамы?

И шук, нарасый
Хәятым җене!
Ерак тормасаң,
Бер күрен инде.

Шаркылдап көлеп,
Кычкырып карыйк.
Уйнап, шаярып,
Дөнья куптарыйк.

Җеннәрне җыеп
Иркен табынга,
Кузгатыйк бәхәс
Бәхет хакында.

Монда безне кем
Тыйсын, туктатсын.
Урман,
Җен
Һәм мин —
Яшәү ноктасы.

Ә урман һаман
Телсез — терелми.
Хәятым җене
Килми, күренми.

Еракта кинәт
Кеше кычкыра.
Чакыру авазы
Котны очыра.

Мине эзлиләр,
Мине көтәләр.
Тапсалар, «яңа
Кеше» итәләр.

Җенемне тотып,
Суеп аталар.
Урманны йолкып,
Турап саталар.

И шук, нарасый
Хәятым җене!
Хыянәт итмә,
Ташлама мине!

Син дә бирмәсәң,
Миңа кем бирер
Каршы торырлык
Әмәл һәм сихер.

# *Рухыма*

Замананың шатлыкларга
Коточыргыч карун чагы.
Язмышымның сабыйланып,
Юатылырга зарур чагы.

Әйтерсең лә, төпсез кое —
Йотты мине төшенкелек.
Нигә, рухым, син елыйсың? —
Үзең этеп төшердең бит...

Инде Сәмруг кошы бул да
Югарыга күтәр мине.
Менгән чакта хәлең бетсә,
Ашатырмын йөрәгемне.

# Ачу чыкты

Ачу чыкты — чыбыкларның
Алыйм икән кайсыларын,
Барсының да очларыннан
Тамып тора ачуларым.

Ярсып селким чыбыкларның
Үткерләрен, ачыларын,—
Үзәкләргә үтеп керә
Сызгыруы ачуларның.

Эзләттереп җир тишеген,
Елата ул шайтаннарны.
Сиземләтеп бәла-каза,
Сагайта ул хис-җаннарны.

Йә җилләрне талый башлый,
Ачы чинап, өзгәләнеп.
...Бу язмышның заман белән
Йөз тырнашкан мизгелләре.

# Куршем

Эше юк.
Хисе юк.
Уе юк.
Кургаштан пулялар әвәли.
Курыкмыйк, дускаем, күршедән,—
Акылдан язмаган ул әле.

Кабанга,
Пошига,
Аюга
Пулялар саналып өстәлә.
...Юк аның бер бөртек шикәре,
Бер телем икмәге өстәлдә.

Шәһәрнең бер йолкыш чыпчыгы
Үчекләп тәрәзәгә чиертә:
«Кабаннар, пошилар күптән юк,
Бу бәндә ник түзә, ни көтә?»

Пәрдәләр шатырдап тартылды...
Пулялар өелә өстәлгә...
Ачудан, кургаштай коелып,
Пуляга әйләнде күзләр дә.

* * *

Безнең якта «кәлтә сихерли»
диләр.

*(Автор.)*

Күпме хата, гөнаһларым
Койрык булып арттан килә.
Койрык өзеп качу җаен
Яшел кәлтә генә белә.

Күпме кайгы, хәсрәтләрем
Йөрәгемне төнлә телә...
Кышын тыныч йоклау серен
Яшел кәлтә генә белә.

Мине күрсә, үрә торып,
Күзен терәпката кәлтә:
Юньсез бәндә, күзләремә
Туры кара, дигән мәлдә.

Күптән инде — сабый чакта
Койрыгына баскаладым.
Шул гөнаһым мая булган,—
Хәзер сирәк шатланамын.

Сихерләргә исәбедер —
Йөгрек теле «келт-келт» итә.
И Ходаем, сихерләве
Булсын минем исәнлеккә.

# Яккан идем елан кабыгы

Белмим, нинди зәхмәт бүген
Ниятемә кагылды.
Учак ягып терелттем мин
Кипкән елан кабыгын.

Көмешләнеп яңа кабык,
Бик күңелле чиерди.
Тоеп сирәк канәгатьлек,
Йөрәк читем чемерди.

Әйтерсең лә, кайгыларның
Барсын җыеп мин яктым.
Карап зәңгәр нәзек утка,
Ләззәтлектә мин актым.

Запас булып тора сыман
Алда тагын бер гомер.
Болай йомшануларымны
Язмыш ничек кичерер...

Ахры миңа, Ходай тыйган
Табу хисләр кагылды,—
Кинәт кенә сүнде учак,
Усал җилләр каныкты.

Дулкынлана үлән өсте,
Тирбәләләр кылганнар.
Әйтерсең лә, асларыннан
Шуышалар еланнар.

Елгада да, дулкын түгел,
Кайный кебек еланнар.
Гүя алар агачка да
Буйдан-буйга уралган.

Курыкмыйм да, әмма килми
Кузгаласы, атлыйсы.
Кайсы вакыт, кайсы җирдә
Чагар икән кайсысы.

Кемнәр боерыгыннан сүнде
Канәгатьлек, тынычлык.
Әллә заман, әллә Ходай,
Әллә язмыш тырышты.

Җилләр (нинди җилләр икән?)
Уйларымны сизделәр.
Көлен елан кабыгының
Күзләремә сиптеләр.

# Пошил аткач

Шундый салкын. Нарат шартлый.
Эт селәгәе боз булган.
Җан чыгарып яткан поши
Җылысына сыенам.

Карт аучылар ашыгалар —
Пычаклары йөгерә.
Сунарчымы? Үтерүчеме? —
Үземне кем диярга?

Ирексездән сораусынып
Текәләмен Галәмгә.
Аң көчәнә — динсезлегем
Алланы эзли мәллә?..

Карт аучылар сөяк чаба —
Өлешләргә бүләләр.
Итне түгел, гүя күчләп
Гөнаһларын өяләр.

И табигать, нишлим инде?
Алам миңа тиешне.
Бабалардан калган гөнаһ —
Өлешемнең көмеше.

Картлар йөзе шундый кырыс!
Куркамын эндәшергә.
Шул кырыслык бик борынгы
Күңелсез сер яшергән.

Җылынмый көн. Нарат шартлый.
Үзәндә — аксыл томан.
Үр артында, күпләп атып,
Поши туныйлар сыман.

Шумый юкә чаңгыларым —
Табаннарга кан каткан.
Эзәрлекләп гомерлеккә,
Авыр хис кайта арттан.



# ЯДРӘ ТИГӘН



# Ядрә тигән

Бозланалар күл читләре —
Кыш та тиз җитәр микән?
Күл өстендә ялгыз үрдәк,—
Канатына ядрә тигән.

Очасы юл ерак иде —
Шәһәрләрдән, диңгезләрдән.
Талпынгалап карый да ул,—
Канатына ядрә тигән.

Кайсы явыз, булдыксызы
Аңа төбәп атты икән.
Кычкыра алмый — хәлсез үрдәк,—
Канатына ядрә тигән.

Коткарыйм дип, күлгә киләм:
Бозы юка, төбе тирән.
Үрдәк мине өнәми дә,—
Канатына ядрә тигән.

Туңмый калган күл уртасы
Карый җирнең күзе сыман.
Шушы күзгә үрдәк түгел
Әйтерсең лә ак тап кунган.

# Яңа уй

Дәһшәтле чытырдап,
Учак талпына:
Яшь Себер татары
Ята янында.

Өр-яңа уй уйный
Егет аңында.
Серле дәрт гөлтләнә
Тубыл талында.

Кояш та үтәли
Баккан учакка;
Күләгә дөньясын
Урый-чуалта.

Егетнең уй-хисе
Очкын очыра,—
Себернең тарихы
Бүген борчыла.

Дулкыннар очлана,
Калкып тирәннән,—
Әйтерсең Ермакның
Шлемын кигәннәр.

Һавада сызгыра
Уклар өере.
Атлармы, гаскәрме
Үтте йөгереп.

Корыган наратлар
Шартлап авалар,
Әйтерсең казаклар
Туптан аталар.

Ә егет ишетми —
Чумган уена.
Ялкыннар, сөенеп,
Аңа сыена.

Камышка, талларга
Дәһшәт урала.
Яңа җыр-тантана
Бүген ярала.

Иң татлы, иң изге
Көчәнеш иңә:
Ирнең дә, җирнең дә
Елыйсы килә.

Ә козгын, карт козгын
Нигә очмый соң?
Наратка сыенып
Нәрсә уйлый соң?

Егетнең уенда
Уйный очкыннар:
«Бу җирнең хуҗасы —
Мин бит чынында.

Бу җиргә иң тәүге
Тир, яшь, кайнар кан

Ерткычны куркытып
Тамган бабамнан.

Беренче учакны
Монда ул тергезгән.
Авазны сүзләргә
Башта ул төргән.

Өшегән, ысланган,
Баткан, югалган,—
Кешене кыргыйдан
Саклап калалган.

И табигать улы —
Самим бабам!
Зинһар, гафу ит.
Сине кызганам.

Аллабыз нигә соң
Сакчың булмаган?
Ни гөнаһ өчен соң
Коллык юллаган?

Явызлык, комсызлык
Сине ник җиңгән?
Урманны, сазларны
Читлек иттергән.

Кем әйтә: «Ризалык...»,— дип,
Бу бит — түземлек.
Һаман да яшикме
Рәнҗеп, кимсенеп?!»

Сикрергә җыенган
Бүре шикелле,
Ялкыннар, сыртланып,
Җиргә иелде.

Ә козгын, карт козгын
Нигә очмый соң?
Наратка сыенып
Нәрсә уйлый соң?

Сөрелгән килмешәк
Бүген узына,—
Монда мин хуҗа дип,
Күкрәк сугына.

Бу җирдә бу егет
Бар дип уйламый.
Тоеп җир рәнҗешен,
Каны еламый.

Болытлар, камышлар
Таллар, каеннар —
Бар җиһан тартыла
Учак янына.

Дәррәү кабынып, бер
Балкып алырга,
Күкләргә айкатып
Сөрән салырга.

— И Алла, егеткә
Иңдер көч-куәт.

Килмешәк нәфесен
Тыйсын хакыйкать.

Шаһит бит Җир-ана,
Шаһит — син, Аллам.
Бу төбәк — төп мирас
Калган бабамнан.

Гайрәтле гөрелтәү
Очкын очырта:
Әллә ул искәртә,
Әллә котырта?

— Бу җирдә иң әүвәл
Бабаң таш алган.
Ерткычка иң әүвәл
Ул бит ташлаган.

Карт козгын, селкенеп,
Куйды кычкырып.
Өзелде егетнең
Уйлар чылбыры...

Мылтыгын төзәде
Козгын башына.
«Атарга ярамый!» —
Күңел ачына.

Козгынны атарга
Кушмый бит картлар.
Нигә соң бу коштан
Алар куркалар?

Буыннан-буынга
Күчкән бу тыю.
Йоланы бозмакчы
Егетнең уе.

Карт козгын очмады,
Бүген көн озын.
Наратка сыенып
Нәрсә уйлый соң?

Сугамы ялкыннар
Кара йөзенә?
Кердме тетеннәр
Комсыз күзенә?

Уйлыймы: «Бу җирдә
Ермак чорыннан
Никадәр татарның
Башы чукылган».

Җилләргә ябыша
Учак егәре:
Күчермәк була күк
Җирне, күтәреп.

Кайтырга ашыгам.
Көт мине, якташ.
Сүнмәсен учагың,—
Булам учакташ.

# Ышык җирләрдә

Иркен Себернең
Ышык җирендә
Хыянәт итте
Хатын иренә.

Гыйшык күзләре
Саксыз уйнады:
Адәми чама,
Оят тоймады.

Ире бер кичне
Тотты хатынны;
Йөрәк тамыры
Шартлап тартылды.

Чайкалып куйды
Бик борынгы җир.
...Юк, кыйнамады —
Түзде кырыс ир.

Каты кысылып
Тешне теш ватты.
Яшь хатынын ир
Урманга тартты.

Урман эчендә
Өстен салдырды.
Анадан тума
Бәйләп калдырды.

Хатын үтенде:
— Бик газаплатма,
Йә ат син мине,
Йә хәнҗәр када.

Сезгә сөйлим дә
Үзем тетрәнәм,—
Ходай Тәгалә
Ничек күрмәгән!

Тәнгә сырылды
Черки, кигәвен.
Чибәр хатынның
Бирде кирәген.

Ачы кычкыру
Күкне умырды.
Урман эченә
Курку тутырды.

Эчеп күкрәкне,
Эчеп иренне,
Черки кинәнде,
Черки тилерде.

Ялангач хатын
Озак тилмерде.
...Сеңдерде җанын
Таң эңгерлеге.

Кояш сагайды:
Инде нишләргә?
Әллә менәргә?
Әллә төшәргә?

Сезгә, безләргә
Инде нишләргә?
...Калмыйк бу хәлгә
Ышык җирләрдә.

## Балыкчы хатын

Яшь егет һәм яшь хатын —
Икәү без бер чанада.
Вак усаклык, яшь таллык
Бәсләнә ян-яннарда.

Көндә шундый яктылык!
Җирдә шундый саф аклык!
Язгы хисләр гыйнварга
Керде, ахры, адашып.

Кинәт хатын, дереллдәп,
Мине тартты үзенә.
Иреннәре ашыгып
Тыпырчынды йөземдә.

Шар ачты ул изүен:
— Кил, курыкма, кечегәм...
Каты итеп коч мине,
Туңам, җаным, күшегәм...

Ике «ак кыр тавыгы»
Калкып чыкты изүдән;
И Аллам, нинди сынау
Бирдең минем йөземә!

Куркытты мөкатдәс сер.
Көтмәгәндә чишелеп,—
Дилбегәгә орынды
Йөрәгемнең тибеше.

Ыргылды ат: туң күлне
Барабанлап чабабыз.
Кайсыбызны үчекләп
Ыңгыраша чанабыз?

Яшь таллар — нәзек таллар
Оялгандай болгана.
Өстә очкан саескан
Кунмак була дугага.

Кал саескан, сәбәп юк
Гайбәтләр таратырга:
— Туң балык,— дип, яшь хатын
Каты төртте артыма.

...Инде менә картаям,
Гаеп тоям үземдә.
Карый алмыйм туп-туры
Хатын-кызлар күзенә.

## Туң чуртан

Якташның хәлләрен
Сорарга оныттам;
Күрсәмме өендә,
Чоланда туң чуртан.

Күкрәккә терим дә
Чыралыйм чуртанны.
Түзем юк чәйнәргә,—
Турыдан йотамын.

Рәхәтлек пәрдәсе
Тәнемдә бозлана.
Миләрем, суынып
Кылчыктай очлана.

Буранны тишәр күк
Күзләрнең күреме;
Хисләрем бәсләнеп
Яктырта күңелне.

Бар нәрсә гап-гади,
Җап-җайлы күренә.
Һәм асыл таш булып
Тоелам үземә.

Һәм кинәт шунда мин
Бик тиз айныймын,—
Чуртанның саңагын
Ияккә кадыймын.

Күзләрне яшереп,
Якташка борылам:
— Ни эшләр бетереп
Яшисең син, туган?

## Язгы кар

Күкнең юмартлыгы
Җиргә ишелә.
Аклык бер дә юкка
Корбан ителә.

Күңел, җепшек кардан
Шатлык теләмә;
Кар боткасы булып
Таптала мәгънә...

Кирәк түгел, язмыш,
Мәңгелек гомер,—
Язгы ялкаулыкны
Гына син бетер.

# Йолдызга менимме?

Учагымны ашыгып
Яктым күк тоела.
Күбәләкләр туп-туры
Учакка коела.

Инде күпме җәнлек, кош
Читләшер бу яктан;
Куркыныч кара тамга,
Ис калыр учактан.

Җил учакны йөземә
Капларга ниятли.
Нарат мине күтәреп
Атарга ниятли.

Үземдә гаеп тоеп
Күңелем сүрелә.
Кайда, кайчан артык мин?
Эх, ничек белергә?

Бик авыр төннән төнгә
Күченеп барулар;
Урын сайламый гына
Ут-учак ягулар...

Һәр якта ят учаклар —
Очкынлы, төтенле.
Үз урынымны эзләп
Йолдызга менимме?

## Сагая карт урман

Былтыргы яфраклар өстендә
Күренә тиеннәр сукмагы.
Нигәдер күңелем йомшанды,
Сукмакка басарга куркамын.

Тиеннәр сукмагы өстендә
Яшел нур — яшь үлән йөгерә.
Үләннең очына менгән дә,
Бер бөҗәк күкрәген киерә.

Былтыргы сукмакның бер башы
Корыган наратка бәйләнгән.
Ботакка кадалган Ак гөмбә
Бер төкерем күбеккә әйләнгән.

Тиене килмәгән-тимәгән.
Бу кышны җәнлеккә ни булган?
Гөмбәгә иелеп, күз текәп,
Сагаеп яшәрә карт урман.

## Белмим нигә

Белмим, нигә ала карга
Ярсып чукый аягын?
Җирдә ничек йөгреп йөрер? —
Уйлый микән шул ягын?

Белмим, нигә ак күбәләк
Җиргә бәрә канатын?
Ул һавада ничек очар? —
Уйлый микән шул ягын?

Белмим, нигә алабуга
Ташка ышкый саңагын?
Ничек суда сулап йөзәр? —
Уйлый микән шул ягын.

Дуслар әйтә: — Синең һаман
Бер дә юктан күп кайгың.
Гомрең, кара — тиз кыскара!
Уйла әле шул ягын.

## *Кул йөрәге*

Бителем тулы
Табан балык.
Күтәреп торам,
Судан алып.

Бител селкенә,
Тыпырчына;
Күпме балыкның
Җаны чыга.

Җибәр, дигәндәй,
Дулкын дулый.
Кул акчарлагы
Ачы елый.

Җил ярсып суга
Яңагыма,
Таллар кизәнә
Як-ягымда.

Куркыбрак карыйм
Бителемә,—
Кулнең йөрәген
Элдем мәллә.

Куркыбрак кузлим
Кулнең өстен,—
Йөрәк умырган
Чокыр эзлим.

Күренми суда
Чокыр-яра.
Берни аңламый
Күл — бичара...

...Акчарлак арттан
Елап барды.
Балыкны күбрәк
Тоттым, ахры.

## Черкине сагынам

Көлсәгез, көләрсез, дусларым,
Бу сәер чагымнан.
Себернең мәчкәен — тынгысыз
Черкиен сагынам.

Бу — чирме? Ни булса, шул булсын —
Күчкәндер бабамнан.
Черкиләр тешләгән тәнемне
Кашудан тәм табам.

Черкине тыңласам, тынлыкта
Оета тирән моң.
Хәтерем урманын, күз йомып,
Үтәләй күрәмен.

Зур хаким йә мескен хәлендә
Үземне хис итәм.
Черкиләр безләвендә вакыт
Агышын ишетәм.

Черкиләр тәнемә, йөземә
Яратып кадала.
Куанам, димәк ки, тамырдан
Сәламәт кан ага.

# Язның бер көне

Үрдәк төшәргә курка
Җылы сазлык суына.
Суда калган талларга
Чуртан туе сугыла.

Юмарт бүген чуртаннар —
Уылдыкны җәлләми.
Чиләк белән сосарлык
Бүрән күлнең мәрҗәне.

Гүя эре уылдык
Бөртеге — кояш карый.
Тып-тын оча акчарлак —
Уылдыкны барлый.

Чәнечкене* күтәреп,
Бер мәлдә катып торам;
Ялгышып яз йөрәген
Чәнчеп куюдан куркам.

* *Чәнечке* — балык чәнчи торган корал.

# *Җет ул*

Бәйрәм бүген! Бәйрәм бүген! —
Елгабыздан боз киткән!
Көймәләрдә узышырга
Җыелдык без — яшь-җилән.

Беләк зеңли, теләк зеңли,
Чак тыямын көймәмне,—
Ярдан карый бер чибәр кыз —
Өметләнеп йөргәнем.

Җае чыкты, хәзер аңа
Кемлегемне күрсәтәм;
Барсын артта калдырам да,
Сине сөям, дип әйтәм!

Йөрәгемне йолкып алды
Әйдәүченең* мылтыгы.
Көймәм минем, үрә торып,
Иң беренче атылды.

Узып киттем көчлеләрне,
Уздым батыр Сәйпүшне.
Узып киттем хәйләкәрне,
Уздым җитез Кәпүшне.

Куып җитеп, чөеп уздым
Чабакларны, чуртанны.

* *Әйдәүче* — старт бирүче.

Узып киттем, ахры, хәтта
Ярда чапкан боланны.

Мин беренче! Мин җиңүче!
Халык мактый, кул чаба.
Көймәм белән очырдылар
Ак болытлы һавага.

Күрәм өстән, югарыдан:
Өметләнеп йөргәнем
Китеп бара көймәсендә
Артта калып килгәнең.

«Боз — кыз», «Боз китте — кыз китте»...
Хәл — акылдан язарлык.
Хет үл: Сәйпүшләр, Кәпүшләр
Торалар авыз ерып.

## Ашыкма

Бу давыл эт җанлы —
Басыла белмәде.
Егетем бүген дә
Яныма килмәде.

— Әрләмә давылны,
Мин аны кызганам:
Ашыгып барганда
Итәген җыймаган...

Карурман давылның
Итәген эләктергән.
Күтәреп, тарткалап,
Erткалап бетергән.

Тикмәгә, дисеңме,
Җанланган бар җиһан,—
Урманның куйнында
Давыллык бозылган.

Уйлан да, сеңелкәш,
Барырга ашыкма
Давылда килмәгән
Егетнең каршына.

# Аккошларым

Чапмак, якмак иде күпләр
Күлнең куакларын, камышларын,—
Еладым мин каршы торып:
— Аккошларым анда! Аккошларым!

Көне-төне яңгырар иде
Күл өстендә мылтык тавышлары,—
Еладым мин күкрәк куеп:
— Аккошларым анда! Аккошларым!

Коткарыйм, дип кагылдым мин
Аугa эләккән аккош баласына.
Ниләр әйтим, чукый-чукый,
Йөзгә суккан анасына.

Еладым мин шунда түгеп
Яшьнең кайнарларын, ачыларын:
— Миңа гына суга аласыз бит,
Аккошларым минем! Аккошларым!

# Бәхет

Бәхет бит бу — бәхет!
Чишмәләргә карап,
Йөземне күрә алам.
Чыгып болыннарга
Теләгән чәчәктән
Такыя үрә алам.
Шактый ишекләрне
Үз кулларым белән
Шар ачып керә алам.
Илем картларына
Үз тавышым белән
Сәламем бирә алам.
Төн булсын, көн булсын:
Өемә курыкмый
Кешене кертә алам.
Кайгырып, каңгырып
Йөрсәм дә, һәр җанга
Елмаеп үтә алам.

# *Беренче китабымдагы портретыма*

И рәсемем, рәсемем,
Торам аптырап:
Аңлый алмыйм үземне,
Йөзеңә карап.

Күзләрем еламсырый,
Ирен елмая,
Маңгаем җыерчыгы
Тирән уйлана...

Нишләргә?
Әллә сине
Җиргә күмәргә?
Әллә турыдан-туры
Өскә эләргә?

# Аңлый төшәрсең

Актарылган бураннарда
Юлга чыгып кара.
Шаулап яуган яңгырларда
Шырпы сызып кара.

Ач бүренең күмер күзен
Төнлә күреп кара.
Черки канатыдай юка
Боздан йөгреп кара.

Пошы баткан көрт астыннан
Чия табып кара.
Таштай каткан туң балыкны
Телеп, кабып кара.

Ай астында кыр-урманда
Кышын йоклап кара.
Шунда Себер татарыдай
Сузып җырлап кара.

Аңлый төшәрсең, дустым,
Менә шул чагында:
Нигә мин карап бармыйм
Түбән, як-ягыма.

## Каен – яшел шар

Сезгә ничектер,
Минем күземә
Яшел шар булып
Каен күренә.

Тора калтырап,
Тора көчәнеп —
Оча икән ул
Җирне күтәреп.

Очып бара ул
Кай якка таба?
Бездәге хәлләр
Танышмы аңа?

Бик ерак, озак
Очалмас кебек,—
Ботаклар арган,
Тамыры черек.

Без, җирдәгеләр,
Дуслашыйк әле;
Каен бәйрәме
Бер ясыйк әле.

Һәр халык, ыру
Каен утыртсын.
Каенга каен
Кулын тоттырсын.

Әгәр берәрсе
Егылса арып,
Җирне икенче
Күтәреп алыр.

Кешелек шулай
Дәвамлы булыр,
Җир шарыбыз да
Мәтәлми торыр.

## *Кайт туган ягыңа*

Кайгылардан котылырга
Табалмасаң хәл-чама,
Авылыңа кайт та кер син
Анаң яккан мунчага.

Сөт күбеге сулышыдай
Җиңеләер тәннәрең.
Бал кортының канаты күк
Нәзекләнер көннәрең.

Җитәр сиңа бу җиңеллек
Күтәрелеп карарга,
Шатлык та юк, кайгы да юк
Дигән тыныч арага.

# Айда эрләннәр

Эреләр, җирәннәр —
Кай ара менгәннәр?
Ай йөзен мыж сырып,
Казына әрләннәр.

Сары ком күчләре
Өелә, ишелә.
Бераздан аебыз
Уыла, тишелә.

Авыр ком — сары ком
Яфракта шыбырдый.
Авызга керә дә
Тешләрдә чытырдый.

Йә салкын, йә кайнар —
Өстемә коела.
Ватык ком сәгате
Ага күк тоела.

Ай йөзен «мыж» сырып
Казынсын әрләннәр.
Чирканмыйк, курыкмыйк,
Без — хаксыз адәмнәр.

Ком аксын, тик менә
Ялгышып, таш кына
Тәгәрәп төшмәсен
Бу газиз башыма.

# Беренче кар

(Кубыз көенә озын җыр)

Дөнья бүген
Тар тоела.
Күктән гөрләп
Кар коела.

Сабый бала
Авыз ачкан:
Шатлык, шуклык
Аңкый кардан.

Япь-яшь төлке
Йоклый алмый.
Кабат-кабат
Карда ауный.
Җирне тырный,
Ләң-ләң өрә,—
Тәүге тапкыр
Карны күрә.

Төлке бик шат!
Артык тере!
Бирсен Ходай
Озын гомер.

Яшь аучы да
Дулкынлана.
Шатлыгыннан
Тирли, яна.

Җилкендерә
Саф күңелне
Кар бөртеге
Җиңеллеге.

Очты егет,
Гүя аны
Йолкып алды
Урман алды.

Һәр тарафта
Төлке эзе,—
Чекерәя
Өмет күзе.

Тора йөрәк
Чак-чак эләгеп:
Бирсен Ходай
Уңыш! Бәхет!

Күңелләрне
Чеметтереп,
Кар түшәлде
Мул иттереп.

Беренче кар!
Беренче кар!
Язмышларда
Катнашың бар.

Килде эздән
Аучы посып,
Ярый әле
Сынды чыбык.

Япь-яшь төлке
Ялт-йолт итте.
Ярый әле
Качып китте.

Берсенең дә
Юктыр зары,—
Кыш башланды
Гына бары.

Иң беренче
Куркып очу!
Иң беренче
Койрык очы!

Беренче кар,
Яшик тату.
Телим сиңа
Тыныч яту.

Тыныч ят та
Көн дә телә
Озын гомер
Яшь төлкегә.

Тыныч ят та
Күктән сора
Уңышлы ау
Сунарчыга.

Һәм миңа да
Бәхет телә:
Туры, каты
Басыйм җиргә!

# Черек каек

Ята иде ярда каек,
Комга батып, капланып.
Йөгереп төште шук гөрләвек,
Ерактан ук шатланып.

Этте-төртте, шаярды ул,
Аска кереп кытыклап.
Карт каекны кыстады ул,
Им-томнарын пышылдап.

Картлык, түзми бу кыстауга,
Бер селкенеп карады.
Коры, черек такталары
Коелды да таралды.

Очып йөрде ала карга:
— Карт — харап,— дип сөйләнеп.
Бушап калган яр буенда
Кунар урын эзләде.

...Елга, берни булмагандай,
Алга акты да акты;
Черек такта, чүп-чарларны
Ярга какты да какты...

# Аллам ишетмәгән

Күзләремне кат-кат уам:
Туган ягым түгел мәллә? —
Шарак шаулап торган җирдә
Йолкыш бушлык күренә лә.

Кая гына элим икән
Арган рухны, карашларны,—
Күрмим уйчан каеннарны,
Сабыр буйлы наратларны.

Кай якларга тәгәрәгән
Чал толымлы тумарлары?
Өсләрендә бии иде
Дәртле туе торналарның.

Җилгә аскан болыт булып,
Куе таллык чыңлый иде,
Болытларны чайкалдырып,
Текә камыш сулый иде.

Кошы, черкиләре белән
Инешкәйне йоткан канал.
Кешене дә йотар сыман,
Ул ыжгырып тора һаман.

Кемнәр шулай туган җирнең
Җан җелеген актаралган?
Шундый җаннар туа бары
Җен яраткан аналардан.

Каныкмыймын якташыма,
Талаттың, дип, күрәләтә.
Миндәй читтә яшәгәннең
Юктыр хакы үпкәләргә.

— Саклый күр! — дип ялваргандыр
Якташ Ходай Тәгаләгә.
Аллам аны ишетмәгән,
Минем тавыш җитмәгәнгә.

Шуңадыр ла ачынуны
Агызырга кыенсынам.
Сүз башласам, шыңшый тавыш,
Типкәләнгән көчек сыман.

# *Нинди корттыр*

Күңелемә корт керде —
Ашый да ашый:
Нигә түгелмен икән
Мин ике башлы?

Ходай да качкын күзләр
Уеп куймаган.
Татлы икейөзлелек
Биткә коймаган.

Кайчак яшисе килә
Шундый иттереп!
Сөлек кебек суырып,
Кара көйдереп!

Байлык миңа ышкылып
Ага янымнан.
Акылым ычкына алмый
Намус авыннан.

Җанны ашый да ашый,—
Ул нинди корттыр?
«Яшәп кал»,— дип күңелне
Кайчан котыртыр?

# Себер татары

Ишкәгемне киң каерып
Тирән батырамын.
Көймәдәшкә җиңел була
Ишеп барулары.

Учак яксак, чүмәшәмен
Очкын очкан якка.
Учакташым төтен йотмый —
Җайлап кына ята.

Киек атсак, үзем сорап
Алам кабыргасын,—
Итлерәге, миңа түгел,
Сунардашка калсын.

Бирәм соңгы серәнкәне,*
Соңгы телememне.
Күрәм кеше күңелләрен,
Тыңлап күңелемне.

Кызганмыйм да, үкенмим дә —
Рәхәтләнеп калам.
Себер татарларын шулай
Яраткан бит Аллам.

* *Серәнкә* — шырпы.

# *Исәнлегем*

Чак беленеп,
Чак күренеп,
Бар булуыннан
Сабыйдай кыенсынып,
Агачларда
Чак эленеп
Тора алдымда
Бер гаепсез моңсулык.
Үткән кыштан,
Үткән эштән
Эзләп мәгънәләр
Миләрне көчәндермим.
Шатлык тоеп,
Песнәк сыман,
Зеңгелдәп куйды
Зәңгәрсу исәнлегем.

# Саескан

Аптыраганнанмы? Халәтем
Иңемә мылтыкны элдерде.
Саескан ерактан күрде дә,
Куркыныч килә, дип белдерде.

Мин нинди куркыныч булыйм ди.
Кош юкка борчыла шул чаклы!
Йөрәкнең һәр чите кителгән,
Күңелем — борчулар учагы.

Мин барам. Яшемне сөртергә
Йөземә чыбыклар орына.
Яшьләрем сөртелми — ябешкәк,
Чык булып яфракка сарыла.

Саескан кычкырып, тузынып
Сагайтты кошларны, каенны.
Бер атып уятыйм мәллә соң
Суынган, миңгерәү җанымны.

Сизмәдем: мылтыгым түтәсе
Ышкылып иңбашым канаткан.
Саескан турында уйланып,
Борчылып сунардан мин кайтам:
Куркыныч килүен белдереп,
Оча бит мылтыгым очыннан.
Без ирләр ник үрнәк алмыйбыз
Менә шул табигать кошыннан?

# Мәхәббәт

— Сиздермисең, күрсәтмисең,
Бармы синең сөйгәнең?
— Чынлап сөйгән, янып көйгән
Йөремидер сөйләнеп.

Егет чактан күрше агай
Колагыма киртләде:
«Мәхәббәт ул — карурманда
Үзең тапкан җиләклек.

Качып кына барасың да
Туйганчы сыйланасың.
Ятлар табып алмасын дип,
Борчылып моңланасың».

# Мин поши куалыйм

Яшәүләр, әй, рәхәт!
Урманга мең рәхмәт!
Уйланмыйм, моңланмыйм,—
Мин поши куалыйм.

Күрше кыз ялына:
— Кил,— дия яныма.
Юк инде, килә алмыйм,—
Мин поши куалыйм.

Күрше кыз үтенә:
— Өйлән,— ди,— үземә.
Юк инде, ала алмыйм,—
Мин поши куалыйм.

— Тыңла! — ди әнкәем,—
Шул кызның әйткәнен.
Юк инде, тыңламыйм,—
Мин поши куалыйм.

Инде кыз кияүдә.
Төрттерә күргәндә:
— Син поши кууда
Көндез дә, төнлә дә...

Ә поши күптән юк —
Атты бит «мужигым»,
Пошиның тиресен
Астыма түшимен.

## *Кунакка кайткач*

Анасының култыгына
Поскан чебеш шикелле,
Табигатьнең кочагыннан
Карый миңа Киндерле.*

Бу нарасый төбәкне дә
Замана аямаган.
Яман чирен — аракысын
Читтәрәк коялмаган.

Утка төшкән күбәләктәй
Көйгән күпме күңелләр.
Алар — сабыйдай самими,
Һәм эчкерсез иделәр.

Әүхәт тә бит шундыйлардан:
Сүнгән йөзе, күз нуры.
Исе дә юк — ачуланмый,
Сәрхуш, дисәң, туп-туры.

Нинди шатлык тоя икән
Бу дөньяда ул яшәп?
Йөрәгемне учлап кысып,
Энем белән сөйләшәм.

— Нигә, энем, калош тишек,
Оегың да күренми?

---

* *Киндерле* — авыл исеме.

— Яланаяк йөрү, абый,
Озынайта гомерне.

— Җылы кием-мазарларың
Чөйләреңдә күренми.
— Ялан өстән тышта йөрү
Озынайта гомерне.

— Ишек алдың буп-буш, энем,
Утыннарың өелми.
— Салкын өйдә сулап йоклау
Озынайта гомерне.

— Ятса икән өстәлеңдә
Сынык икмәк телеме.
— Гөмбә, балык, җиләк ашап
Озынайтам гомерне.

— Мунчаң черек. Оятыннан,
Ахры, җиргә сеңүе.
— Кар-яңгырда юынам мин,
Озынайта гомерне.

— Кайда балаларың? Бичәң
Мич янында йөреми...
— Бу дөньяда ялгыз яшәү
Озынайта гомерне.

— Ялгызың син. Озын гомер
Сиңа энем нәрсәгә?
Җитмимени калган гомер
Бер туйганчы эчәргә.

Юк, айнымас, ул терелмәс,
Башын ташка бәрсәң дә.
Һаман шул ук тозсыз җавап,
Ихтыярсыз фәлсәфә.

Ничек ансат котылган ул
Кайгысыннан дөньяның.
Күпме кайтып, ишетә алмыйм
Аһ-зарларын мин аның.

Оят, иман, әхлак — бары
Аның өчен узган эш.
Сүнсә сүнәр икән шулай
Кешелеккә ышаныч.

Нинди хыял, өметләргә
Тора икән тәрәлеп.
Кайчан атлап китәр, аңлап,
Гаиләсенә кирәген.

Авылкаем, кайчак сиңа
Үпкәлисем килә бит.
Күз алдыңда тыныч кына
Юаш энем үлә бит...

## Әүхәт әнемә хат

Төнлә айнып тыңла тынлыкны,
Ишетерсең ачы чынлыкны.

Ватык тәрәзәңдә тырналып,
Елый балаларың язмышы.

Суык моржаларга чорналып,
Елый балаларың язмышы.

Яланаяк, бозлы чоланда
Елый балаларың язмышы.

Әллә кырда, әллә урманда
Елый балаларың язмышы.

Юк, сызгырмый кысан сулышың,—
Елый балаларың язмышы.

Шулай елап чыга төн озын
Үксез балаларың язмышы.

# Сыерчыклар яратмаган

Көй сызгырып оя ясыйм
Язның матур таңында.
Күрше кызы, иртә чыгып,
Басып тора янымда.

Ниятендә ниләр бардыр —
Әй сөйләшә, әй көлә.
Кайчак эссе толымнары
Беләгемә түгелә.

Туңган куян баласыдай
Калтырана күкрәге.
Карашыма тирән батып
Эзләнә керфекләре.

Юк, алданмам, игътибарым
Чүкечтә дә кадакта.
Тырышма, дим, күршекәем,
Суктырырга бармакка.

Ә кыз китте. Толымнарын
Чорнап тотып, тарткалап.
Черек такта очып төште
Каты япкан капкадан.

Язгы таңнан ләззәт тапмыйм,
Чыксам, иртән уянып. —
Сыерчыклар яратмаган
Мин ясаган ояны.

# Нарат һәм мин

Ботаклар аша зәңгәр күккә карап,
Аударды мин колач җитмәслек нарат.

Кирәк иде елгыр каек каерга,
Бәхет эзләп еракларга агарга.

Йөрәк туктый язды куркып, калтырап,—
Ялгыш якка авып китте чал нарат.

Анда нәни сабый нарат буй суза.
Сынмый калды — коткарды бит могҗиза.

Ничек барып кочканымны тоймадым.
Әллә еладым мин? Әллә уладым?

Күкрәгемдә нидер кинәт шартлады.
Күңел еракларга тартмый башлады.

Җир, гөрселдәп, яңгырады аңымда:
«Синең нәсел тора кору алдында».

Туган җирем, нигә туры әйтмисең?
Нарат белән мине нәрсә бәйли соң?

Сабый нарат очы ята теземдә.
Утырам минауган нарат өстендә.

# Кояш качты

Җир читенә
Кояш төшкән.
Минем буем
Җитә икән.

Итәгенә
Килим әле,
Борчуларны
Төйим әле.

Кояш шуңа
Чыдар микән?
Иртәгесен
Чыгар микән?

Уйны кояш
Сизде, ахры —
Миннән качты
Бер төн ары.

# Йөзне кыйнатасы килә

Калкулыкта ялгыз каен,
Җәелгән ул табып җаен.
Бер карасаң, яшел канат,
Бер карасаң, яшел янгын.

Сыйпап, буяп җибәрә дә
Җәйнең салмак болытларын,
Кемнәрнедер каршыларга
Үрә-сүтә толымнарын.

Кайткан чакта туры килсә
Яннарыннан үткәләргә.
Кызыгамын оҗмах булып
Оеп яткан күләгәгә.

Хакым юктыр бу оҗмахка,
Утырырга кыенсынам.
Ялгыз каен мине түгел,
Башкаларны көтә сыман.

Миңа иртә әле, иртә
Калкулыкта йомшанырга.
Йөзне кыйнатасы килә
Каенның чыбыкларына.

# Телем телләдем

И, нарат, нарат,
Син шундый сабыр!
Әйдә, җилләнеп
Болытлар чакыр.

Гайрәтле болыт
Өскә салынсын,
Кое салкыны
Йөзгә кагылсын.

Маңгайны «ярып»
Эре тамчылар
Челлә өстенә
Ятьмә салсыннар.

Юаш әрекмән
Такмагын атсын.
Такмак көенә
Яңгырлар чапсын.

...Чәчәкләр укый
Соңгы догасын,
Ә син һаман да
Тыныч торасың.

Әллә куйныңда
Яңгыр йомгагы.
Шуңа син сабыр —
Күзең йомгансың.

Ничек булса да
Ярсы, чайкал син,—
Яңгыр күзенә
Ылыс кадалсын.

Һаман, наратым,
Гамьсез торасың.
Яшен чакырам;
Аңа чыра — син!..

Нараткай куркып
Тетрәнеп куйды.
Өстемә кипкән
Ылысын койды.

Үзем дә куркып
Тешләдем телне.
...Өметсезлектән
Дәшүем иде.

## *Ала карга сайрар*

Каргаларда
Күп зар;
Иртә таңнан:
«Карр! Карр!»

Шатлыкларым
Тар-мар.
Алда хәвеф
Бар! Бар!

Карга куа:
«Карр! Карр!»
Бу иленнән
Кач! Бар!

Калсаң төнгә
Кадәр,
Кайгы угын
Кадар...

Илем күге
Тап-тар,
Карга канат
Каплар.

Кая барма:
«Карр! Карр!»
Кайда безнең
Шартлар?

Ходай ничек
Саклар?
Куркак безнең
Җаннар.

Югыйсә бит
Аң бар,
Без барлыкны
Барлар.

Хәлләремне
Аңлар
Илдә тагын
Кем бар?

Күндек — тыңлыйк:
«Карр-карр».
Каркылдауда
Тәм бар.

Көтик — Ходай
Җайлар;
Ала карга
Сайрар.

# Ишкәк

Чормада таптым да
Төшердем аска.
Гаҗәпләнде улым:
— Бу нинди такта?

— Ишкәк, улым, ишкәк.
Онытылып ята.
Мин ясаган идем
Синдәен чакта.

Тыңла: ничек елый
Ишкәк ярыгы!
Җилнең сыртын тешләп
Өзмәкче, ахры.

Аңлыйм ишкәк хәлен,
Шуңа кырыс мин;
Авыл урамында
Исә кысыр җил.

Балык су исен җил
Күлдән китерми,
Дулкыннар шавын да
Ул ишеттерми.

Күлнең тирәнлеге
Карга ботыннан.
Ишкәгем бик черек —
Тузар, тотынсам.

— Әле кайчан икәү
Булдыра идек.
Сугып, дулкын сыртын
Сындыра идек.

Каек була иде
Гелән туп-тулы.
Йә балык, йә хыял
Белән туп-тулы.

Җәйге аяз кичләр
Шатлыклы иде.
Яр башында бер кыз
Каршылый иде.

Толымнары сиңа
Сарыла иде.
Тезләренә «ялгыш»
Кагыла идең.

Кыз киткәндә, сиңа
Таяна идем.
Сине назлап, сыйпап
Моңая идем.

Ярыкның елавы
Өтә күңелне.
Ишкәк миңа рәнҗеп
Елый түгелме?

Ә улым аңламый
Җиңемнән тарта.
Чак типми, сорый ул
— Бу нинди такта?

# *Кикрикук тә кикрикук*

Ымсындырып
Таң ата.
Әтәч кикрик
Кызарта.

Әтәч шактый
Дәртле күк.
Аяк тибә:
— Кикри-күк!

Таң уяткан
Өметне
Кармак итеп
Мин бөктем.

Җиме —
Әтәч кикриге.
Бәхет
Күреп килерме?

Җил дә килеп
Өлгерде,
Сыйпады ул
Кикрикне.

— Бәхет бүген
Кап! Кап! Кап!
Яр башында
Ялтырап ят.

Күккә болыт
Мин асам —
Булсын әйдә
Кылказан.

Бәхет тулып
Кайнасын.
Абзаң бүген
Масайсын.

Әтәч якын
Китерми,
Горур тота
Кикрикне.

Котырта ул:
— Кикрикүк!
Кикрик берәү,
Ә сез күп.

Кирәк булса
Бу кикрик,
Йоклап ятма
Тор иртүк.

Торып карыйм
Бик иртүк;
Һаман да шул ук
Кикрикүк.
«Кикрикүк» тә
«Кикрикүк».
Бәхеткәем
Бик өтек.

# *Нигә аттым?*

*(Тамак төбе белән җырлана)*

Нидер җитми
Минем җанга:
Төзәп аттым
Ак томанга.

Кичке кояш
Яньчелде күк,
Тел сындырып
Тынды kәккүк.

Сырт кабартты
Куак, үлән.
Кош дөньясы
Купты күлдән.

Күп нәрсәнең
Очты коты,
Үземне дә
Курку тотты.

Колагымны
Яра язды
Мылтыгымның
Кайтавазы.

Нигәдер ул
Бик тиз кайтты,
Бөгәрләнеп
Янга ятты.

Кайтавазны
Җәлләп куйдым;
Сыйпарга дип
Кулым суздым.

Томан, ахры,
Артык тыгыз,—
Аның аша
Булмас чыгып.

Томан килә,
Килә «гүләп».
Аңкый аннан
Салкын куәт.

Менә-менә
Килеп җитә.
Мине егып,
Кырып китә.

Пышылдыймын
Куркуымнан:
— Сау бул, Кояш.
Сау бул, Урман.

Нигә аттым
Мин, дивана,
Тыныч яткан
Ак томанга.

Ятсын иде
Сазда тулып,
Ак тау булып,
Ак төн булып.

Миңа акыл
Керми һаман:
Тиктомалга
Тавышланам.

Тавышымнан
Куркып калам,
Үз башыма
Кайгы табам.

...Күрәм,
Күзне кат-кат усам:
Өскә килә
Гади томан.

## Басмада

Килегез, карагыз
Бик сирәк тамаша:
Кыз балык чистарта
Күлдәге басмада.

Күңелле четердәп,
Тәңкәләр чәчелә,
Сөенеп куналар
Чибәрнең чәченә.

Житезлек, өлгерлек
Пычакны уйната,
Жанымда рәхәтлек,
Шаян дәрт уята.

Ләмләнгән басманы
Яктырта кыз тезе.
Дерелди такталар
Дерелди күл өсте.

Карыйм да чибәрнең
Йөзенә, учына,
Чыгырдан чыгардай
Йөрәгем очына.

...Эх, ятарга кызның
Пычагы астына.
Кырмасмы картлыкның
Кабыгын аз гына?

## *Чытырдапябыштым*

— Кот керсен, кот чыксын!
Пышылдап,
Селкетәм бер күндәм агачны:
Урманым, күтәреп пәрдәсен,
Үземә хәзинә ачмасмы?

— Ул монда, ул монда,— дигәндәй,
Кайдадыр бер тукран тукылдый.
Агачтан агачка күченеп,
Хәзинәгә юлны ул бутый.

— Кит моннан, кит кеше, дигәндәй,
Ишеттем козгынның тавышын.
— Кот керсен! Кот очсын! —
Кычкырып,
Агачка чытырдап ябыштым.

# Бал корты йөземдә

Чалкан ятам... Каурыйлана
Бик биектә ак болыт.
Сулышымны тыеп ятам —
Эчтә кайгы туп-тулы.

Чалкан ятам. Күк күкрәген
Җир түшенә терәде.
Икесенең арасына
Аһ, кысылды йөрәгем.

Чалкан ятам... Хәлсез марта*
Кунды нурсыз йөземә,
Җыеп энә-тырнакларын,
Ул утырды тезем ә.

Хәлем калган пышылдарлык:
— Күз яшемне эч, менә.
Өеңә кайтып җитәргә
Куәт бирер үзеңә.

Эчми марта — шуыша бит
Йөрәгемнең өстенә.
Күкне җирдән аерыйм, дип,
Соңгы кабат җилпенә.

* *Марта* — умарта корты, бал корты.

## Тозак кора идем

Пималарым тишек иде,
Өсләремдә иске-москы.
Бәйли идем тозакларны,
Яшь талларга ышкып-ышкып.

Шул яшь таллар салкын төндә
Авыртудан елагандыр.
Куяннарым, якын килми,
Сагаешып тыңлагандыр.

Ә аннары шаяннары,
Өй түренә төнлә килеп,
Чәчте эре «борчакларын»,
Үзләренчә миннән көлеп.

Тозакларны күп корсам да,
Куян күпләп тоттырмады.
Тиде Өмет теңкәсенә
Буш тозаклар елтыравы.

Еллар, куян «борчагыдай»,
Нокталанды анда-монда.
Эз табалмый интегәмен
Көртле гомер аланында.

Өметемне сагайттырып
Язмыш әллә миннән көлә.
Инде хәзер кояшы да
Тозак булып киерелә.

# Моңым ага

Йөрәк кыстый.
Тәнем кыстый.
Күңел кыстый.
Җаным кыстый.

Хисем кыстый.
Акыл кыстый.
Җирем кыстый.
Халык кыстый.

Исем китми
Бу дөньяда
Кыстаучылар
Күп булганга.

Ымсынмыйм да
Көчәнергә;
Булыйм бары
Исән генә!

Ятып җылы
Томаннарга,
Ләззәт бөркеп
Моңым ага.

Моңым ага,
Болытларны
Салмак кына
Кага-кага.

Моңым ага.
Учакларны
Ашыкмыйча
Яга-яга.

Моңым ага.
Таңнарыма
Моңлы өмет
Тага-тага.

Моңым ага
Үзе генә
Белгән, тойган
Якка таба.

Тап булмасын
Адашырга
Кыстауларның
Арасында.

Карамыйча
Йолдызларга,
Нарасыем —
Моңым ага.

## Ак болытка карыйм да

Бал кортлары сырылган күк
Көнбагышлар йөзенә,
Хыялларым куна иде
Ак болытлар өстенә.

Нинди җилләр исә хәзер!
Ага нинди болытлар?
Күләгәләр хыялларны
Җиргә кысып сыттылар.

Инде миндә башка кайгы,—
Булмас кебек шатлыклар.
Ак болытлар таш төялгән
Олау булып бастылар.

Ак болытка карыйм да мин
Күзне йомам тетрәнеп:
Күзем ачсам, шатлык бәргән
Саф зәңгәрлек күрмәмме?

# Яшьтәшем Фатихка

Озаккамы туган якта
Гәп-сүзсез йөрүләрем?
Заман сөяк итте, ахры,
Телләрен шул ирләрнең.

Нурлы күзләр, сөремсез йөз
Күрергә мин сусадым.
Рәхәтләнеп, күзгә карап,
Килә сорыйсыларым.

Балык ничек? Иртә-кичен
Ауларга тыгыламы?
Капкыннарга төлке-мазар
Бик теләп сугыламы?

Каплап куйган каегыгыз
Сезне көтеп сыктыймы?
Урман, кыздай күз уйнатып,
Серләшергә кыстыймы?

Ничек анда таң атканда
Сулый наратлар шавы?
Юкәдәнме, ефәктәнме
Атларыгыз тышавы?

Туган авыл урамнарын
Ялгыз башым мин үтәм.
Капка төптә тәмәкеле
Берәр ирне күр икән.

Нишли ирләр? Ниләр уйлый,
Качып капка артына?
Җырларыма көч, моң кирәк
Капкаларны ачарга.

## Көнем – упкын

Миңа күп нәрсә
Карый күз текәп.
Белмим, кайсысы
Миңа бик кирәк.

Көнем — кояшлы
Тирән упкынлык.
Белмим, нәрсәгә
Торам тотынып?

Юк елаганым,
Күптән көлгәнем...
Белмим, нәрсәгә
Торам эләгеп?

Ничек тырышыйм?
Ничек мин басыйм?
Бу упкынлыктан
Ничек мин качыйм?

Сорап ризалык,
Борчый язмышым.
Селкенмим, хәтта,
Авыз да ачмыйм.

Мин куркак, куркак —
Әйтергә оят.
Кирәкми миңа
Бернинди куәт.

Упкын өстендә
Җаным тилмерә:
Юк мөмкинлекләр
Горур үләргә.

## *Картаюны тойгач*

Кәрәзгә җыелган
Умарта балы күк,
Тирәнгә җыелган
Иң эре балык күк,

Әз-әзләп җыелды
Мин-картка тәҗрибә.
Мөмкиндер, «әй, син» дип,
Тормышка дәшәргә.

Тәҗрибәм барлыгын
Онытып куямын.
Кайчакта үземне
Бәхетсез тоямын.

Йөземне кызартмас
Тәҗрибәм —
Тик минә
Яшәргә кызыгу
Күземә куналмас.



# СӨМӘН КАДЫЙМ



# Нинди Төмән?

*Булат Сөләйман истәлегенә*

Иркен Төмән!
Моңсу Төмән!
Юмарт Төмән!
Кызу Төмән!
Минем Төмән — Туган ягым капкасы!
Куыштырып дулкыннарын,
Елгыр Тура* сорый миннән:
— Сагыныпмы, кызыгыпмы кайтасың?

Монда болгар,
Монда монгол,
Монда үзбәк,
Казахыдыр,
Монда манси** — буталганнар каннары.
Аталабыз Себер татарлары,
Әмма кайсыбызның
Бабалары чып-чын Себер татары?

Тарих тирән,
Кое сыман:
Мүкле, серле,
Төшкән саен
Салкынрак, куркынычрак тоела.

Телим кайчак
Мәрхүм әкәм

---

* *Тура* — елга исеме.
** *Манси* — аз санлы Себер халкы.

Булат кебек
Кайберләргә:
— Сез — килмешәкләр,— дип әйтеп куярга.
Кайчагында
Күңелләнеп:
— Гафу ит,— дип
Дәшмәк булам
Ерактагы, тайгадагы мансига.
Әмма халкым
Миңа андый
Вазифалар
Тапшырмаган —
Ашыкмый тор, тыел, күңел, ярсыма!

Иркен Төмән!
Моңсу Төмән!
Юмарт Төмән!
Кызу Төмән!
Минем Төмән — Туган ягым капкасы!
Сиңа кайтсам,
Мин сагаям:
Сүзләр эзлим,
Сүзләр сайлыйм —
Килми йөрәк тотып ялгыз ятасым.

# Госман

Кояш кашы
Шактый чыккан,
Күл буенда
Мин дә Госман.

Шаулый, чыртлый,
Җырлый урман.
Тонык гырлап
Йоклый Госман.

Шап-шып чумып
Уйный чуртан.
Авыз ачып
Йоклый Госман.

Таңы салкын,
Чыкка чумган.
Шыр ачылып
Йоклый Госман.

Йөзен, битен
Черки сырган.
Көлемсерәп
Йоклый Госман.

Таң атканда
Ниләр булмый.
Башкайларга
Ниләр тулмый.

Гамьсез Госман
Хис-уйларга,
Кайгыларга,
Хыялларга.

Төкергән ул
Соң калуга,
Сызлануга,
Моңлануга.

Күлгә төшеп
Йөзәм, чумам.
Ничә тапкыр
Йөреп чыгам.

Учак сүнсә,
Тагын ягам —
Һаман ята,
Йоклый Госман.

Үч иткәндәй
Уйларыма,
Хисләремә,
Хыялыма,
Көлемсерәп
Йоклый Госман.
Җил сагайтып
Гырлый Госман.

Кул күтәрәм —
Хәзер сугам.
Күрәм: күзен
Серле кыскан.

Гүя шулай
Ятып, Госман
Зур бәхетне
Җиргә кыскан.

Шулай булса,
Шулай булсын —
Озак йокла
Дустым Госман!

Туган якның
Менә шушы
Тыныч матур
Иртәсендә
Минем бәхет
Йөри, дустым,
Синең бәхет
Тирәсендә.

## Озын җыр

«Саз каены тиз саргая...»
«Ялгыз каен тиз саргая...»
Ничек итеп җыр башларга? —
Ялгызлыкта җан ашала.

Иңеп ялгыз каеннарга
Йөрим туган ягымда ла...
Шушы яшел карында ла
Тусаң иде яңадан ла.

* * *

Сусарларны куып булмый,
Кысыла бит сулышлар.
Урманнарга кереп йөрсәм,
Кызыктыра куышлар.

Качма, сусар, тукта, сусар,
Сиңа минем йомыш бар:
Булыш әле, табыш әле
Мин сыярлык куышлар.

Берсендә мин яшь түгәрмен,
Берсендә мин көләрмен,
Берсендә мин уйланырмын.
Берсендә мин үләрмен.

Алдар идем бу тормышны,
Сусар булып булмый бит.
Кысан бәхет куышлары —
Сыеп кына булмый бит.

* * *

Ишеттерәләр колагыма,
Сугалар яңагыма...
Дус әйләнде дошманыма,—
Түз, күңел, сынма гына!

Кизәнеп ихтыярыма,
Басалар як-ягыма —
Теләп мине туктатырга,—
Түз, күңел, сынма гына!

Мин ышанам җырларыма,
Тулышкан моңнарыма.
Үз ягымда, үз чагымда
Түз, күңел, сынма гына!

## Язмыш шуа

Боз өстендә
Яфрак шуа,
Аны астан
Чуртан куа.

Чуртан, бик яшь
Булгангадыр,
Кош-мазар дип
Уйлагандыр...

Икесе дә
Китеп бара
Ерактагы
Иң уртага.

Җил артымнан
Этеп карый,
Артларыннан
Куып бар, ди.

Йөгереп кенә
Китәр идем,
Бозы гына
Күтәрми бит.

Иркенлектә.
Бозны сырлап,
Өерелә
Соңгы яфрак.

Куа-куа
Чуртан арыр,
Маңгаен да
Бәреп ярыр.

Саңак җәеп
Чалкан ятыр.
...Иртәгә боз
Калын катыр.

Иртәгәсен
Берәү килер,
Курыкмыйча
Күлгә керер.

Җырлый-җырлый
Бозны чукыр.
Балык башын
Кысып тотыр.

Яфракны да
Куып җитәр,
Үкчә белән
Сытып үтәр.

Мин иртәгә
Монда булмам.
Ашыгамын —
Бәхет куам.

Шунсы ярый:
Җан кытыклап,

Тел очында
Көйри такмак.

Ары лап-лап,
Бире лап-лап —
Булса икән
Күлне каплап.

Яфрак кача,
Чуртан куа —
Юка бозда
Язмыш шуа.

Зәңгәр элпә
«Чырт-чырт» итә —
Җәһәннәмгә
Хәбәр китә.

# Әле була яшәргә

Әйдә, ашыгыйк
Урман буена.
Көртлекләр килгән —
Бәстә коена!

Кайсы яклардан
Килеп чыкканнар?..
Аклыкка шатлык
Булып шытканнар.

Канатын көртлек
Җилпеп җибәрә:
Бөреләр зеңли,
Каен тирбәлә.

Көртлекләр бик сак
«Кыт-кыт» диярләр.
«Китердек сезгә
Кот, кот!» диярләр.

Рәхмәт, көртлекләр!
Күзем яшьләнә...
Була бит әле,
Була яшәргә!

## Бөрлегән

Йоклыйлар балалар,
Таралып идәндә.
Кандала дөньясы
Кан эчеп кинәнә.

Яшь йотып, яшереп
Әнием сулкылдый.
Уллары тагын бит
Эч кысып, ач йоклый.

Авылның өстенә
Сагышлы ай килгән.
Түбәгә чүгәләп
Морҗага иелгән.

Ә әни сулкылдый,
Тыелып, тын кысып.
Ай бары ишетә
Балалар сулышын.

Шул төнне шатлык та
Килергә уйлаган.
Айданмы шикләнеп,
Урманда туктаган.

Моңаеп, каңгырап
Аланда йөрегән.
Ул сырган эзләрдә
Калкыган бөрлегән.

Бөрлегән, бөрлегән...
Әй пешкән, күп икән!
Җыябыз куанып
Килдек тә бик иртән.

Онытып ачлыкны,
Шауладык, кычкырдык.
Әллә без бәхетне
Шул чакта курктык?

Күзләрен яшереп
Әнием иелә.
Җыелган җиләккә
Күз яше түгелә.

Бөрлегән кадәрле
Бөртекләр түгелә.
Әнием яшеннән
Таң чыгы күперә.

Балалар бит — алтау:
Тиз тула савытлар.
Олы ул — мин китәм
Җиләкне сатарга.

Саталмыйм — җан сыктый,
Бер чатка мин чүгәм...
Әнием күзедәй
Мөлдери бөрлегән.

...Тагын төн. Яшереп
Әнием сулкылдый.
Уллары тагын бит
Эч кысып, ач йоклый.

Ай тагын чүгәләп
Морҗага иелгән:
Мин үксим тел тешләп,
Яшереп әнидән.

* * *

Авылыбызда Нургали карт
тал каезлап кәсеп итә иде.

Инешем, кайгы бар,
Акмый тор, тукта әле.
Ярыңда тал суя
Күрше карт Нургали.

Яр аша еракка
Шыксызлык кычкыра.
Шәп-шәрә ботаклар
Күңелне сыдыра.

Кәүсәгә кырмыска,
Бөҗәкләр кагылмый.
Кояшның нурлары
Тия дә шакылдый.

Кая ул бу җирдә
Көләргә, уйнарга.
Күздән күз яшердек:
Әзер без еларга.

Йөрәктә кабынып,
Йөзләрдә үч яна.
Нишләргә? Теш кысып
Малайлар уйлана.

Туган як — изге җир
Күзалда талана.
Безләр дә хуҗа бит
Бу ямьле талларга.

Нигә соң Нургали
Кызганмый талларны?!
Малайлар күзенә
Туп-туры карамый.

...Кабыксыз кәүсәләр
Җәй төнен яктырта.
Күкләрдә чагылып
Йокымны качырта.

— Кая син җыендың?
Йокла,— ди әнием.
— Нургали тәрзәсен
Мин ватып килием.

— Шаярма, улкаем,
Яздыңмы акылдан?..
Кыйнарга тал чыбык
Чыгарды чатлыктан.

* * *

Сазда ике селәүсен,
Атып алдым берәүсен.
Ыргытамын үләксә,
Этең миңа өрмәскә.

Күреп калдым күзләрен
Очып барган козгынның.
Синңа качып кергәндә
Читәнеңә кысылдым.

Буйдан-буйга ертылды
Селәүсеннең тиресе.
Сазда тагын берәүсе
Нигә мине тиргисең?

«Кеше-кара күрмәсен,
Сарбаем да өрмәсен».
Сине тыңлап торам да
Килми янә керәсем.

Сазда ялгыз селәүсен —
Төшләремә кермәсен.

* * *

*Шигырьдә «йолдызны»*
*күп кулланучыларга*

Җирдә йолдыз, күктә йолдыз,
Шигырьдә дә туп-тулы.
Йолдызларның буш ябышуы
Туйдырды ла, туйдырды.

Аяз көндә, баксам күккә.
Күңел сүнә, пошына:
Йолдызлары корчаңгы бит,—
Ай сыртына ышкыла.

# Кайгыларым бар-барын...

Бер саескан кунды да
Янымдагы каенга,
Кычкыра да кычкыра —
Каныкты бит җаныма.

Юмалый күк кайчакта:
Синнән юмарт юктыр, ди.
Миңа, тәмләп чукырга,
Берәр нәрсә ыргыт, ди.

И саескан, саескан,
Юк бирерлек бер нием.
Ач, ялангач үзем дә —
Бәхет эзләп йөримен.

Ә саескан аңламый —
Кычкыра да кычкыра.
Ачуланып, тузынып
Баш очыма утыра:

«Күкне чукып тишәрмен.
Җиргә яңгыр ишәрмен.
Атыңа да җитәрмен —
Чукып куып китермен.

Йокларга дип күз йомсаң,
Учагыңны туздырам.
Саранланып утырсаң,
Йотканыңны костырам».

И саескан, саескан,
Нишләргә дә белмимен.
Кай ярыкка керием —
Юк бирерлек бер нием.

Кайгыларым бар-барын...
Ничек бирим аларын,—
Үзең чакырып торганда
Тагын, өр-яңаларын?..

* * *

Картаела,
Картаям ла.
Күнегелде арырга.
Күңел тартмый
Акыл белән,
Хис белән шаярырга.

Маңгаемда җыерчыклар —
Кипкәнгәме йөз суым?..
Күрәм гади хәрәкәт дип
Бал кортының очуын.

Куркам аркан ыргытырга
Чапкан болан өстенә...
Йә ул мине өстерәп китәр,
Йә элер мөгезенә.

Төнлә йолдыз атылганда
Кинәт сүгенеп куям...
Тик торганда кемне сүгәм?
Үземнедер дип тоям.

* * *

Барып кайтып йөримен —
Киндерле дә Канчәбер.*
Кайный каен арада
Яфрак-чыбык чәчрәтеп.

Ява яңгыр, ява кар
Йөри торган юлыма.
Йә чәчәкләр, йә ылыс
Йолкып алам кулыма.

Егерме бер чакырым —
Канчәбердә бәгырем.
Барган шәпкә чәйнимен
Йә җиләген, йә әремен.

Кояш чыгып Тәүдедән**
Канчәбергә сыена.
Кояш белән нишләем,—
Бәгырем керсен куйныма.

* *Киндерле, Канчәбер* — күрше авыллар.
** *Тәүде* — елга исеме.

* * *

И табигать, бүген мин
Шаярмыйм, көлмим.
Борчылам: сине, ахры,
Ярата белмим.

Шуңадыр торышыңда
Көчәнеш тоям.
Миңа юнәлгәндер дип
Шикләнеп куям:

Әкренләпме, кинәтме —
Ничектер итеп,
Акылымны алырга
Телисең кебек.

# Урманнарга кабам

Кинәт кенә көнне яра
Ачы тавыш: «Урман яна!»

Бу яшенле кара хәбәр
Йөрәкләргә кереп шартлый.
Сикереп тора түшәгеннән
Үлеп яткан күрше карты.

Беркем кушмый җыелырга —
Кан боера! Җан боера!
Бөтен авыл кубарылып
Сүндерергә томырыла.

Күрше авыллар да килә,
Юл буенча сугып чаңны.
Бугазыннан буып алып,
Тураклыйбыз аждаһаны.

Булды хәлләр, булгалады —
Үлем дә уйнагалады.

Өскә агач аугалады,
Күзгә күмер төшкәләде.
Аяк-куллар, кызган тәннәр
Сөяккәчә пешкәләде.

Бабалардан калган урман —
Туган якның йөрәге бит!
Ансыз
Безнең йөрәкләрнең
Кешелеккә кирәге юк.

Без үскәндә ел саендыр
Урман тагын, тагын янды.
Без дә тагын! тагын! тагын!
Кубарылып суктык чаңны.

Быел кайтсам туган якка:
Чит теллеләр урманнарда
Наратларга, усакларга,
Каеннарга суга тамга.

Янгыннан да куркынычрак
Күзләренең йөгрүләре.
Сорыйм моңсу авылдаштан:
— Рөхсәт сорап керделәрме?

Авылдашлар күз яшерә:
«Нишлик инде... шундый заман».
Гарьлегемнән янгын булып
Тиздән урманнарга кабам.

# Бозны чукыма

Яз изү чишә
Урман артында.
Дулкыннар тынчый
Аяк астында.
Тукта, балыкчы,
Бозны чукыма.
Су анасын син
Бүген борчыма.
Эзләсен төптән
Алтын таракны...
Күзен төшереп
Югалтты аны.
Тарак табылса,
Бозлар арчылыр,
Кочагына җәй
Күлне качырыр.
Туйдырды кышның
Салкын карлары.
Урлыйсым килә
Алтын таракны.
Буласым килә
Яшел маңкалы,
Ялан аяклы
Тукай малае.

# Капкын ята аргы кырда

Капкын ята аргы кырда,
Төлке йөри бирге кырда...
Көнне ничек уздырырга?
Ымсынмый ла күңел җырга.
Бирге кырда казып, төлке
Шатлыгымны күммәк була.
Арт күрсәтеп, койрык болгап,
Миннән бераз көлмәк була.
Күңелемә ишеттерә
Аргы якның зәңгәр җиле:
Үзен миннән кызгандырып,
Гарьлегеннән капкын зеңли.
Капкын корып, төлке күреп,
Моңланамын инде менә.
Шатлык җырын җырлап кайттым
Кичә генә, кичә генә.
Бу кырларга, урманнарга
Тиздән мине керетмәсәләр,
Сине күрми, төлкекәем,
Аучы күңелем ничек яшәр?
Ята капкын аргы кырда,
Төлке эзе бирге кырда...
Төлке үзе кереп килә
Йөрәгемә — моңсу җырга.

# Туа ният

Бәйрәмчәрәк февральнең
Кояшлы бураннары.
Хисләремнең ташып чыга
Җилбәзәк булганнары.

Атлыгамын изү чишеп
Бураннар ышыгына.
Тапсам, хәтта чумыр идем
Аюлар куышына.

Онытыла төшә бераз
Язларны көтүләрем.
Куакта, кызыл түш булып,
Тирбәнә өметләрем.

Туа ният яшәмәскә
Бер көйгә, мыштым гына.
Телне тидерәсем килә
Кызыл түш томшыгына.

Февраль озак тынып торса,
Шикләнеп басам карга...
Ышанычым бетеп куя
Язларда шатлык барга.

## Карчык зары

И күл!
Син миндәен түгел.
Хәлең әле ярыйсы.
Суларың да болганмаган,
Төбең тирән, ахрысы.

Киңлегең бар
Рәхәтләнеп, тынып
Оеп алырга.
Куәтең бар,
Мөмкинлек бар
Айкап дулкынланырга.

Йөзеңдәге җыерчыгың —
Йөгрек җилләр эзе генә.
Яшелләнер саргылт ярың
Кергәндә язгы көнгә.

Миңа инде насыйп булмас
Ярга янә чыгарга.
Калган хәлем җитсә-җитәр
Чабакка бер чумарга.

И күл! Миңа җиңел түгел
Дулкыннарны тыңлавы.
Сиңа үпкәмне көчәйтә
Акчарлаклар елавы.

Гомер үтте. Алтын балык
Картыма тоттырмадың.

Без аулаган балыкларга
Алтыннар йоттырмадың.

Ярыңдагы наратларың
Язмышымны камады.
Бәхет бераз булгалады —
Якында чумгалады.

Җир йөрәге димме сине —
Тыпырчынган буласың.
Дулкыннарны миңа таба
Ниләр уйлап куасың?

Юк инде, юк! Суларыңа
Тылсым көчен теләмим.
Яшәрергә эчим дисәм,
Иелергә юк хәлем.

...И күл! Сине ничек итеп
Күзләремә сеңдерим.
Картым тегендә иң әүвәл
Синең хакта төпченер.

# Улыма

И улкаем,
Карыйм сиңа
Күзләремне уып:
Кай арада үсеп җиттең
Күз тиярдәй булып.

Заман — бозлавык чоры күк...
Җирнең йөзе тайгак.
Китик, әйдә, тотынышып,
Бер-беребезне саклап.

Тотыныйммы,
Тотыйммы дип,
Торасыңмы уйлап?
Шундый чагың:
Уйлан, улым,
Уйланалмый елак.

# *Чәчәк иснәсәм*

Кышкы җил, язгы җил
Бергә кушылды.
Хисләрен ташытып
Көртлек чыжылдый*.

Аланда, әйтерсең,
Алтын өермә —
Төлкеләр сөешеп
Ауный, йөгерә.

Каргалар парлашып
Чыбык күтәрә.
Тиеннәр парлашып
Койрык күтәрә.

Минем дә әле бит
Өмет сүнмәгән:
Сөешеп күрсәтәм,
Чәчәк иснәсәм.

* *Чыжылдый* — көртлек туй алдыннан «чуыж», «чыж» дигән авазлар чыгара.

* * *

Көн кояшлы, җилсез булса,
Үрмәкүчләр чатлык саен
Ау үрә.
Дерелдәгән көмеш җептә
Шатлык әз-мәз ялт-йолт итә,
Йөгерә.

Кая барма: шәһәр саен
Авыл саен күрәзәче,
Әүлия.
Тик берсе дә дөрес әйтми:
Нигә халык ыңгыраша,
Ил бөлә?

Хәзергә,
Көн яхшыруын
Үрмәкүчләр ишәюдән
Мин беләм;
Заманаың каралуын
Күрәзәче күбәюдән
Мин беләм.

# *Куркам җырларымнан*

И урманым, уйланасың,
Әллә хәлең кызганычмы?
Серләреңне миңа әйтмә —
Миңа әле ышаныч юк.

Күңелемдә шундый чак бит:
Җырлар куба, өерелә.
Кая анда синең сергә —
Тыныч чат юк үз серемә.

Серләремне җырларыма
Ялгатырга куркып торам;
Нишләрмен мин — серне җырлар
Туздырсалар пыран-заран.

# Заман агачлары

Давыл чыкса, агачкайлар
Бөгеләләр җиргәчә.
Табу кыен каты агач,
Бөгәм дисәң бөгәчә.

Башкачарак төшә җиргә
Агачлардан күләгә:
Гүя, кипкән күбәләкнең
Канатлары түшәлә.

Кая анда күләгәдә
Рәхәтлеккә чылану? —
Күңелемне били ят хис,
Түгел микән чиркану...

Үзгәрде шул, йомышанды
Агачлары заманның.
Бөгелмичә, шартлап сына
Торганнарын сагындым.

* * *

Елганы елга йота...
Чуртанны чуртан йота.
Янгынны янгын йота.
Буранны буран йота.

Тавышны тавыш йота.
Кырауны кырау йота.
Чыкларны чыклар йота.
Җырларны җырлар йота.

Карап-карап торам да
Кайчак, кайбер минутта
Тыныч кеше йөзе дә
Мине шундый куркыта.

## Буйсын язның җиләнә

Гамьсез тора карагай,
Селкенеп тә карамый,
Бөтен үе чуалган,
Ботакларга чорналган.

Иң очында суеры,
Миңа карый туп-туры.
Әллә чынлап «кит-кит» ди,
Әллә юри «көт-көт» ди.

И карагай, карт карагай,
Кырыс булма син алай.
Куркасыңмы балтамнан?
Мин картайдым — ега алмам.

Миңа җитә черек төп
Утырырга яз көтеп.
Сиңа килдем бу таңда
Гүләвеңне тыңларга.

Арт яктагы гөрләвең —
Минем яшьлек көннәрем.
Ал яктагы гүләвең —
Минем калган гомерем.

И карагай, карт карагай.
Иртә әле үләргә...
Өр-яңача гүләргә —
Буйсын язгы җилләргә.

Һаман уйда карагай —
Ник сабышмый юләргә?
Сыйпап үтә язгы җил —
Курка каты тиярргә.

* * *

Чак кына аңлый алсам мин
Үлән, агачлар телен,
Миңа ары яшәр өчен
Кешеләр кирәк түгел.

Җәнлекләре, кошы белән
Чак сөйләшәлсәм бүген.
Миңа ары яшәр өчен
Кешеләр кирәк түгел.

И табигать, үги балаң
Булып торам янәшә...
Син миннәнме, мин синнәнме —
Кайсыбыз соң читләшә.

Аңламасам да телеңне,
Шунсын тоя бит күңел:
Сиңа борын-борынгыдан
Кешеләр кирәк түгел.

# Аю хәлендә калам

Кайбер аюлар
сынган, каерылган агачларның
чыраларын кылтыратып
зеңгелдәтергә яраталар.

Карый аю агачка,
Карый аю күккә.
Бүген җаны «хуҗаның»
Мохтаҗ камиллеккә.

Кирәк җанга хиссият,
Кирәк моңлы көйләр.
Кайчан яшен наратны
Йомычкага теләр.

Җиләк-җимеш өлгерә.
Солыга — сөт керә.
Җанга гына азык юк —
Аю шуңа үкерә.

Кешеләр тыңлый куркып,
Мин тыңлыйм кызганып.
Үзем дә бит аю кук
Чын моңга сусадым.

# Уян!

И яшь егет, бик тә яшь егет,
Сиңа кайгыру килешми кебек.
Утырасың язында җебеп,
Елгага балтаң төшкән кебек.

Әллә йоклап яткан аюның
Ботын кашырга чамалыйсың?
Әллә куян тотып, тәпиен
Дагаларга мәл таба алмыйсың?

Уян!
Оя корган каргага
Кулың изәп караштыргала —
Һич юктан булыр бер танышың,
Күзен куанып каршыларга.

# Тагын улыма

Каракош үз баласын
«Әйдә оч» дип, оясыннан
Этеп төшерә.
Ә кеше үз баласы
Киткән чакта авырсына,
Сагыш кичерә.

Ач бүре үз баласын
(Авыру булса, хәлсез булса),
Буып үтерә.
Ә кеше әзер тора
Баласына үз йөрәген
Күчертергә.

* * *

Күл өстендә аккошкай —
Канатлары каралган,
Туган якка ашыккан
Нинди күктән, һавадан?

Күрмәмешкә салышыйк,
Канатларын ак диик.
Туган якның күлендә
Бераз шатлык саклыек.

Аккошкайның каурыен
Ышкыйм ап-ак каенга.
Каерыдагы кара тап
Кайгы өсти кайгыма.

* * *

Сибелешеп чумды суга
Чөрәгәй* бәбкәләре.
Гарьлегеннән яшь карчыга
Күл өстен бәргәләде.

Куанычлы кайнар яшькә
Буылдым да тереләдем —
Менә кемнәр саклый икән
Олы котын Себернең.

* *Чөрәгәй* — иң кечкенә кыр үрдәге.

* * *

Җырлый да белмим,
Бии дә белмим,
И туган җирем!
Аунап, тәгәрәп
Елый белүне
Күрсәтеп бирим.
Бөҗәк, еланнар
Чагып өлгерми —
Аста изелә...
Агу урнына
Үләннәр каны
Чәчри йөземә.
Аунап туям да,
Туфракны тырнап,
Җиргә капланам.
Умыртка җебе
Өзелгән бер зур
Корт булып калам.
Болытлар гына
Теләр-теләмәс
Сыйпый аркамнан:
Әйтерсең мине
Юандырырлык
Бу җирдә бүтән
Берни калмаган.

# Поши ите

Март башларында көрт өсте ката, болында йөрү кыенлаша, кайчак сыйраклары сөяккә тикле кырыла. Пошилар юлларга чыгалар. Мин малай чакта якташлар аларны күпләп аталар иде.

Аучы чалдун* юмартлыгы
Һәр өйгә дә керә иде:
Табада да, чиләктә дә,
Өстәлдә дә поши ите.

Сыйланырга мине кыстый
Олысы да, кечесе дә.
Сөяк таба, сөяк өстери
Этләре дә, мәчесе дә.

Итне алсам, рәхмәт әйтмим —
Мин ашарга кыенсынам.
Тәрәзәне йолкып алып
Поши башын тыгыр сыман.

«Бу канлы март кайчан узар»,—
Дип кайчак сүз ычкындырсам,
Булды мине яратмаган,
Булды колагымны борган.

* *Чалдун* — Себер татары (диалект).

Язга чыккач, бакча саен
Поши сөякләрен җыям.
Җилдән ясин укыттырып
Бер чокырга күмеп куям.

Поши ауган урыннарга
Үсеп чыга сары чәчәк.
Шул чәчәкне таптаганны
Яшен сугып үтерәчәк.

* * *

Тигәнәккә бәрелеп
Егылды да чикерткә,
Ак болытлар куркышып
Өелделәр бер читкә.

Качып чуртан тешеннән
Ярга чумды акбалык.
Елгыр елга сагайды
Агуыннан тукталып.

Җил очыртты уалап
Чикерткәнең канатын.
Ярда яткан балыкны
Пешекләде кайнар ком.

...Ай-яй көне матур! — дип,
Кеше-кара соклана.
Мин дә шулай соклансам,
Ни әйтерсең, Җир-ана?!

# Бер танышым зары

Болыт кая ага, күзләр кая бага —
Шул якларга китеп булмый һич.
Җаным, аһым тоя: мине бәйдә тыя
Күк артындагы бер олы көч.

Җепне чак тарткалый,
йә чак бушаткалый...
Муеныма оста бәйләгән.
Типкәннәре тибә, маңгаема тия —
Шулай бер тирәдә әйләнәм.

# Исерекбаш

Этең сөяк, имгәнгән
Исерек килеш типкәннән.
Ишек, чатлык кыйшайган,
Стеналар ыржайган.

Калган бары бер чыбык
Биек, ышык читәннән.
Калган бары бер чыра
Ит тураган бүкәннән.

Төтен, чыкса морҗаңнан,
Хәлсез, ятим күренә.
Кыенсына менәргә
Туган ягың үренә.

Кычытканнар котырып
Тәрәзәңә үреләә.
Бу дөньядан йортыңны
Яшерергә, күмергә.

— И бәндә! — берәү әйтер
Озатырга килгәндә:
— Бөгәрләнеп үлгән бу —
Моңа җәннәт нимәгә?

* * *

Күндәм бер колы мин Аллаһ Тәгаләнең,
Арта гына бара Аңа рәхмәтләрем.

Булдым бәби, булдым егет, булдым ир дә,
Инде менә тыйнак картлык хәбәр бирә.

Күпне югалтсам да сукмак яра-яра.
Югалтырлыкларым һаман арта бара.

Сәер канәгатьлек күңелемә каба:
Күпне югалтырлыгым балаларга кала!

* * *

Эт шикелле өрә беләм,
Карчыга күк күрә беләм.
Сезгә карап тора-тора —
Булып куйдым күзле бүкән.

Кызарырга яңагым бар.
Батканнарга саламым бар.
Сезне тыңлап, инде менә
Хәерчедән аласым бар.

Йөк атыдай тартыр чакта
Мең еланга вакланамын.
Сез нинди — мин дә бит шундый,—
Дип, күз йоммый акланамын.

* * *

Ерак качмый шатлык, мине ташласа —
Урманга йөгерә бакча аша.

Тыгыз куакларга сыртын сыдырта.
Саесканын кычкырырга котырта.

Чәчәк саен күбәләкне култыклый,
Җырчы кошның тамак астын кытыклый.

Һәм төшә дә салкын куышка,
Анда еламсырау булып тулыша.

* * *

Кайвакытта язмышым
Мине шундый утырта...
Усалрак булырга
Кемдер шулчак котырта.

Кермәсме, дип, усаллык,
Ашыйм пычак очыннан.
Куакларын сындырып,
Урманнарда кычкырам.

Каен тузын, кабызып,
Агым суда агызам.
Кызынып яткан еланга
Таяк белән «тамызам».

Әллә нишләп карыймын
Инҗми генә усаллык —
Һич югында, урамда
Йодрык селкеп узарлык.

# Кайсы чык авыр?

Эре чыклар
Чәкештеләр,
Кара-каршы
Әйтештеләр:

— Мин авыр, ди
Куак чыгы.
— Мин авыр, ди
Кыяк чыгы.
— Мин авыр, ди
Чирәм чыгы.
— Мин авыр, ди
Җикән чыгы.
— Мин авыр, ди
Чәчәк чыгы.
— Мин авыр, ди
Җиләк чыгы.

Шунда җил чак
Исеп куйды:
Бу чыкларның
Барсын койды.
Калды бер чык,
Бөртек кенә —
Йөрәк чыгы
Керфегемдә.
Шундый авыр —
Мине бөгә...
Бирсен Ходай
Түзем генә!

Белмим, кайчан
Очар, кибәр?..
Исеп карый
Төрле җилләр.

Куак чыгы!
Кыяк чыгы!
Чирәм чыгы!
Җикән чыгы!
Җиләк чыгы!
Чәчәк чыгы!
Таң атканда
Тулышканда
Керфегемә
Тамыгызчы.
Күз яшемне
Керфегемнән
Бүлешкәләп
Алыгызчы,
Һәм шуннан соң
Чәкешегез,
Кара-каршы
Әйтешегез.

# Үрдәккә

Һаваларда очканыңда
Шатлыгым бөртеге — син.
Камышларга качканыңда
Өметем бөртеге — син.

Җәен таңнар аттырганда
Сагаеп бакылдыйсың.
Безне — ерткыч кешеләрне
Һаман да ятсынмыйсың.

Күпме аттым — баш очымда
Һаман да әйләнәсең.
Әллә бабалардан калган
Берәр әманәтме син?!

# Кичен

Сагыш, борчу йотып
Арлы-бирле йөрим.
Болын җилен тоймыйм.
Аяк астын күрмим.
Бер аягым баскан
Каен җиләгенә.
Бер аягым баткан
Сыер тизәгенә.
Тартар сирәк-мирәк
Томшык сугып куя.
Кычкырмый ул бүген,
Ничектер ачу җыя.
Көндезге шау-шулар
Оеп булды томан.
Шул томан астыннан
Шайтан карый сыман.
Очты куркып бер кош
Томан кочагына.
Нәрсә пышылдый ул
Шайтан колагына?..
Шайтан, көлемсерәп,
Тыныч карый миңа;
Тели озын гомер
Авыр уйларыма.

* * *

Чыбылдык булып
Яңгыр эленде.
Соңга калдым дип,
Тешлим телемне.

Чыбылдык чите
Миңа җитмәде.
Нигә соң яңгыр
Миннән читләште?

Көн ни кыладыр
Яңгыр артында...
Үтеп карарга
Күңел тартыла.

Юк микән анда
Берәр могҗиза —
Күрми калам дип
Эчләрем кыза.

Миңа кагылгач
Яңгыр туктады.
Чыбылдык төшеп
Җирдә буталды.

Сулышны кысты
Шул ук көн, шәһәр.
Могҗиза да юк,
Кайда ул «каһәр».

Күкне бизәкли
Зиннәтле күпер,
Хәлемне белсәң
Йөрәгең чеметер.

Терәлгән күпер
Тынчу шәһәргә.
Шундый уңайлы
Элмәк эләргә.

## Сусар хәле көнләштерә

Сабый сусар, кызып уйнап, ерак китте.
Урманының читенә үк барып җитте.

Шунда кинәт, шаулап кайнап, яңгыр койды.
Сусар исен, нәзек эзен җирдән юды.

Арлы-бирле аптырашта йөрде җәнлек:
Оясына кайтыр инде ничек?

Ялгыз алмый үткер күзе кирәк эзне,
Абайламый сизгер борын кирәк исне.

Яшен яшьни, көн яктысын яңгыр юа.
Сусаркайны, кысып алып, курку буа.

И сусаркай, койрыгыңны тешләп торма.
Синең хәлең мине синнән көнләштерә.

Ничек миңа ис, эземне югалтырга?
Тели күңел азатлыкка олагырга.

# Озак кайтмый кайткач

Нинди күлдер?
Чуммый балык,
Үсми камыш, төнбоеклар.
Йөзми үрдәк, әллә курка
Чуртанга йотылудан.
Үземне дә сагалый күк
Үзем буйлы бер ач чуртан.
Куркам
Төпсез уйга китеп
Онытылып йомшанудан.
Авыр уйга, тойгыларга
Юк иде лә мохтаҗлыгым.
Җырлардык итеп,
Күңелне
Инде ничек итеп чистартырмын.
Кап-караңгы күлнең төбе,
Гүя вакыт туңып каткан.
Ә мин?
Терек су савытын
Ваткан адәм булып кайтам.
...Кайтып була авылыма
Башка яктан, урман яктан,—
Ничек качыйм урамнарда
Мине көткән сораулардан.

* * *

Тирә-ягым баткаклык —
Басып торам тумарда.
Селкенергә дә куркып,
Карыйм ерак суларга.

Күл өстендә буш каек,
Төбе иркен коп-коры:
Туры басып җырларлык,
Озын дога укырлык.

Чумышалар балыклар:
Алтын, көмеш төсләләр.
Кичә баткан бәхетне
Бик тырышып эзлиләр.

Җилләр кая качтылар,
Ни бетереп ялыкты?
Миңа таба балыклар
Куалмыйлар каекны.

Сазлык аша карыймын
Буш каекка, суларга.
Укыйм белгән догамны
Басып уйнак тумарга.

# Ят бию биегән

Яшь торна оча алмый,
Тилмерә үзәндә.
Тәпие чорналган
Энәле үләнгә.

Матур таң сызылып,
Җиләсләп атканда.
Нигә соң үләннәр
Әйләнде капканга?

— Яшь торна үссенеп
Ят бию биегән.
Томшыгы, масаеп,
Өскәрәк чөелгән.

Йөгерә ач төлке
Торнаны кабарга.
Алдарак мин чабам —
Коткарып калырга.

Үләннәр чытырдап
Тезимә сырыла,
Гүя ки, ни уйлап
Кайттың? дип сорыйлар.

Коткаргач торнаны
Аптырап торамын.
Үләндә сузылып
Аунарга куркамын.

Ятларның көенә
Биеп йөрмәсәм дә,
Масаеп борынны
Чөеп йөрмәсәм дә.

# *Тансыкка ук аттым*

Корыган чыршыны
Уклыкка дип ярдым.
Теземә салдым да
Нәзек ук шомарттым.

Кистем дә яшь шомырт,
Җәялек киптердем.
Тез терәп бөктем дә,
Шәп җәя киерттем.

Уңайлы тезләнеп
Очырттым угымны —
Хәйранга калдырып
Яшүсмер улымны.

— Искиткеч уенчык
Ясадың бит, әти.
— Бу — корал, бу — һөнәр,
Бабакаң өйрәтте.

Очты ук сызгырып,
Җилне дә чыйнатты...
Кай җиргә төшкәндер,
Күзләрем югалтты.

Чамалап бардым да
Үләнгә тезләндем.
Буялып, тырналып,
Угымны эзләдем.

Тезләнеп эзләргә
Чакырам улымны.
Сөйләнеп иелә:
— Тезләнми булмыймы?..

Тезләнсәң, улкаем,
Буласың җиргәрәк.
Кояш та, ай да бит
Тез кебек түгәрәк.

Бары тик кабатлыйм
Бабасы сүзләрен.
Әйткәли иде ул
Чылатып күзләрен.

Әйткәли иде ул
Тезенә утыртып,
Ясаган угымны
Кулыма тоттырып:

«Угыңны син атсаң,
Чит җирдән эзләмә.
Ни булмас, тик менә
Дошманга тезләнмә».

Мин сөйлим хисләнеп,
Ә улым тыңламый;
Кәефе кырылган,—
Угы бит югалды.

Улымның колагын
Борырга торамын —
Ясарга өйрәт! дип
Нигә ул сорамый?..

## Яр буенда

Яңгыр ява караеп,
Авыраеп, тураеп.
Яр буенда су да ком,
Кайда качып тораек?

Янәшәмдә яшь бичә,
Ятсынуы тоелмый.
Юеш күлмәк аркылы
Бар нимәсе мыймылдый.

Әйтәм аңа тураеп:
— Күрәсеңме: зур каек.
Икәү комга каплаек,
Аска кереп ятаек.

Бичә әйтә:
— Син, әкә,
Күккә генә карап тор.
Яңгыр суы шифалы:
Чәчләреңне каралтыр.

* * *

Ничәнче көн күкнең йөзе тоташ кара.
Болытларга арка ышкып бөркет ара.

Сезгә, җилләр, ачуларым арта бара —
Сыйпагандай кагыласыз агачларга.

Агач, яфрак селкетүдән нинди файда?!
Ник кумыйсыз болытларны? Кояш кайда?

Җәйне кырыс итәргәме исәбегез?
Чәчәкләргә серкә төртер юк хәлегез.

Кая анда мине этеп атлатырга.
Йә аяктан егып җиргә каплатырга.

...Шунда исеп куйса җилнең көчләрәге,
Көйри башлый өметемнең күмерләре.

Тоям сыман: алда көчле давыл поскан;
Куркып түгел, сикерергә сыртын кыскан.

* * *

Уятмыйм улымны
Урамга чыгарга —
Ар якта аланда
Бер күчкер кычкыра.

Улымның төшенә
Керәдер шатлыклар,
Күчкернең моңында
Рәнҗешләр, сагышлар.

Тыңлыйм да кошкайны
Үзәгем өзелә;
Тоз булып эри бит
Яшәүне сиземләү.

Ятимлек хисләре
Күңелдә мөлдери.
Шул бер ай астында
Туздырдым гомерне.

Шул бер күк астында
Кайсыдыр бабамның
Җанының, рухының
Язмышын кабатлыйм.

Күчкернең елавы
Сихерли аңымны.
Әллә ул иң моңлы
Бабамның җанымы?

И күчкер!*
Сине дә, мине дә
Телиләр сытарга.
Без икәү тыңлашып
Өйрәник чыдарга.

* *Күчкер* — кулик (саз кошы).

* * *

Аллам рәхмәтеннән иңгән
Тынлык туган түбәгемдә.
Ишетелә «кетер-кетер»
Кырмыска йөгергәне дә.

Күңелемә, сискәндереп,
Таныш түгел хисләр иңә.
И Тәңрем, чыра булып
Кадалганмын җир тәненә.

Җаным-тәнем белән тоям:
Сызлый җирнең яшел тәне;
Тыңлыйм сулкылдавын, күрәм
Ничек яшьләр яшергәнен.

Чыклар, эре-эре чыклар,
Яшьнәрләр күк, бәрелешсә.
Зәһәр тынлык — тыңлап торсаң,
Үз-үзеңә кадер төшә.

# Им-томнар гына

Бара торгач,
Килеп каптык.
Алдыбызда —
Чиксез сазлык.

Килешик без
Бергә-бергә
Түмгәкләрдә
Сикерергә.

Түмгәк бетсә,
Елый күрмик.
Камышлардан
Канат үрик.

Очмый калсак,
Сыгылмаек...
Торналарга
Салынаек.

Торналар да
Күтәрмәсә,
Уйлыйк бергә
Берәр нәрсә —

Рәтле нәрсә.
Уй тумаса,
Ут төртәек
Шушы сазга.

Кылтырамый
Ут төртәек —
Үзебезне
Көл итәек.

Майлы булыр
Безнең көлләр...
Яңа шытым
Гөрләп үсәр.

...Тилергән, дип
Әйтмә миңа;
Бу такмаклар —
Им-том гына.

* * *

Күзгә төн, аяз төн нигәдер
Мине ят итә.
Кермә дип
Йөземә, күземә
Чыбыклар төртә.

Төкрүгә охшатып чыпылдый
Балык чумышы.
Котын алыр күк кычкырып
Айның чыгышы.

Үле төс, шомлы төс, диимме —
Каен яктыра.
Күләгә төтенли, куркадыр
Җиргә ятырга.

И Аллам! Сагаеп яшәүдән
Туйдым, бик ардым!
Ишекне тырнаган этемне
Тышка чыгармыйм.

Йөрәгем түзәрме, ишетсәм
Этнең улавын.
Бар күзәнәкләремне киереп
Төнне куамын.

Бар тәнем изелгән пыяла
Кебек чытырдый.
Аяз күк, ыжгырып, аңымнан
Нәрсәдер сорый.

Сорауны аңламый.
Ничек соң җавап табырга?
Бөҗәккә әйләнеп кач икән
Берәр ярыкка.

## *Юк инде, юк...*

Нәүмизләнеп ялгызым
Табан балык чистартам.
Йөрәгемне чәнчетеп
Яр башына күз атам.

Кайтуымны ишетеп
Ул яныма килмәсме...
Учагымны терелтеп
Кыл казанны элмәсме...

Онытылып
Шулпага
Тозны артык салмасмы...
Күзгә керде дип төтен,
Йөзен сөртеп алмасмы...

Юк инде, юк... яныма
Килүчеләр күренми.
Сары сукмак күпереп
Гаепле кук дерелди.

Сүнәрбезме инде без
Әчтәгене әйтмичә...
Көз бик моңсу, бик кулай
Аңлашырга дәшмичә.

Көз торышын сагайта
Юеш утын чыйнавы,—
Ишетелә шикелле
Үткән гомер елавы.

Балык төшеп кулымнан
Тыпырчына үләндә...
Ул да тели шикелле
Сине күреп үләргә.

## Кайбер чакта төннәрдә

Биргән Ходай чыдам:
Төнне тыңлап чыгам.
Төнге ачы җилләр
Тиккә исми, диләр.

Елый кайсы еллар?..
Нинди хыял, уйлар?..
Төнге ачы җилләр
Тиккә исми, диләр.

Кемне нәрсә кыстый?
Кемнең җаны сыктый?
Төнге ачы җилләр
Тиккә исми, диләр.

Яңгырар кебек булмәм —
Булып ачы сөрән.
Көзге ачы җилләр
Тиккә исми, диләр.

Иртән тышка карыйм.
Карыйм да, аптырыйм:
Нигә шулай күрше
Җыйган бик күп кеше?..

Әллә таза ирләр,
Әллә ачы җилләр:
— Тагын бер яшьтәшең
Төнлә үлде,— диләр.

И яшьтәшем, яшьтәш,
Түгел идең юләр...
Шунда миңа керсәң,
Алмас иде җилләр.

Күзге ачы җилләр
Саташтыра төнлә.
Миңа керер кемнәр,
Мин дә керим кемгә?

# Комсыз

Балык тота, җиләк җыя,
Төлке аулый, поши ата;
Табигатьне тәмләп имеп
Рәхәтләнеп яшәп ята.

Күзен йомып таба, белә:
Кайда күп тә, кайда эре.
Канәгатьлек тантанасын
Эчтән генә көйләп йөри.

...Белә тагы якташ мине,
Минем урман яратканны.
Шуңа тели Аллабыздан
Авылыма кайтмавымны.

## *Кемгә икәнен үзе белә*

Елгыр атлар кура саен,
Ат карагы булалмаем.
Бичәм ята чәчем сыйпап —
Сиңа барып куналмаем.

Алка итеп, йөзек итеп
Күрәм төннең алтын аен.
Бичәм ята аңа карап —
Сиңа бүләк италмаем.

Белмим мине нием тарта?
Әллә җаның, әллә каның?
Бичәм ята ирнен тешләп,
Сине уйлап куйган саен.

# Мин бүген хан

Елга читләре
Ката торган чак.
Чуртан сайлыкка
Ята торган чак.

Көймә борнына
Учак асабыз.
Төнгә ышкылып
Түбән агабыз.

Учак яктырта
Балык дөньясын...
Җәннәттер бу дип
Уйлап куясың.

Анда да чуртан,
Монда да чуртан...
И туган ягым,
Бүген мин — зур хан.

Теләсәм: чәнчим.
Теләсәм: җәллим.
Теләсәм: төртәм,
Уйнап үткәлим.

Чуртан күзләре
Җемелдәп куя.
Тәнем, йөрәгем
Чемердәп куя.

Һәм күрәм шунда
Бүрәнәдәйне!
Чәнечке сабы
Йолкый гәүдәмне...

...Тынам, суынам.
Берни котыртмый.
Йолдыз күплектән
Күгем чытырдый.

Канәгатьләнеп
Сүрелә учак.
Чынлык хыялны
Юмалаган чак.

Аяз, яңрау төн.
Көймәдә чуртан.
Бөтен Себергә
Мин — бердәнбер хан!

# Шик

Карчыганың күзе,
Тырнагы үткер —
Тычкан чыйнавыннан
Ярылды туң җир.

Телгәләнгән яфрак
Төште һавадан —
Тычкан тырнагыннан
Ычкынып калалган.

Иртән чыккан чакта
Җырлардык идем.
Күпме «хәерле юл!»
Ишетеп киттем.

Инде басып торам
Туң агач төсле.
Нигә соң бу ярык
Юлымны өзде.

...И шик! Хәвефле шик,
Туар идеңме,
Китсәм туган яктан
Йомып күземне.

# И бөҗәк!

Кырмыска оясы йом-йомык.
Өстендә суыклык, боеклык.

Әрсез җил керде дә кысылды,
Туздыра өелгән ылысны.

Тукта, җил, ояны актарма...
Ышаныйк без анда җан барга!

Уятмыйк шикләрне, хәтерне.
Яз әйтер: оямы, каберме?

Хәзергә, кичекми, кыш китер.
Кар өеп ояны тау иттер.

Өметнең үләсе бик килми.
Шул тауга чумырга ул тели.

Кырмыска тәненә сыенып,
Ятмакчы язгача җылынып.

Тукта, җил, көчәнеп сызгырма!
Казынып ояны туздырма!

И бөҗәк — кырмыска, кырмыска!
Ни көтә безләрне бу кышта?

# Ишарә

Күрдем кызык каргасын
Туган якның, кайткачтын.
Баш өстендә әйләнде
Кашып түшен, канатын.

Кыланышын карганың
Ишарә дип аңладым.
Дулкынланып, оялып,
Як-ягыма карандым.

Ишарәле шикелле
Калкыган корсагыма.
Еракларга очалмаган
Кыюсыз җырларыма.

Рәхмәт инде, мең рәхмәт
Карганың акылына —
Каркылдамыйча гына
Каршылый алуына.

## «Кырт» тешләп куя

Поши галәмгә
Танавын суза...
Охшый йолдызлар
Сибелгән тозга.
Яларга теләп,
Телен уйната.
Түземсезләнеп
Коерыгын ата.
Тоз коелсын дип,
Җиргә типкәли.
Биек наратка
Мөгез төрткәли.
Авыр тояктан
Җир тетрәп куя.
Биек наратлар
Зеңгелдәп куя.
Авылда этләр
Өргәләп куя.
Чөйдәге мылтык
Тирбәлеп куя.
Йолдыз атыла,
Күк йөзен кыя.
Тел очын поши
«Кырт» тешләп куя.

* * *

Актарамын урманнарны туган якта:
Минем хыял — төлке тун да, төлке яка.

Сабый чакта каннарыма калган сеңеп:
Төлкедән дә кыйбат, матур юктыр кебек.

Күпме йөреп, өметсезлек салынганда,
Бер төлкесе килеп басты минем алга.

Җирне тырнап, төкрек чәчеп шыңшый, өрә.
Борыныма костырырлык исе керә.

Үзе аксак, тоташ кутыр, корчаңгыдыр...
Кая ату? — Карарга да чиркандыра.

Өнсез калып тирә-юньгә күз саламын,
Урманны да, үземне дә кызганамын.

Иң кызганыч бәндәсе мин бу заманның —
Канга сеңгән хыялымнан чирканамын.

* * *

Юк, төнлә урманда
Беркем дә атмады —
Бер капкан ачудан
Гарьлектән шартлады.

Кыш буе көтеп тә
Берни дә басмады.
Әйләнә-тирәгә
Бер эз дә ятмады.

Чыжылдап атылды
Һавада йолдызчык...
Әллә ул капканнан
Атылган кыйпылчык?..

Карурман тынды да
Төрле шик кузгатты.
Гүя ул — куләгә,—
Өрәкләр зираты.

* * *

Кайның печән, кайның капкан,
Кайның бергә казанда.
Печән йотар тимер исен —
Төлке борнын алдарга.

Кайның аңым, кайның җырым
Беттек диган заманда.
Кайсы кайсын йотар икән
Язмышымны алдарга.

Тели күңел хисләремнең
Акылымны йотуын.
Капканнарга капканыңны
Белеп яшәү — ай, кыен...

# Мине каргама

Булды без малай чакларда
Шундый вакытлар:
Чоланга ятып агайлар
Үрдәк аттылар.
Үрдәкне агай ата да —
Алалмый аптырый...
Ничек керәсең бакчага
Батканда каурый?..
Ә мин батсам да, чумсам да
Барыбер керәм.
Буямый-нитми үрдәкне
Китереп бирәм.
Агайлар сыйпый башымнан,
Мылтык тоттыра...
Җанымны чөеп күккәчә,
Шатлык котыра.
Шома, ялтырак түтәгә
Ышкыйм йөземне.
Дөньяның хуҗасы итеп
Тоям үземне.
Каргалар, канат ерттырып,
Авылдан сыза.
Усал эт, сыртын сындырып,
Койрыгын кыса.
Капка төбендә күрше кыз
Чәчен төзәтә.
Көнчел малайлар өйгәчә
Мине озата.
Манма чыланып, соң калып
Кайтам өемә.

Төя башымны әнием,
Әти сүгенә.
Ачынып, төнлә бакчада
Үрдәк бакылдый.
Дерелди өйнең стенасы,
Нидер шакылдый...
Гүя үрдәк кат-кат килеп
Чукый ишекне.
Йокыга китсәм, күзләрне
Чукыр шикелле.
Куркудан идән астына
Качмакчы булам.
Кычкырып, урамга чыгып
Чапмакчы булам.
Төн буе үрдәккәй мине
каргый да каргый.
Еламсырап, үпкәмне аңа
Белдереп карыйм:
— Мин мылтыкны бары тотып
Кына карадым.
Ә мылтыгы да бит әле
Күрше агайның...

* * *

Йокы керми күзләремә,
Дөрес типми йөрәгем,—
Офыктагы кояшны
Өрәк итеп күрәмен.

Өрәк, чәчен тузгытып,
Тәрәзәгә каплана...
Нигә миңа каныга,
Ник ошамыйм мин аңа?

Беркемнең дә берниен
Урлап тотмыйм, яшермим...
Булса алтын-көмешем,
Таратырга әзер мин.

Бераүгә дә янамыйм,
Бераүне дә әрләмим.
Чишмим-түкмим ятларга
Дусларымның серләрен.

Үрмәкүчнең ятьмәсе
Бер чатлыкта бәреләә.
Акрын гына шуышып
Баш очыма ул килә.

Кем белә? — чебен булып
Күренәмдер өрәккә...
Санамыйдыр ул мине
Бу заманга кирәккә.

Битарафмы? Миңгерәүме? —
Ятагымда мин ятам.
Этме? Минме? Өрәкме?
Бусагамны чылаткан.

* * *

Күзнең сизгер болытлары
Курыккандай агалар.
Баш очымда, карылдашып,
Талашалар каргалар.

Исем китеп карап торам
Каргаларның көченә.
Йодрык кадәр ит кисәге
Күк йөзенә чөелә.

...Ит кисәге тырнакларда
Менеп китте югары.
Карга өере ерак китеп
Зәңгәрлектә югалды.

Нәрсәгә юрыйм икән бу
Тамашасын күземнең?..
Дерелдәгән кулым белән
Йөрәгемне эзлимен.

Аллага шөкер, йөрәгем
Үз урынында әлегә.
Кайтса комсыз кара кошлар,
Кайтсын берәм-берәм генә.

* * *

Талгынлыкмы? Нидер коя кышның күге.
Төп өстендә йокымсырый сукыр өге.

Булыр икән төлкенең дә сабырлыгы —
Йөгерттерә тычканнарны арлы-бирле.

Чәүкә кунган карт пошиның җилкәсенә.
Тукран тыныч — тими көннең теңкәсенә.

Яшел бәрхет булып күпчи усак кабы.
Тәннәремә, канга тәмле ою капты.

Авыр сүз ишетмәс бүген Себер кышы —
Үзен безгә охшатырга тырышуы.

Карга ятып җәнлек ауный, кош коена.
Күңелемә моңга охшаш түл җыела.

# Бөкре имән

Бөкре имән актан киенгән,
Карлы кыр өстенә иелгән.

Гүя сука тоткан кулына,
Кырны сукаламакчы ул була.

Килеп җитте буран тиз генә,
Сипте ак ком имән күзенә.

Имән айкалды да чайкалды:
Тураймады — һаман шул калды.

Таңда пошы килеп ышкыла.
Йоклый сусар төшеп куышына.

Ботакларга җилләр кысыла.
Чыбыкларда песнәк сызгыра.

Ә имәннең исе китми бернигә —
Һаман сабан тотарга дип иелә.

* * *

Туңуданмы, куркуданмы дерелди.
Кайдалыгын әллә аңлап бетерми?

Куркам өзәргә дип, якын килергә:
Яшен яралгысы булып күренә.

Озаграк карап торсам үзенә,
Шундый моңлы, ятим булып күренә.

Язгы хис юк — шик биләде күңелемне:
Сыңар күзле өрәк карый түгелме?

Карның әле эрисе дә эрисе,
Бәхеткәме шыттың талның бөресе?

* * *

Язмышымның ярында
Тукталып торамын.
Тыпырчындырып каекны,
Сагызын кырамын.

Каегымның агымына
Юк иде бер зарым.
Бары тик шик булганга
Сагызын кырамын.

Кыргачтын каекта
Ыржая зур ярык,—
Котырынган дулкынның
Тел очы сыярлык.

Инде менә җил тарыйм,
Көлтәләп угычлыйм.
Иң елагын сайлыйм да
Ярыкка дыңгычлыйм.

* * *

Төкрә кояш бу заманга —
Чыртлап, чәчрәп балкып тора.
Тирә-юньнең шыксызлыгы
Еракларга яктыртыла.

Ошламамы,* нидер кайчак
Акылымнан кысып тота.
Мылтыгымны төбәр өчен
Күзем йөгерә — эзли нокта.

Күзем йөгерә — үзе курка
Нокталарга абынырга.
Кояш калка, кояш бата,—
Сукыраям акрын гына.

* *Ошлама* (диалект.) — белая горячка.

## Авылдаш хатынга

Саз буенда агуын*—
Чия чуку уенда.
Яуган карлар, ай, тирән —
Якынаю кыен ла.

Якынаю кыен ла
Агуынны атарга.
Дәшер иттем үзеңне
Кыргый итне татырга.

Каерыр идек ядәч тә
Кара-каршы утырып.
Күрер идем күңлеңне
Ирмәк** өчен оттырып.

Саз буенда агуын —
Хәлләремне белмәйте.
Көртләр аша яныма
Ирмәк өчен килмәйте.

Агуында тән эссе —
Карын көртнең эретә.
Икәү бергә шул кошны
Ничек авыз итәргә?..

Карлар ява котырып
Агуынны күммәгә.
Ата алмасам ядәчлек —
Язлар безгә нимәгә?

* *Агуын* — кыр тавыгы.
** *Ирмәк* — кызык.

* * *

Чыкты буран, гүя акбүз
Атлар өерелеп аунап алды.
Күбекләнгән сыртларыннан
Ап-ак чыпталары төшеп калды.

Шатланырга иде дә бит,
Мин эчемдә борчу абайладым:
Карны түгел — таптыйм кебек
Мәңгелекнең юка ямаулыгын.

* * *

Мин ятканда аю үткән,
Өстемә ташланмаган.
Әллә инде ерткыч мине
Кешегә санамаган?

Җирне ертып, сызып барган
Хуҗаның тырнаклары.
Шомлы эзгә тыныч карыйм —
Йөрәгем уйнакламый.

Җилләр арттан этеп карый,
Бу эзләргә тезлән, дип.
Юк, тезләнмим — миңа хәзер
Ике дөнья — бер кәнди.

Еракларда үкерешеп
Килсен шунда мең аю...
Миңгерәүлек чорында мин —
Уйларымда юк таю.

## *Чалдун теле*

Юк. Көлкеле, мескен түгел
Чалдун анамның теле.
Ул бит татар телебезнең
Иң серле, моңлы күле.

Ничек аны сай дип әйтим —
Төбенә җиткәнем юк.
Ничек аны тар дип әйтим,—
Ярыннан үткәнем юк.

Кайтсам — аның бәбкәсе мин,—
Туп-туры чумам, йөзәм.
Табигатькә, борынгылыкка
Якынаюны сизәм.

Эчәм, эчәм — эчкән саен
Сусавым арта бара.
Күзләр, йөзем, күкрәкләрем
Монда күпчеп кабара.

Тыңлап телнең яңгырашын
Тәмләп елап аламын.
Фәрештәләр монда гына
Чайкыйлардыр тамагын.

...Ничек мескен булсын
Теле чалдун анамның.
Кул корыса Себеремдә,
Сүнәр теле татарның.

* * *

Алла бирсә бирер икән:
Йөзе шундый сөйкемле!
Йөрәккәем келт-келт итә,
Кәлтә теле шикелле.

Кашларына эленгән дә
Төтенләнә җен-пәри.
Тәннәремне чемердәтә
Атлавының җилләре.

Аһ! Наз сиптермәсе икән —
Миңа туры сиптерә.
Ничек кенә кагылмыйча,
Чыланмыйча үтәргә.

...Ярый әле абайладым:
Барам икән ияреп.
Харап итә язган мине
Татлы, серле юләрлек.

# Талчитән

Калкулыкта талчитән
Бөкрәеп тора иде.
Курыкмыйча, ай төшеп
Ияген кыра иде.

Ай янына читәнгә
Менеп атлана идем.
Ул авыша читкәрәк —
Миннән саклана иде.

Ә нигә борчылмаска? —
Чәчен тарткалый идем.
Барабан итеп күреп
Кыйный, каккалый идем.

Читәндә хыяллану
Шундый уңайлы иде.
Булганмын юньсез — айга
Төкреп куйгалый идем.

Хыялларым күплектән
Читән дерелди иде.
Ай теге яктан, ә мин
Бу яктан тери идек.

Безгә сиздерми генә
Җиргә сыгылды читән.
Бөҗәк зырылдый дидек...
Вакыт кимергән икән.

...Кайда читән, балачак?
Бәлки ай шаяргандыр...
Юри генә күтәреп
Үз кырына алгандыр.

Читән мине биектән
Көткәндер дә көткәндер.
Зарыгудан ай комына
Әверелеп беткәндер.

Ләкин ай да сагышлы
Минем белән бермә-бер.
Талчитәнгә аның да
Ышкыласы киләдер.

# Суган арчыганда уйлану

Кайчак язмышым,
Кеше-каралар
Миннән шундый оятсыз көлә! —
Башым тиресен
Арттан сыдырып
Үз йөземә
Каплыйсым килә.

Әмма дусларым,
Таныш-белешләр
Минем кыргыйлыктан
курыкмыйлар.
Чөнки тормышта,
Үземне арчып, яшь агызырлык
Урыным бар.

## Ничек томан аша үтәргә?

Сынып төшкән ботакларны
Кадыйм юеш җырларга.
Бәлки алар тамырланыр,
Бөреләнер иртәгә?..

Аңлы көчме, аңсызымы —
Куерттыра томанны.
Күрмим барган сукмагымны,
Баш бәрәсе коймамны.

Әрле-бирле йөрим дә мин,
Капшап, җиргә утырам.
Кадап киткән ботакларны
Күрми басып сындырам.

Шунда чыртлый миемдә шик:
Әллә инде ботаклар
Бу томанны җибәрмичә
Итәгеннән тоталар?

Миндәй йомшак күңелләләр
Бу дөньяда сирәктер:
Сынганнарны үз файдаңа
Кулланырга кирәктер.

Ботакларны кулга алып
Селтәргә дә селтәргә.
Селти-селти, төртә-төртә
Томан аша үтәргә.

...Ә томан һаман куера —
Кузгалмыйча торамын.
Күзләремне ботакларга
Төртермен дип куркамын.

## Кабан күленә

Күңелсезләтеп көннәрне,
Көмеш төскә төренгәнсең.
Шомарып, ышкылып беткән
Тәңкә булып күренәсең.

* * *

Карагайга кара кантар —
Козгын баскан.
Тырнаклары ботакларга
Тирән баткан.

Горур түше ялт-йолт итә
Күзгә сыман.
Әллә шушы елтыраудан
Көн суынган.

Ята алда кап-кара җир —
Сукаланган.
Козгын күзли, кырда аның
Ние калган?

Кычкырамын чәчүчегә:
— Чәчми тор ла...
Козгын күзе тиеп куяр
Орлыгыңа.

Ә чәчүче — сүзсез, кырыс —
Чәчә бирә.
Эте, никтер, кошка түгел,
Миңа өрә.

Козгын миннән җирәнгәндәй
Башын бора.
Кап-кара каурыен йолкып,
Ташлый кырга.

Каурый оча, мин ыргылам
Аңа таба,—
Төшермәскә, күмдермәскә
Буразнага.

...Әле һаман да мин йөгерәм
Аңа таба.
И Ходаем, зинһар мине
Абындырма!

## Тешне кысып куйгалыйм

Кысылгангамы ярыкка,
Теш шыгырдата яфрак.
Ертып, уып ташлар идем,
Шыгырдатса катырак.

Тешем кысмыйм, шыгырдатмыйм —
Ярый әле бар түзем.
Тыныч кына үз җаена
Үтсен әле бу көзем.

Ә көз балкый. Алтын төстән
Буыннарым калтырый.
Күл төбеннән иң тирәннән
Чуртан күзе ялтырый.

Баш очымда тукталышып,
Уйланыша торналар.
Әллә миңа моңлы быргы
Калдырмакчы булалар.

«Картайдың син, корыдың»,— дип,
Кызганалар шикелле.
Юк, кирәкми быргылары —
Күңелемә килешми.

Торна күзе ничек күрми? —
Туры басып кул болгыйм.
Әле кышның күп төлкесен
Аулармын дип тә уйлыйм.

...Сизми торам: тешләремне
Каты кысып куйганмын.
И Ходаем, теш кысудан
Оеп ләззәт тоямын.

* * *

Әнә карга: «Кар, кар!— ди,—
Карап торма, кайт, бар»,— ди.

Әнә көртлек: «Келт-келт,— ди,—
Керә күрмә, кит, кит»,— ди.

Әнә кошчык: «Чык, чык,— ди,—
Чытырманнан чык, чык!» — ди.

Әнә тукран: «Тук-тук,— ди,—
Тукта! Сукмак юк, юк»,— ди.

Менә шулай, улкаем,
Кош теле ул — бик ансат.
Аны бик шәп аңлыйсың,
Табигатьне яратсаң.

* * *

Калып томан асларында
Усаллыгым кысылды.
Күпме җырның сагаюдан
Көе, моңы бозылды.

Эре бүре көтүләре
Кайчан кырда күренер...
Җае чыгып эчеп куйсам
Сөтен ана бүренең:

Үзгәрмәсме тавышларым,
Очланмасмы тешләрем?..
Күзләремә ут капмасмы
Томаннарны тишәрлек.

Бүре миңа аулатырмы,
Шул турыда уйлау юк...
Шунсы ярый: томанлыкта
Сагаю бар, елау юк.

* * *

Мылтыгыңны астың,
Чаңгыларга бастың;
Кай якларга таба
Шудың япа-ялгызың.

Атыргамы төлке?
Егаргамы поши?
Кемең бик котыртты,
Нинди җенең кушты?

Юкмы мал-мөлкәтең,
Әзме гөнаһларың?
Сунардашың итеп
Нинди җырны алдың?

Үттең мине күрми,
Күңелемне кырып.
Сиңа хушрак шул
Чаңгыларың җыры.

Нәүмизләнеп читтә
Калды җырчы җаным.
Үрти, көнләштерә
Җыры чаңгыларның.

* * *

Яшь наратка ни булган?
Җәй башында саргая.
Җирәнәме мәңгелек
Бу якларга карарга?

Учлап-учлап җәйге җил
Саргылт кылчык ыргыта.
Зырылдавы ылысның
Кош-кортларны куркыта.

Көчәергә тора күк
Гаделсезлек балкышы.
Янәшәдә агачлар
Күрмәмешкә салышты.

Аһ, нинди чарасызлык,
Ярдәмсезлек болгана...
Табынганмын икән мин
Менә нинди дөньяга.

...Тукран килеп өлгергән,
Тыңлый нарат йөрәген.
Миңа инде барыбер дип,
Бичарага терәлдем.

* * *

Үлән изеп ятуымны бик хуш күрәм,—
Эреп йокы кочагында бер төш күрәм.

Имеш: каным шарлап ага — тиздән үләм,
Җыелганнар як-ягыма төрле үлән.

Кычытканы, тигәнәге, әрем, билчән —
Күбесенең исемнәрен белмим икән.

Борчылалар: «Бу кешебез тиздән үләр.
Каныбызны бирик аңа тизрәк»,— диләр.

Үләнкәйләр берсен-берсе этә-төртә,
Чәчәге дә, чүп үлән дә чират көтә.

Шунда ачы кычкырмасмы бер карт үлән...
Очы сынган, тапталган ул — күпне күргән.

— И ахмаклар, кан бирмәгез, үлсен тизрәк.
Безнең тәнгә, тамырларга чермә кирәк.

Ятса адәм сөякләре күпләп, таулап,—
Без үсәрбез, кардәшләрем, күпләп, шаулап.

Үлән, ярсып, бугазымны буа башлый.
Яткан җирдән куптарылып торып бастым.

Күзләремне акайттырды сәер курку,
Кылтырап куйды җир шарының яшел сырты.

Өр-яңадан тудым кебек бу дөньяга:
Үләннәргә карыйм да мин яшем ага.

Нигә елыйм?
Чын шагыйрьлек килдеме әллә?
Җәза булып каннарыма сеңде мәллә?

* * *

Давыл җуймый хәтәрлеген,
Юнәлешен борса да.
Козгын мине күздә тота,
Арты белән торса да.

Синең хакта уйлаганда
Гомрем тизрәк кыскара.
Биек күпер башларында
Якынаерга кыстама.

## *Кабан буенда*

Кичә тирәк бар иде
Ышыкланып торырлык.
Камышлар да бар иде
Үрдәк оя корырлык.

Ярда зәгыйфь яшеллек —
Кеше чәчкән чирәмлек.
Карга курка төшәргә,
Очып үтә читләтеп.

Дулкыннарны хәлсезли
Авыр, куе сабырлык.
Ә бит минем хәлләрем —
Күл өстеннән чабарлык.

Качып кайсы җирләргә
Елыйм да мин уйланыйм?..
Сизгер Мәгънә Кабанда
Инде якмас учагын.

Мин аңламыйм, и Казан,
Ни кылды соң куркырлык
Кабандагы ятим күзле,
Хәлсез, моңсу кыргыйлык?

* * *

«Каурыйларын коя-коя оча кошлар»
*(Танылган Казан шагыйре шигыреннән)*

Каурыйлары коелган кош
Ничек оча ала икән?
Һавадагы биеклеккә
Ничек чыга ала икән?

Каурыйлары коелса, кош
Мәтәлеп төшә иде.
Канат төбен чукый-чукый,
Түшкәен тишә иде.

...И Казаным, күп җырларың
Сагайта, ышандырмый.
Күңелемне бушандырмый
Чыкларга чыландырмый.

Күгеңне күптән күзәтәм:
Ник коелсын каурыйлар?!
Нигә соң? Нигә җырларым
Күккә куркып карыйлар?

# *Яртыясак**

«Казанлы үтсә, күлләр кибә»
*(Себердә шундыйрак әйтем бар.)*

Күлне иләк иттек,
Бозын тишә-тишә.
Сынды сөмән, көрәк —
Сынды әллә ничә.
Сөмән бозны тырный,
Уйдан башлар ката:
«Балык нигә кача?
Кайсы төптә ята?»
— Кемнәр гөнаһлы?— дип,
Уйламыйча булмый.
Куак артларында
Буран җиле улый...
Кайберәүләр миңа
Кырын карап куя...
Казан каласында
Коргангадыр оя.
Юк, мин кыенсынмыйм —
Бозны тишә бирәм.
Күлгә тир тамызып,
Суын эчә бирәм.
Кырын карашларга
Мин күнеккән инде.
Алар Казанда да
Сыный күптән мине.

---

* *Яртыясак* — әти-әниләренең берсе Себер татары, икенчесе Казан татары булган кеше.

Үз көемне көйләп,
Беркатлана бирәм.
Күзләр сай булса да,
Күңел ай-яй тирән.
Бәлки ялгыздыр мин,
Бәлки үгидер мин.
Моң-хасиятемне
Аңлап бетермимен.
Бозны тишә-тишә
Күлне иләк иттек.
Күп балыкны эзләп
Башка күлгә киттек.
Әйтәм агайларга
Иренемне тешләп:
Китим... мин булмасам,
Балык эләгер шәт.
— Китә бир,— дип миңа
Әйтми беркеме дә.
Шатлык оптылары
Уйный күңелемдә.
Рәхмәт, туганнарым!
Минем чалдуннарым!
Миң кат көчем артып —
Бозга сөмән кадыйм.

* * *

«Кинәт кенә кубарылып давыл чыкса,
Өсләремә тау-таш ишсә, агач екса...
Кинәт җир ярылып мине упкын тартса,
Кемдер мине бутап миңа ялгыш атса»,—

Шундый уйлар көпә-көндез кайбер чакта,
Капылт килеп, миләремне үтә чага.
И Алла! — дип ыңгырашып әйтеп куям,
Шундук куркып телем тешлим, авыз йомам.

Белмим, бармы хакым Аңа эндәшергә,
Башкаемны ничек иим тезләнергә;
Карап күкнең кай читендә, кай ягына,
Саклый күр дип, ымсынырга, ялварырга.

Биле сынган җәнлек кебек карыйм күккә:
Охшаган ул йокымсыраган зәңгәр күзгә.
Юк, Аллабыз булмас безнең сыңар күзле,
Теге дөньяны күзлидер икенчесе.



# ҖИЛГӘ МОҢ ДЫҢГЫЧЛЫЙМ



## Хәзинә

Камышка камыш ышкыла,
Җилсез-нисез ышкыла.
Әйтерсең яшеренеп яткан
Ат табуны пошкыра.

Шып туктый кайчак очкан кош —
Гүя укка сугыла.
Тозак кылыдай кылтырап
Кояш нуры суына.

Сизә күңелем, әй, сизә:
Ята монда хәзинә.
Күчүмнеңме? Кайсы ханның?
Әйтә алмыйм хәзергә.

Сизсәм дә кайда ятканын,
Теләмим кагылырга.
Иректән мәхрүм халыкның
Ирексез алтыны да.

# Күңел елый

Тәүде, Тубыл, Тура, Иртеш ярларында
Учак ягып бераз ятканым бар.
Дулкыннардан, камышлардан, яфраклардан
Ишеттем мин бер үк ачы моң-зар.

Гарьлегемнән туфрак чәйнәп, йөрәк кысып,
Ярларында корттай бөгәрләндем.
Куе томан эчләреннән олы көчме,
Нидер көтә-көтә юләрләндем.

Газиз халкым язмышының шаһите — ай
Ник елмайсын шунда юри генә.
Боекланган, моңсуланган буйсынып ул
Ачы хакыйкатьнең ирегенә.

Учагымның очкыннары югарыга
Талпына да менми — чыртлап сүнә.
Карый белсәң: күк йөзендә — акылсызлык!!!
Гөрли, ыжгыра ул — ничек кенә!

Моң-зарларны тыңлыйм да мин, күңел елый:
Ия түгелмен күк үз-үземә.
Дан җырларга гына кала Себер
Татарның мәэюз түземенә.

Тәүде, Тубыл, Тура, Иртеш ярларында
Учак ягып бераз ятканым бар.
Сүлпән булды, ахры, учакларым —
Өермәләр килеп капмадылар.

# Ни диим?

Шаулыйлар карт таллар, шатланып,
Күчүмнең кайтуы турында.
Шаулыйлар дулкыннар, елашып,
Ермакның батуы турында.

Тик урман болганмый — куйнында
Кысылган зур дәһшәт йомгагы.
Туйдырды шул дәһшәт каршында
Үкенү, юану, моңаю.

Калды тик, чыгарып аланга,
Акыртып суярга язмышны.
Калды тик рухыма булырга
Өгенең «уф»лаган тавышы.

И себер татары: ни диим?..
Бары тик Ермакны, Күчүмне
Тарихта калдырыр өченме
Дөньяга, бу җиргә син килдең?

# Ат

Кычкырып, сызгырып карыйм —
Атны кузгатып булмый.
Ник, дисәм, шулай карыша? —
Ачык авызын тыңлый.

Дерелди, гүя гәүдәсен
Черки, кигәвен сырган.
Күзләре акаеп тора
Шартлап чыгардай сыман.

Мин дә ишетә башладым:
Ах, тыңламыйча булмый!
Нинди җил, кайсы гасырдан?
Авызга кереп елый.

Саргылт тешләргә бәрелеп,
Нинди моң йомарлана?!
Ат белән маңгай терәшеп
Әллә бер еларгамы?

Йөрәгем аша үтә күк
Бар дөнья сагаюы.
Суыра мине ат авызы —
Коточкыч тирән кое.

Кешни генә күрмәсен ул —
Куркам хаос туудан.
Бармак очларыма басып
Качам ат баскан кырдан.

## Йолдызлы төндә

Карасам йолдызлы күгемә,
Чемердәп, хәл китә тәнемнән:
Әйтерсең, бай ханлык качканда
Тәңкәләр, чулпылар чәчелгән.

Шыгырдап куйгалый туңган кар,
Агачтан чыбыклар коела.
Тирәмдә килалмый, сәкәнләп.
Күчүмхан йөри күк тоела.

Үз итеп, сөенеп, ник чыкмый
Алдыма, учагым янына?
Батырның саф канын тартырлык
Җегәрлек юктыр шул канымда.

Тынлыкны тыңлыймын, тыңлауга
Чыдамый, шартлады төз чыршы.
И ай, мә, кадал дип, хәнҗәрдәй
Очланып, сузылмый син торчы!

# Тимә

Уйда кайттым ерак бер гасырга,
Хәтеремнән алда торып.
Мине миңгерәтеп серле тынлык,
Йотты яшел караңгылык.

Мылтыгымны ордым тирән күлгә,
Бабам рухларыннан куркып.
Җәя генә тирбәнергә тиеш
Монда тынлык йонын кыркып.

Кысам күзләремне, шундый кысам! —
Очкан ук кагылуын көтәм.
Көчәнештән баш әйләнеп: — Мин — хан! —
Дип, үземне игълан итәм.

Бөтен төркиләрне җыймак булам,
Корыч туплар коймак булам.
Кош канаты буйга йөз арырлык
Дивар өеп куймак булам.

...Шунда: — Ни явызлык уйлыйсың? — дип,
Иңбашыма төртте кәфер.
Акырасым килде: — Тимә! Мин — хан!
Монгол ханы! Тезлән! Хәзер!

## Кошы кайсы чорның син?

Куркыбрак, кысылыбрак
Кырда басып торамын.
Аяклары салынган
Очып килгән торнаның.

Тели сыман моңлы кош
Күз-йөземне тырнарга.
Нинди кара гөнаһым
Җир өстеннән тырпая?

Юк, ашыкмыйм, җыенмыйм...
— Мин гөнаһсыз,— диярге.
Күл кичкәндә тамчылар
Таммый калмый иренгә.

Теге чорда, изге дип,
Очынып кылганнарым
Булып куйды бу көндә
Иң кара гөнаһларым.

Юк, карышмыйм, торнакай,
Чукый алсаң, чукырсың.
Тик шуны гына әйт миңа:
Кошы кайсы чорның син?

* * *

Кар төшкәләп, йөз сыйпаштыргалый;
Кояшы да караштыргалый.
Көртлек очып куя; алга чыгып,
Кеш койрыгын болгаштыргалый.

Каен кәүсәсеннән туз, сыдрылып,
Бергә кубыз өрергә димли.
Юк инде, юк! Көзем, көчәндермә —
Матур сүзләр уйлыйсым килми.

Шатлык-очыш булмый калмагандыр —
Хәтеремне барлыйсым килми.
Ут койрыгын болгаштырып төлке
Этлек-мазар кыларга өнди.

...Куа чыксам, төлке ерак китмәс:
Эзе өндә туктарын беләм.
Минем генә эзләр бара-бара
Кайчан, кайда югалыр икән.

## Себергә Корбан бәйрәменә кайткач

Әнә: тора! Болан тора!
Мылтыгымны атмыймын:
Тибендереп тунаулардан
Хәзер ләззәт тапмыймын.

Соңгы болан булып куйса,
Онытыма ни калыр?
Бу як әле янә «Себер
ханлыгы»,— дип аталыр!

Болан тора! Мине йомлый
Шундый татлы, котлы уй!
...Себернең барлык куе да
Шул боланга тормый, гуй!

Болан тора! Сөзешергә
Атлыга бит шатлыгым.
Әллә нимә миннән кылың —
Барыбер аңа атмыймын!

* * *

Сукмактагы кортны изсәң,
Җиңү хисе киләме?

Йоклап яткан эткә типсәң,
Җиңү хисе киләме?

И, себер татары, кинаям,
Җаныңа хуш киләме?

Урманнарың, күлләрең — син
Теләгән киңлектәме?

## Булмас бүтән уңай вакыт

Нишләргә дә белми йөрим —
Ярсыргамы? Еларгамы?
Анда — Тубыл татарлары,
Монда — Төмән татарлары.

И кардәшләр, күкрәк сугып,
Бу җирләрне безнең, диеп,
Имгәтелгән рухыбызны,
Кисәкләргә бүликмени.

Елгаларга, урманнарга
Озак-озак караганда,
Бер үк төсле эре яшьләр
Күзебездә кайнарлана.

Йөзләр берчак ак булгандыр,
Томалаган хәзер бер үк сөрем.
Кырыслыкмы, мескенлекме?
Тарих кына белә серен.

И, якташлар, рухым сизә:
Булмас бүтән уңай вакыт.
Тубыл, Төмән арасында
Чын татарча ярсып алыйк!

## Мин сүгендем

Еларга кирәк булгандыр —
Мин каты сүгендем.
Һәм тезләндем дә ачынып
Козгыннан үтендем.

— Сүгенүемне ятла да оч —
Ил буйлап күктән сип.
Баш игән, сүнгән кешеләр
Һич юкта, сискәнсен.

Кая карама, агачлар
Чайкала, тирбәлә.
Дәррәү тибенеп, козгыннар
Очып китте мәллә?

## *Төмәнне кортка төрә*

Бураннар йөгреп керә,
Төмәнне көрткә төрә.

Яр буйлап утрау-утрау
Укмашкан йокымсырау.

Турага төшеп карыйм,
Бозларын тишеп карыйм.

Тирәли этләр өрә,
Дулкыннар йоклый бирә.

Дулкынны коткарырга
Көч җитми боз ярырга.

Уйларым үчле, тешле,
Елгыр чуртаннар төсле.

Гарьләнеп, ярга карыйм:
Килүче-мазар бармы?

Бармы, күгәрмәгәнме
Чормада сөмәннәре?

...Бураннар йөгреп керә,
Төмәнне көрткә төрә.

Йоклый себер татары,
Карга чумып, уралып.
Боз астында, тирәндә
Тончыга алтын балык.

## Якташым

Маңгаенда җыерчык —
Табан балык чумарлык.
Йөзендәге кырыслык —
Елан коты очарлык.
Күзендәге кысыклык
Ташның суын сыгарлык.

Шул якташтан җаныма
Канәгатьлек үреләә:
Туган якның иң үзәк
Тамыры булып күренә.

# Бармы ирләр?

Күк томан эчендә «дөп» тә «дөп»,
Тышаулы елгырлар килә күк.
Ятып та, басып та мин карыйм:
Күрмәмме аларның сыртларын.

Күрмәмме шунда мин берәр ат —
Иярле, кылычлы, чукмарлы.
Җилфердәп килмәсме сөңгедә
Күчемнең ак кыллы бунчагы.

«Дөп» тә «дөп» — инде ул бик якын!
Чынлап та ат булса, нишләрмен?
Ничек мин, туктатып, тотармын?
Ничек мин тышауны чишәрмен?

Болгана каршымда күк томан.
Белмимен: артымы, алдымы?
Атларны чүктереп атланыр
Берәр ир Себердә калдымы?

# Ханчабыр авылы

Күчүм хан да, йөнләләр дә
Бу авылны талаган.
— Без — кандашлар, рухташлар,— дип,
Казанлылар алдаган.

Күл төбендә күпме ядрә,
Ук очлары черегән!
Кеше каннарында уылдык
Бөртүен дә күл күргән!

Авыл әле исән, яши,
Наратларга сыенып.
Халык йөзен саклый әле,
Күл суында юынып.

Янәшәдән поезд үтә,
Рөхсәт сорап ул тормый.
Карагайда — суер, күлдә
Балык куркып кылтырый.

Кайчак мүкле карайгалар
Тоташ селкенеп куя.
«Һаман да бу — өнме ни?» — дип,
Алар күзләрен уа.

Ханчабырда өнемдә дә
Төшемдә дә мин булам.
Күл буенда йөрегәндә
Ачы яшькә буылам.

## Минем җирләр

Бухарага алты чакрым,
Егерме бер — Ханчабырга,*
Төмәнемә йөзгә якын,
Казанга мең чакрым гына.

Шул чакрымнардан соң тагын
Сузыла ничә мең чакрым.
Бу — бит минем туган ягым;
Яши шунда татар халкым.

Була, халкым, төрле чагың,
Тискәрерәк тә чагың.
Үпкәләргә кирәк тапмыйм,
Чөнки аңа юктыр хакым.

Ни булса да, туган халкым,
Синнән качмыйм, чыгып чапмыйм —
Утлы упкын булып уыла
Ят киңлекләрдәге чакрым.

* *Бухара, Ханчабыр* — авыл исемнәре.

# Кысырыклау

Агун* кебек алпан-тилпән
Ал таң ата.
Йөреп, иснәп арган төлке
Көрткә ята.

Көн туудан минем җанга
Шатлык йокмый.
Заман җирдән акрын гына
Кысырыклый.

Көрсенсәм мин, нарат, шартлап,
Авар кебек.
Ауган чакта күкне умрып
Алыр кебек.

Беленә көн, агачларга
Хәлсез тибеп
Тозагымда җанын биреп яткан
Агун кебек.

* *Агун* — кыр тавыгы (куропатка).

## *Ашыкма дан яуларга!*

Бер дә уйламаганда бит
Басып куйдым капкынга.
Ярый әле ябылмады
Тимере тутыкканга.

Әйләнәсен сырган җиләк,
Әйтерсең, кан чәчрәгән,
Тәннәремдә дөрли көч, дәрт —
Белмим инде — нәрсәдән!

Әмма мин — шат! Шундый шат!
Алга атлый алганга.
Аерам да үләннәрне,
Төкерәмен капкынга.

Күзләреңне син тондырып,
Ашыкма дан яуларга.
Күгәрергә вакыт калдыр
Корылган капкыннарга.

* * *

Туры килде күпме саз,
Күпме урман үтәргә.
Насыйп кына булмады
Берәр поши күрергә.

Күк йөзе шундый охшый
Тоз сибелгән тирегә.
Әйтерсең лә, тарттырып,
Элгәннәр киптерергә.

## И, ана!

Нарат өстендә
Козгын әйләнә.
Йолкып ташларга
Ниятли мәллә?

Ни чыгарса да
Үзеңне юлга,
Ата-анаңа
Үпкәле булма.

Сабый имгәндә
(булды күргәнем)
Чәйнәп куйгалый
Ана күкрәген...

Суккалап куя
Шуңа анасы —
Башкача ничек
Инсафланасың?

...Адымың кыскарт,
Ашыкмый атла:
Озаграк карап
Кала алсын ана.

Тиз уңсаң, күздән
Козгын гына кала.
Игътибар итә
Күрмәсен аңа
Ана. И, ана!

## Кыш килә

Буш көннең, кыш көтеп.
Сеңере тартылган.
Ни кыра артыннан? —
Чытырдый алсу таң.

Әйтерсең кышлардан
Зәңгәр хат — күл каткан.
Укырга сарытүш
Сузыла куактан.

Шул хатка сукканда
Ишкәкнең яңагын,
Яңраудан ярыла
Балыкның саңагы.

Кискенлек, усаллык
Бөркелә чишмәдән.
— Тыныч тор әле,— дип,
Бармакны тешләттем.

Чишмәнең, дерелдәп,
Бар буе чирканды.
Кай ара шулкадәр
Боздырдым мин канны?

Сагайтып җиһанны,
Бик зәхмәт кыш килә.
Тынычлык тоя алмыйм,
«Күнеккән» дип кенә.

...Курыкмас идем дә
Киләсе кышлардан,
Миндә генә тибенсә
Сыкрак җан, бозык кан.
И, заман!

* * *

Күрәсеңме яфракларны:
Ничек оча, тузалар?!
Сагышымны чемтеп, чемтеп
Таратмакчы булалар.

Тыңлыйсыңмы торналарны:
Ничек «торыйк» сузалар?!
Сагышымны йолкып, йолкып
Таратмакчы булалар.

Аңламассың җилен көзнең:
Тереләме, үләме?
Селкетә күк агачларны
Сагышымның гүләве.

* * *

Олау-олау яфрак ява
Юл буенда каеннан.
Очка менгән борындыктан
Сызгырмавын ялынам.

Ләззәт булып оча тора
Ашыгуның ялкыны.
Очкан казлар миннән сорый
Борынгы җыр, ялынып.

Үзем дә бит телим аны —
Көтәм сусап, сагынып.
Китәр идем туган якка
Яңрашына салынып.

Каеннардан яфрак ява.
И ява ла олулап!
Сызгырмаган борындыкка
Баш иямен, олылап.

# *Көчәнеш*

Каен аягын аерган,
Болыт муенын каерган,
Суның үпкәсе күренә,
Чәчәк ачудан күбенә.
Шөпшә күзенә керәм кук.
Үземне читтән күрәм кук.

...И аңым! Тиздән үләм ич!
Газаплый шигъри көчәнеш.

* * *

Биектән һушлары киткәнме,
Искереп тузамы оялар?
Көн буе җилләрсез-niләрсез
Төпләре чыбыгын коялар.

Ә кәккүк акыллы — алданмый,
Аларга күкәен ул салмый.
Биеккә кунган да сабыр җан
Ояның алтынын чамалый...

Ятимсу ай чыга, төн җитсә,
Эленә оялар каршына.
Нәкъ кәккүк күкәе — тик кемдер,
Им өреп, зурайткан аз гына.

* * *

Моңлы, үкенечле торышы...
Кунмыйдыр аңа урман кошы.
Әллә ничек бөгелә-сыгыла.
Терсәген тешләмәкче була.

Кызгандырдың, юкә — булдырдың.
Кисмим инде — зур шик тудырдың.
Насыйп түгелдер шул басарга
Үзем бөккән яңа чаңгыга.

...Ярар инде ... күнеккән бит
Көрткә бата-чума, барырга.
Тик менә... ничек күренәмдер
Мин язмыш бураннарына.

* * *

«Көн начар»,— диюегезне
Һич ишетәсем килми —
Колакка нидер әйтеп,—
Кисәтмәкче ул безне.

Урманга керәм дә мин
Табамын тыныч урын.
Чыланган чебештәй ул
Чак калтыранып торыр.

Туар күк хикмәтле сүз,
Җитдиләнеп уйласам.
Очып та китәрмен күк,
Көлә алсам, йә еласам.

Кояшка гына кайчак
Килеп куя тибәсем.
Нигә ул хәтерләтә
Черек чебен гөмбәсен?

# Эч пошканда

Төзи дә беләм бит — вата да...
Әмма аннан миңа юк файда.

Күрмидер лә Аллаһ Тәгалә
Яшәвемне нинди халәттә.

Башым бөрештерми рәтле уй.
Хет балта астына салып куй.

* * *

Менә монда болан ауган —
Ята-ята усак булган.
Әнә анда куян яткан —
Ята-ята куак булган.

Үсә каен, нарат, балан,
Күрәм тагын эт шомыртын.
Агач кочып уйланамын:
«Мин, егылсам, ни булырмын?»

Кайчагында карурманда
Шундый татлы иңгеримен.
Гүя, оҗмах белән тәмуг
Арасында мин йөримен.

* * *

Төлке баскан капкынга —
Мескен шундый тилмерә.
Төне буе тәпиен
Чытырдатып кимерә.

Мин дә ятам бу төндә,
Шыңшып: — Түз, йөрәгем, түз!
Күзгә карап, бер таныш
Әйткән иде авыр сүз.

Таң алдыннан төлке шат —
Йөгерә өч аяклап.
Ә миңа ай иелә,
Төкерергә сымаклап.

## Өнендә күргәннәрең төшеңә керә

Төшемдә һаман
Куян да куян.
Аю, пошины
Күрермен кайчан?

Килер әле көн,
Төне дә килер:
Тычкан, күсе генә
Төшеңә керер.

* * *

Моңаю — күндәмләнү генә ул,
Ә сүгенү — өзгәләнү.
Ярым моңаеп, ярым сүгенеп
Бу дөньяга түзәм әле.

# Каен

Кибә инеш, тиздән төбе
Үлән белән капланасы.
Ярындагы яшь ак каен —
Сусыз калган су анасы.

Талпына да, очына да —
Китә алмый — көтә һаман:
Урлаттырган чәч тарагын
Китереп бирерләр сыман.

Алтын тарак табылмавын
Җаным һәрчак хуплап торыр.
Китсә каен — су анасы,
Инеш кенәме соң корыр?

# Сандугач

Кошчык симез корт чукый,
Җирдән тартып чыгарып.
Кичке шул тамашага
Карый кызым чиркanып.

Җир кортыннан хәл күчкәч,
Кошчык очты куанып.
Кайдандыр ул җыр сузды —
Кызым тыңлый сокланып.

# Тынлык

Гап-гади, чып-чын җәйге тынлык...
Ходайның бу могҗизасыннан
Табигать тә, мин дә тел йоттык.
Ахры, икебез дә курыктык:
Моң-сагышка күмелә калсак,
Мәңге булмас кебек котылып.

# Әнеләремә

Бар алар — биек агачлар, бар.
Анда-монда берән-сәрән.
Тик җилфердәми очларында
Безнең әләм.

Буй үстергәнгә үкенгәндәй,
Кыенсынып тора алар.
Борчылалар да күк, эленә
Күрмәсен, дип, кеше-мазар.

Эх, энеләрем, кайтсам сезгә,
Йөрәк сызлап, җаным сыктый.
Шул агачларны аударырга
Ниндидер бер җенем кыстый.

# Җилле көндә

Ак төтенгә эленергә
Юк һавада иркен урын,
Гарьлегеннән, җиргә ятып,
Чәйни, тырный үлән сыртын.

Юеш борнын ялтыратып,
Килеп чыкты ап-ак көчек.
Кереште ул ботарларга
Тыпырчынган төтен күчен.

Шул кызыктан тәэсирләнеп,
Күкрәгемнән ыргылды җыр.
Качты көчек койрык кысып,
Тавышымнан куркыпмыдыр.

Чыбыкларга сыдырылып
Өрә-өрә көчек качты.
Җырым, куәтләнә барып,
Артына ук аның басты.

Алар авыл урамына
Икәүләшеп килеп керде.
Минем җырым нишләгәндер,
Ә көчек өрде дә өрде.

Әй тырышты, тырышты ла
Куркак көчек, аһ, бичара!
Купты тавыш, кош-кортлары,
Күтәрелде бөтен карга.

Ә кешеләр... Куандырды.
Мең рәхмәтле мин аларга.
Каш өстенә куллар куеп,
Күз төбиләр минем ярга.

Учак яна, гөрләп яна!
Ник янмасын җилле көнне!
Әйтә генә күрмәсеннәр:
— Кем анда җырлый белми?

## Күләгәдә интегәмен

Урман тонык, кош-корт боек,
Көне дә бозык, сытык.
Күкрәгенә түгә-түгә
Су эчә йолкыш чыпчык.

Тәпи җәеп киерелеше
Җирне үтә чукырлык.
Юк хисем — ачуланырлык.
Юк хәлем — таш орырлык.

Озаккамы ябыштырды
Мине тынчу күләгә?
Чыпчык чәчрәткән тамчылар
Тама икән кемнәргә?

...Шигырь заманы түгел бу,— дип,
Йөрегәндә күп шагыйрь,
Күләгәдә интегәмен,
Шигырь уйлап, мин — бахыр.

# Тәрәзәдән карыйм

Килде мәче, аннан соң эт,
Мәчедән күрмәкче.
Бер читкәрәк кунды карга:
Чукыды, чүпләде.

Килде тагын адәми зат,
Куды ул аларны.
Ашыкмыйча, бик җентекләп
Чүплекне актарды.

Кыйнап алсу таң яңагын
Ишекләр ачылды.
Сукрайган җан асраучылар
Каядыр ашыкты.

Тышта бик килми йөрисем —
Тәрәзәдән мин карыйм.
Чүплек йота, комсызланып,
Таңнарның ак карын.

Тагын көн үтә, кич җитә,
Эз килә, эз китә.
Карлар күмә алмый чүплекне,
Котырып ишеп тә.

...Тагын, йөз яшереп, бер адәм
Казына чүплектә.

# Елан

Ком өстендә ята елан,
Бөгәрләнеп сабый сыман.
Үлән, чәчәк, яшь карлыган,
Чык исләре аңкый аннан.

Четердәтеп, сөенешеп,
Нурлар кыра тәңкәләрен,
Тел очлары кутырласын
Агулы, дип әйткәннәрнең.

Баш күтәрсә, соклан да
Китеп бар,— яхшысы — шул.
Табигатьнең беравыкка
Кабык салган язмышы — ул.

# Үр-гүр

Анда яңа сызланулар, борчылулар;
Төшендә, теш шытырдатып, кычкырулар.

Баеп, менмәк була берәр биек үргә;
Тели аннан, ыштан салып, арт күрсәтергә.

Тел очыма кытык куна, килә «дер-дер»;
Әйтмәк була шул кешегә: «Үр-гүр, үр-гүр».

# Саклый күрсен

Әфсен-төфсен!
Әфсен-төфсен!
Аттым бер тилгән
Елга буенда.
Тырнагын йолкып
Астым муйныма.

Әфсен-төфсен!
Әфсен-төфсен!
Аттым бер аю
Урман куйнында.
Тешен каерып
Астым муйныма.

Әфсен-төфсен!
Әфсен-төфсен!
Тоттым сандугач
Тал куелыгында.
Каурыен чеметеп
Астым муйныма.

Тагын ни җитми
Минем муенга?
Тфү! Явыз коткы,
Кермә уема!

Әфсен-төфсен!
Әфсен-төфсен!
Мине Тәңрем
Саклый күрсен.

# Газинур Моратка

Шигырьдәге мәргәнлегең
Йөрәгемне көйдерә.
Сунардагы сабыйлыгың
Безне дуслар иттерә.

Ядрә тигән чөрәгәйләр
Егылып төшкән арада,
Нинди уйлар өлгерәләр
Миләреңне чагарга?

Күзләреңне яшерергә
Җитми синдә осталык.
Тама мылтык түтәсенә
Күз яшьләрең «тып» та «тып».

Тыпырчынган үрдәкләрнең
Сугар чакта башына,
Каушап калып, кылтырыйсың,
Кояш, күк, су каршында.

Каннан куркып күз чылаткан
Чыкмый иде сунарга —
Син чыгасың канлы йоннан
Утлы шигырь сыгарга.

Кызганамын сине ауда —
Сабый инде, сабый син!
Шигъриятнең бер алыбы
Ничек була алдың син!

# Бер халык шагыйренә

Елгага казык тезсәң,
Агым көчсез кала.
Акыллы сүз күплектән
Җырда моң югала.

Шигырьләре аның — нәкъ
Уылдыклы балык.
Балыкчы исемен дә
Аңа тагып карыйк.

* * *

Сузыла алдымда
Төлке сукмагы.
Ә минем кулымда
Куян тозагы.

Кулымда булганда
Төлке капкыны,
Тычканның эзләре
Сырлый ак карны.

Каен да, ит элеп*,
Тормый бөгелеп.
Барсына гаепле
Килде-киттелек.

Туган як сөйми шул
Килгән-киткәнне.
Көтәм карагайлар
Артка типкәнне.

---

* Аучылар табышларын эт-мазардан саклар өчен агачка элеп куялар.

## Син тагы...

Карт нарат ярылган —
Яшьләрен агыза.
Кояшның нурлары
Ябыша сагызга.

Ябышудан куркыпмы,
Тиеннәр йөгерми.
Көчәйтә сагышны
Алтынсу эңгерлек.

Бәйләргә иде лә
Наратның ярасын —
Белмим шул агачны
Дәвалау чарасын.

Нишләргә? Сыларга,
Буярга ярыймы?
Йөгертсәм утлы куз,
Нишләтер ярыкны.

Иң соңгы зур агач
Корый бит күзалда —
Дәвалый белүче
Бар микән авылда.

Наратны кайгыртып,
Авылга мин кайтам.
Кешеләр зур табут
Чыгара капкадан.

— Кем ул? Ник үлгән? —
Сорыймын аптырап.
— Син тагы...
Күршең бит — аучы карт.

— Үлә алмый ятты ул
Ничә ел тоташтан.
...И Алла, мин аны
Бөтенләй оныткан.

# Авылдаш

Әллә иярә чыкты,
Әллә озата бара,
Иртән торып, авылдаш
Олы юлга таба.

Кышның салкынын сизмим,
Җил ачысын тоймыйм.
Күршемнең миңа сипкән
Мәдхиясен тыңлыйм.

Әй, мактый да мактый ул,
Туктап, адым саен.
Җылынып, эреп китеп.
Масаюда кайныйм.

Бар икән бит авылда
Мине хөрмәт иткән!
Авылдаштан яшереп,
Яшьләремне сөртәм.

Килеп чыктык без Тәүде
Юлы чатына да.
Алыста, борылышта
Чаба машина да.

Әллә нишләде күршем —
Беләгемнән тотты.
Каушап, калтырап сорый:
— «Ярты»лыгың юкмы?

# Көнләшәм каргадан

Калын каер астында
Корт дөньясы кетерди.
Тукранның шатлыктан
Койрык очы зерелди.

Нәни кошчык чыелдый,
Юеш карга чак чуммый,—
Шартлаганга бөреләр,
Курка, талга ул кунмый.

Ялтрак карга түшләре
Күзләрең явын йомлый.
Орып, кычкырып карыйм —
Һич тә куркытып булмый.

Көнләшәмен аңардан:
Ничек татлы кыңрайган!
Яз килүен тыңларлык
Тына, оныта алган!

# Ике шаман ымлаша

Кылтыранып нидер көйли нарат —
Әллә анда шаман утыра?
Шул гүләүгә, биек тирбәлешкә
Кушылырга күңел котыра.

Төрле аваз кычкырмакчы булам —
Әллә миндә шаман уяна?
Әфсеннәре аның, им-томнары
Кирәк, бик кирәк — бу дөньяга.

Очынгалыйм да мин, тәгәрим дә
Сыенамын яшел бабага.
Кубып, төрле аваз, сөрән орып,
Җирне тырнап, очыйк кай таба?

Тамырымда каным гөлт-гөлт итә,
Ылысларда нурлар ыңраша.
Берсе карт наратта, берсе — миндә,
Тының, ике шаман ымлаша.

## Сай елгада

Карынында елганың
Күбекләнә сайлыклар.
Бер-берсенә сыенып,
Боегалар каеклар.

Дулкын кырган күкрәкләр
Коргаксыган, ярылган.
Чикерткәләр үтәләй
Очып үтә ярыктан.

Дулкын сөйгән комнарга
«Сүрә сыза» күчкерләр.
Гүя елан каплары,
Кымырчына күмерләр.

Чытырдатып елгабыз
Ташларына тотына —
Килми аның сеңәсе
Үз төбенең комына.

Төлке, кереп уртага,
Салындыра койрыгын.
«Тот капчыгың»,— дигәндәй
Мыгырдана карт козгын.

...Уйланамын, карыйм да
Кибеп барган суларга.
— Әллә Тәңрем аламы
Тере сулар сыгарга.

Аккан сулар әверелсә
Тере суга, ярый да.
Тик ник соң каекларның
Күкрәкләре ярыла?

* * *

Җилсез-нисез шаулый урман,
Сагаеп болыт тыңлый.
Туктап, баш имичә булмый,
Урман хәтере елый.

И урманым, кайталмасам,
Кайтырлар минем җырлар.
Очыңа чорналып, алар
Синеңчә шаулар, елар.

## *Наиләгә*

Кояшка, и, карадым ла!
Кайгы яше аркылы да!
Шатлык яше аркылы да!
Ул һаман сары калды ла.

Сарымы, сүндеме кояш —
Итмим хәзер игътибар.
Кояшларны оныттырган
Янымда бит син минем бар.

# Акчарлак һәм мин

И тузынасың, кычкырасың —
Мине куасың түгелме?
Күлнең суларын, балыкларын
Үзеңнеке дип белдеңме.

Читкә оч йә тын, йом телең.
Кыймылдый, әнә, калыкты.
Кыл өстенә куя язмышын
Алтынмы, гади балыкмы?

Капса, сиңа бирәм алтынын —
Үзем иң гадиен сагындым.

Кычкырма, тузынма — көт сабыр.
Дөнья болай да ягымсыз.
Эләксә, иң соңгы балыкны
Ашар идеңме, акай күз.

...Чүгәләде акчарлак, арып
Тузынудан, кычкырудан.
Уйлыйдыр: «Иң соңгы балыкны
Ашар инде бу — комсыз җан».

# Кемне син яраттың?

*Х.гә*

Чәчәкләр сүрелгән, боеккан
Бакчада, классташ, син юктан.
Күңелсез, бик шыксыз миңа да,
Моңаеп сөялдем коймага.

Һавадан салына болытлар —
Гаҗәп ак, тыйнаклар, яктылар.
Алар бит татылмый оеган
Серле тәм, куаныч, шатлыклар.

Четердәп чикерткә шикелле
Күп еллар күзалдан үттеләр.
Инсафлы хыяллар, өметләр
Тынлыкта тын гына сүнделәр.

Язмышка карышып торырга
Булмады чаялык, бозыклык.
Камиллек кача бит, яшеңне
Сөртүче булмаса, сузылып.

Күзеңә карармын, күренсәң,
Әмма мин юатмам — юк хакым:
Яшьлегең гөрләгән чагында,
Белмимен, кемне син яраттың.

Нигә соң күңелем төбендә
Кызгану, үкенү куера?
Гаҗәп саф, бик тыйнак, ак болыт
Миемнән акылны суыра.

Мөлдери зәңгәрсу чәчәкләр —
Бәрәңге бакчасы яшьләре.
...Бакчаны урталай кап ярып
Сап-сары күбәләк яшьнәде.

# Бер читтәрәк утырсын

Мине — төче күл балыгын
Тозлы суга салдың син.
Ярларымны ялкын белән
Ялматтырып алдың син.

Коткар, зинһар. Кара миңа,
Кара шундый иттереп:
Чумыйм әле чоңгылларга
Кояшкача сикереп.

Мәхәббәтнең мөмкинлеге
Көнләшкәнне куркытсын:
Карап миңа, сулый алмый,
Бер читтәрәк утырсын.

* * *

— Урманда куяннар туң каер кимерә,
Курада атыбыз азыксыз тилмерә.
— Без аның ялларын йолкаек, кыркаек,
Ишик тә куянга тозаклар кораек.
— Көрт — тирән, көне дә бик суык, буранлы.
Кичә бит саттык без чаңгыны, туннарны.
— Баш сызлый, ничек тә дәвасын табаек.
— Барыбер тилмерә, без атны сатаек.

* * *

Кар төшә... Алда әле
Рәхәтләнеп явасы.
Кая төшсә дә ярый —
Юк бирәсе-аласы.

Канатларын каерып
Көртлек җирне себерә.
Көрт кирәк: чумарга да
Тәмле төшләр күрергә.

Ә мин тиеш атларга.
Алда әле өмет бар.
Ыңгырашырмы... җырлармы?
Ятыр икән нинди кар?

«Яу-яу»,— дип ашыктырмыйм:
Аңа барыбер явасы.
Өметләрем хакына
Булсын гына дәвасы.

## *Мәҗүси зары*

Минем яшүсмер чак...

Һава — зәңгәр учак,
Урман — яшел учак.
Булам кайчак очмак,
Булам кайчак тузмак,
Төрле кош-корт, җәнлек
Авазлары булып,
Төрле бию биеп,
Кыланмышлар кылып.

Канга кузын тыгып,
Акыл гына тыя:
«Аңламаслар сине,
Бу — Аллалы дөнья».

Инде менә «карт» — мин.

Күккә, урманнарга
Канатланып бакмыйм.
Сүрән, гади учак
Итәгендә калдым.

Учак, пыскып, чыртлап.
Күзләремә карый.
Ялвара: өстә, ди,
Өй, ди, коры-сары.

Мин боеккан, арган;
Күз дә ерак күрми.

Утка чыбык-чабык
Ыргытасым килми.

Җаным төпкелендә
Түлләнә бит моң-зар.
Ялкын кебек гөрләп,
Бәлки, ташып чыгар.

Канга кузын тыгып,
Акыл гына тыя:
— Аңламаслар сине,
Бу Аллалы дөнья.

...Юк. Аллама үпкә
Белдерәсем килми:
Өнем агачтан сын
Юньләтергә димли,

Мин табынсын дипме?

* * *

Үлән булып үсәрме?
Төтен булып очармы?
Корый биек өрәңге,
Җыеп арган кошларны.

Тирә-юньдә таулана,
Калкулана яшеллек.
Ел исәбен бутаган
Кәккүкләрне яшереп.

Иске бишмәт-карачкы
Үзен-үзе куркыта.
Качып җиңе астына
Тавык сала йомырка.

Гүли марта күчедәй
Ерактагы олы юл.
Кайнар ләззәт тимчетеп
Сызлый аяк, сызлый кул.

Арка терәп коймага,
Күрше бабай кызына.
Уралырга муйнына
Өстән колмак сузыла.

# Ташландык йортта

Ташландык бер йорт үзендә
Калырга күндерде.
Яккачтын ярык учагын,
Сөягем эреде.

Елмаеп килеп, тулы ай
Тәрәзәгә эленде.
Җырлап җибәрим дигәндә
Чебеннәр терелде.

Эреләр, ачлар. Каһәрләр
Йөземә каныкты.
Кычкырдым: — Миңа тимәгез,
Мин күктән! Айныкы!

Шулай дигәчтен, чебеннәр
Котырып ябышты.
Ай, күрмәмешкә салышып,
Читкәрәк авышты.

Мич ярыклары ыжгыра,
Очкыннар очыра.
Бер чатта, мине кызганып,
Елый күк бичура.

Йокы юк, моң юк, чебен күп —
Хәлләрем киеренке.
Кычкырыйммы әллә: — Тимәгез!
Мин — кеше! Җирнеке!

Кычкырмыйм — куркам: болай да
Пыяла калтырый.
Бәдрәфнең чебене шикелле
Тышта җил зырылдый.

Сытарга телим, сузылам:
Караңгы — күренми.
Нигә мич шунда шартламый,
Диварны җимерми?

Кем ташлаган бу йортны?
Мөгаен, дивана.
Тәһарәттән соң бармагын
Сөрткәндер диварга.

Кем өчен, ни өчен миннән
Чебеннәр үч ала?
Эзлимен капшап ярыктан
Сүрәләр, и Алла!

## Үзен җырлап бетер

Бал кортлары туза —
Менә-менә чага.
Дәртле чалгы селтәп,
Яшь ир печән чаба.

Болыт түшен сыйпап,
Монда кибән калкыр.
Ай утырып аңа,
Ял иткәләп алыр.

Башын суза-суза,
Елан койрык болгый —
Кибән эчендә кыш
Үткәрергә уйлый.

Үлән канын иснәп,
Тычкан чыйнап куя.
Кибән төбе аңа —
Иң уңайлы оя.

Кышын килер дә ир
Бу кибәнне төяр.
Печән исен иснәп,
Кешеләр «Аһ!» дияр.

Тычкан, еланнар да
Олау белән кайтыр —
Ашый алмас сыер,
Бу печәнне кагыр.

Киреләкне күреп
Ир аптырап калыр;
Ауру дип, сыерын
Кар өстендә чалыр.

Ачуланып хатын
Ирен ташлап китәр.
Ошатмасаң җырны,
Үзең җырлап бетер.

...Ә хәзергә яшь ир
Җырлап печән чаба.
Бал кортлары туза —
Менә-менә чага.

# Йотма

Башын чуртан судан сонган.
Шулчак бәке никтер туңган.

Чуртан ярым чыгып калган,
Чуммый калган. Ник алданган?

Күгенә бак: анда кояш —
Нәкъ бер йотма инде, йотма.

Кемне кызыктырып, әйдәп,
Кемне алдап җирдә тота.

* * *

Бу арада ай-яй кыен
Замандашым каргага.
Кычкыра алмый газаплана —
Тиздән, ахры, агара.

Чара юклыктандыр, йолкый
Тәпиләрен, күкрәген.
Күк күзен дә чукыр иде,
Белсә кайда икәнен.

Булыша алмыйм бичарага —
Теш кысам да күз йомам.
Акрын гына йомшый барып,
Үз-үземдә йомылам.

Ишелгән кар, ыжгырган җил
Каргыш булып тоела.
Карап телсез каргаларга
Сулышларым буыла.

Җай чыкмас инде: кундың ни
Мең наратка, мең талга.
Очып китәргә генә кала
Параллель дөньяларга.

## Корыган агач

Ботаксыз, чыбык-чабыксыз,
Кунмый кош-кара.
Авыр суламакчы булып
Көчәнеп тора.

Тоям да шул көчәнешне
Тетрәнеп куям.
Кәүсәне каезлап, тырнап,
Череген коям.

Күктән каен тузыдай ак
Болытлар уза.
Гүя коргаксыган дөньяның
Каплары туза.

* * *

«Нинди азык — шундый холык»
*(Бер карт сүзе)*

Чыраемда
Дулкын-дулкын
Уйный холкым.
Гасырларда
Токым-токым
Уйный холкым.

Минем тәнгә
Төрле балык,
Төрле үлән,
Төрле кош-корт,
Төрле киек
Кереп сеңгән.

Башка тәмнәр,
Үзгәрешләр
Сорый заман.
Кем соң? Кем соң мин?
Әллә кеше?
Әллә хайван?

Шундый хәлем:
Чирканмыйча
Ашар идем
Төлке итен,
Бүре итен,
Елан итен.

Әмма бабам
Бу итләрдән
Тыела алган.
Ачуында,
Ярсуында
Йомыла алган.

Сәер холкым,
Күндәм холкым,
Озаккамы
Мине йоттың?

## Яз

Томшыкка томшык ышкыла,
Мөгезгә мөгез сугыла,
Маңгайга маңгай кагыла —
Муенга муен сузыла.

Бар да әйбәт, тик хатын гына
Бераз эчне поштыра,
Бит очларын алсулатып,
Хыялланып утыра.

## Пошиулеме

Карт поши ешлыкта
Катты да туктады:
Ботымы, сыртымы,
Йөрәкме чыртлады.

Бу чыртлау йоклаган
Куянны уятты.
«Акай күз» каядыр
Туп-туры олакты.

Берни дә селкенми,
Борчылган сизелми.
Тирә-юнь агачка
Каргалар тезелми.

Тынлыкның канында
Зеңгелди тантана —
Әйтерсең табигать
Оялып шатлана.

Кояш та карый күк
Үзгәреп, яңарып —
Ниһаять, бер поши
Үлде бит картаеп!

...Күрсәгез куянны,
Ашыкма атырга.
Ул безгә сөенеч
Әйтергә ашыга.

## Кайда көчек?

Офыкта бик кызык
Тамаша күрәмен:
Җир имә, сыенып,
Кояшның күкрәген.

Текәлеп кояшка
Бер әнчек эт өрә.
Өргәндә имие
Аксыл сөт сиптерә.

Кайда соң көчеге,
Кайларда йөгерә?
Чаптымы әллә ул
Кояшны имәргә?

Елмаеп йокларга
Тырышып карагыз!
Шул чакта югалмас
Шук көчек — кара күз.

Әйләнеп кайтыр да
Ул сезгә сыеныр.
Йөзегез алмасын
Яларга сузылыр.

Саф сөттә юылган!
Кояшны ялаган!
Шул көчек теленнән
Мин эрим, и Аллам!

...Һәм кояш югалды.
Йолдызлар елтырый.
Ач, туңган көчектәй
Җир шары кылтырый.

Чык булып, сибелеп
Сөт тама туфракка.
...Эт көтә кояшны
Тешләргә, тырнарга.

# Тартар

Иртә-кичен яра иде:
— Алла саклар! Алла саклар!
Инде менә ишетелми,—
Нигә тынды безнең тартар?

Әллә бер үк авазларны
Кабатлаудан туйдымы ул?
Әллә мине юатырга
Яңа аваз уйлыймы ул?

Сирәгәя башлады бит
Дусларым, безнең дә сафлар.
Кайда тартар? Ник юатмый:
— Алла саклар! Алла саклар!

* * *

Аллага шөкер!.. Тагын җәй
Тыйнак таңын аттыра.
Мин теләгән яктан исеп, җил
Талның канын яздыра.

Чәпче* чебеше масайган —
Атлый түшен киереп.
Ярда шуыша ач мәче,
Чыкка танау көйдереп.

Кычкырып кумыйм, куркытмыйм:
Мәче тотсын, ауласын.
Үз канунында табигать
Оясында шауласын.

Әмма чебеш чинаганда
Җаным бераз ачыныр.
Явызлыгым, кыргыйлыгым
Каезланыр, арчылыр.

Шулай булсын, тик тусын көн,
Миңа зыян итмичә.
Хәерле көн дияргәме? —
Йон өереп, җил исә.

* *Чәпче* — кулик.

## Айлы төндә ауда

Җәнлек айга караса,
Шундук сукраер.
Кайнар угыз өстедәй
Кылтырап тора кыр.

Хәтта күзгә чәнчелә
Тычкан шәүләсе.
Шыр ачык — чәчрәп тора
Яшәү хәйләсе.

Чү! Болын уртасында
Тагын бер нокта...
Төлке икән. Авылга
Ул борнын тота.

Авыл тирән йокыда
Татлы төш күрә.
Аргы очта, сарыкмы,
Нидер төчкерә.

Менә төлке терәлде
Бакча артына.
Телим, әмма куркамын
Мылтык атырга.

Атсам, күршем иртәсен
Бастырып керер.
Тагын кыйнамак булып
Өстемә килер.

Кичә дә ул хатынын
Сөям дигәндә
Атканмын, алар куркып
Егылган идәнгә.

Шуны искә төшереп,
Елмаеп куям.
Айның тагын да мулрак
Балкуын тоям.

...Җылы курада төлке
Тавык туздыра.
Хуҗаның вакыты юк
Тышка чыгарга.

...Айга туры карамыйм,
Күзем сукраер.
Тәрәзәңдә ут күрмим —
Миңа бик авыр.

# Янә ту икән

Беркөнне, кызып,
Этемә типтем.
Тотып алдым да
Асарга илттем.

Урманда этем
Ычкынып китте.
Агачлар миңа
Карашын төртте.

Елмаялар күк,
Сызланалар күк,
Җирәнәләр күк,
Кызганалар күк.

Нием өчендер
Оялып куйдым.
Никтер үземне
Гаепле тойдым.

Эчемнән урман
Нидер суырды.
Шунда ук өреп,
Нидер тутырды.

Кайтырга чыккач,
Этемне күрәм,
Ни ният белән
Яныма килгән?

Курыкмыйча эт
Каршыма басты,
Күзләремә ул
Туп-туры бакты.

Шундый кимсетү
Тойганың бармы?
Син типкән, сиңа
Кызганып карый.

Ник мине, урман
Мәсхәрә иттең?
Ни сихер өрдең
Җанына этнең?

Тынсыз үкенү
Газабы чигәм.
Их, бу дөньяга
Янә ту икән!

...Чыгыйм инде мин
Куеныңнан, урман.
Эт булып улый
Башлаудан куркам.

## Син һаман да юк

Үрмәкүчләр ятьмә
Кора башлаган чак;
Ярканат колагы
Тора башлаган чак.

Баллы чәчәк эзләп,
Соңга калган, марта
Соңгы кояш нурын
Кыр өстенә тарта.

Ябеште шул нурга
Бөҗәкләр, тилереп —
Әх, дигәнче, нуркай
Бетте кимерелеп.

...Төн. Син һаман да юк —
Җан-йөрәгем сызлый.
Йолдызлары күкнең,
Бөҗәк булып, мыжлый.

Кимерә күк алар
Безнең мәхәббәтне.
Исән калырмы ул
Таң атканга хәтле.

Шуңача, их, миңа
Ярканат булырга,
Йоклатмый, тәрзәңә
Кат-кат сугылырга.

# Төмән кызы Сачилә

Нишләем дә, ни диием,
Төмән кызы Сачилә.
Сине күрсәм, тын кысыла,
Йөрәккәем чәнчелә.

Үзәкләрем «чырт-чырт» итә
Күзләренә карагач.
Алар тиен, селәүсеннең
Күзе белән аралаш.

Тастыганмы, мүк чияме
Иренеңә бөрелгән.
Кагылырга уйлаганда,
Мең үләм дә терелләм.

Ничек чыктың бу гасырга
Син ычкынып ханнардан?
Бабаларны кызганамын —
Алар ничек чыдаган?

Сине күрсәм, куанычтан
Күзләремә яшь килә.
Горурлыгым син, якташым —
Төмән кызы Сачилә.

# Гаҗәп авыл

Бик матур бер авыл бар —
Менә шунда мин туган...
Алан саен — карлыган,
Агач саен кош кунган.
Кычытканнар, әремнәр —
Әйтерсең генераллар,
Нурга ничек балкырга
Әмер биреп торалар.
Башаклары туп-тулы
Кырда үскән бодайның:
Төшсә, тузан туздыра,
Башын тишә тургайның.
Күлмәгеңне сал да сөз
Җан теләгән балыкны.
Урамнарда төннәрен
Кыр үрдәге бакылдый.
Тимәгәндә, этләре —
Бик сабыр, акыллылар:
Тынычлыгын авылның
Чиратлашып саклыйлар.
Малайлары да үзгә —
Күз тидереп куйма.
Кош баласын, егылса,
Кире мендереп куя.
Чык күренә үләндә,
Былбыл күкәе булып.
Ак болытлар карала,
Шомыртларга ышкылып.
Кәкре-бөкре агачка
Йөгереп менә кәҗәләр.

Мөгез ышкып каерга,
Сөзешергә дәшәләр.
Чукып киндер орлыгын,
Тавыклары исерә.
Бутап, сала күкәен
Күршеләре җиренә.
Яши әле бабайлар,
Сәламләргә өйрәткән.
Сирәк очрый агайлар,
Сүгенергә өйрәткән.
Аһ! Киченең, таңның
Күңелләрне айкавы!
Кылтырата җырларга,
Хәтта, чукрак, сакауны!
Татар теле өзелми,
Шундый матур яңгырый!
Читтән килмәвенә ул
Шик-шөбһәләр калдырмый.
Кире кайтып, җылына
Китканнәре — туңганда.
Илдә чыпчык үлми шул
Мондый авыл булганда.
Карап тырыш халыкка,
Килеп тора эшлисе.
Тыңламасаң киңәшен,
Берчак терсәк тешлисе.

...Кичерең, масаюны
Белмим ничек тыерга:
Нинди гаҗәп авылда
Насыйп булды туарга!

## Кемнән ул качты?

Мин сөймәгән күршеләр
Нахак гаеп тактылар:
— Карак — синең улың,— дип,
Атам җанын чактылар.

Кыйнарга дип, ярсынып,
Әти килә өстемә.
«Чарт-чорт» чәчри ачулар
Аның ябык йөзендә.

Имгәнүдән куркып, мин
Әтиемнән качамын;
Тау астына, шаракка —
Яшел төнгә чабамын.

Кызган тоздай чытырдап
Чикерткәләр сибелә.
Чыклы җиләк, чәчәкләр,
Күбәләкләр изелә.

Елан, шөпшә чакканны
Тоймый аяк табаны.
Күрше нәрсә уйлыйдыр,
Күреп сабый качканны.

Куакларга тырналам,
Ботакларга төртеләм,
Бу дөньядан мәңгегә
Югалырга йөгерәм.

Баш очымда күк йөзе
Упкын булып чайкала.
Ачы рәнҗеш җанымны
Илтер икән кайларга?

Минем белән болытлар,
Каеннар да кача күк.
Тукта, улым, качма, дип,
Әти елап чаба күк.

...Артка карыйм дигәндә,
Мин тамырга абындым.
Кушкангадыр Ходаем,
Тал калкыткан тамырын.

Кочып алды әтием
Мине куып җитте дә.
Шундый тибә йөрәге!
Икебезне селкетә!

Нидер безне, куркумы,
Бер-беребезгә сеңдерә.
Әтиемнең яшьләре
Битләремне көйдерә.

Ата-бала яшьләре
Бергә кушылып кайнады.
Карагайлар чайкалып
Авыл якка янады.

Тындык. Безнең яшьләрдән
Урман шундый чистарган!

Тагын килә елыйсым —
Әтиемне кызганам.

Булмаса да гаебем,
Карый алмыйм йөзенә.

Йөрәге аша каным
Ага кебек сизелә.

...Нинди уйлар, нинди хис
Кыскандыр җанын аның.
Оныта алмыйм: «И улым...»
Дип, сузып ыңгырашканын...

Тешен шытырдатканын.

Аңламадым әтине.
Аңламадым шунда мин.
Ә ул сүзсез аңлады
Мин гаепсез булганны.

Каршылады күршеләр,
Астыртын көлемсерәп.
Ашыктырды әтием:
— Атла, улым, тизрәк!

Әти хәзер зиратта...
Иртәрәк шул ул атты.
Энеләрем, бездәнме,
Күршедәнме ул качты?

# *Яз, сеңлем! Яз!*

*«Яңарыш» хезмәткәре*
*Диләфрүз Фәхригә*

Ничек анда — Төмәнемдә
Яңгырлары, бураны?
Тирә-юньгә мәчетләре
Нур чәчрәтеп торамы?

Татар габе, чишмәләнеп,
Урамнарда гөрлиме?
Милләтебез зыялары
Мәэюсләнеп йөрмиме?

Сайрамыймы татлы йомак,
Якташларны йоклатып?
Сүрелмиме үзгәрешкә,
«Яңарышка» мохтаҗлык.

Яз әле, яз миңа, сеңлем,
Менә шулар турында.
Ныгый барган каләмеңне
Манып иман нурына.

Җирле татар хәл-хисләрен
Йөрәк белән аңлыйсың,
Үзгәрешләр чоңгылының
Уртасында кайныйсың.

Көнләшәм дә синнән — кайчак
Кызганып та куямын:
Хатын-кызга бик авыр ла
Мәшәкате дөньяның.

Сабыеңа төнлә карап
Елауларың азмы соң?
Милләт белән бергә чыныгу —
Сеңлем, синең язмышың!

Кояшы да, ае да бар
Киң Себернең күгендә.
Инде менә иман балкый —
Күк өметләрәк күренә!

Өмет, өмет... Көннән-көн ул
Ымсындыра көчләрәк.
«Яңарыш» та, син үзең дә
Туган якка бик кирәк.

Яз миңа, яз әле, сеңлем!
Йөрәгемне айкаттыр!
Синнән килгән хатлар гына
Мине, йолкып, кайтарыр.

...Бәлки кирәгем дә юктыр
Газиз туган ягыма,
Синдәй, сеңлем, фидакарьләр
Анда булган чагында?

## «Яңарыш» гәзите

Син дә, мин дә — «ярты ясак»,
Төмән гәзите «Яңарыш».*
Чынлап күкрәргә, яшьнәргә
Дускаем, синең бара эш.

Көнләшеп, күрәм күп өйдә:
Балкыйсың өстәл-түрләрдә.
Миңа да чиш әле сереңне —
Ничек йөрәккә үтәргә.

Йөзең күренсә күзенә,
Кяференең чырае сытыла.
Чал урман, кояш, кызыгып,
Сине укырга сузыла.

Синең дә минем шикелле
Бик үзгә килеш-килбәтең.
Әмма син туган мәңгелек
Итәргә татар милләтен.

Сине мин әкияттәге
Сәмрух кош итеп күрәмен.
Иңеңә утырып урыйм бер
Борынгы татар җирләрен.

* *«Яңарыш»* — Төмәндә чыга торган газета.

## Киндерле инеше

Инеш ташса, таша инде —
Бер үзәнгә ул туймый.
Мине марта чаккан җирдә
Чуртан чөелмәк уйный.

Тора көндез зәңгәрләнеп,
Иртә-кичен алланып.
Әйтерсең лә зәңгәр күккә
Менә дигән ямаулык.

Киңлегенә «шап-шоп» төшеп,
Яшеннәр шуып китә.
Кагылганда көмешләнә
Җилләр үтәдән-үтә.

Табаннарын көйдергәндәй
Биеттерә яңгырны.
Шуны ишетеп, боргалана
Карындагы яралгы.

Печәнлектә, утынлыкта
Дулкыннар «мыек бора».
Авылдашлар, көлемсерәп,
Бераз ял итеп тора.

Шунда йога йөзләремә
Бер дә уңмас ягымлык.
Күңелләргә, киертереп,
Иңә серле яктылык.

Өем-өем ак болытта
Төтенләнә хозурлык.
Аны тойган якташларны
Тирбәндерә горурлык.

Менә шундый инештә мин
Йөзеп үстем, чыныктым.
Иң беренче аргы якка
Аның аша мин чыктым.

Кайтып хәзер кайгыларны
Айкый-чайкый батырам;
Күреп ташкан бәрәкәтне,
Хозурланам ярыннан.

...Әйе, карап ташуына
Әйтү авыр: — Бу — инеш.
Минем өчен һаман да ул —
Бер мизгеллек тәмле төш.

## И. Фатих

Син дә, Фатих, сизәсеңдер:
Ничек тиз үтә вакыт?!
Әле кайчан гына сазда
Без чөрәгәйләр аттык.

Чөрәгәйләр «пыр-пыр» оча,
Ядрә тими дә тими.
Маһинурың эчтән генә
Бездән көлгәндер инде.

Сиңа миндә ачу кайный
Аугa кыз алганыңа,
Яратышып булмыймыни
Безнең авылда гына.

Үзең киттең аргы күлгә
Кызыңны калдырдың да.
Баш очында очмый үрдәк —
Бакылдый анда-монда.

— Сөбханалла, нинди кич! — дип,
Кыз сүз башларга тели.
Нинди акылсызлык! — миңа
Комачаулавын белми.

Кинәт кызга ташланам да
Куе үләнгә егам.
— Үрдәкләрне куркытасың,
Селкенмә! — дип, кычкырам.

Шунда куак арасыннан
Елмаеп килеп чыктың.
Әремгә яуган яңгырдай
Йөрәге тибә кызның.

Сине күргәч, и куандым! —
Комачаудан коткардың.
Үрдәк атмый калам дип,
Качкандай китеп бардым.

Вакыт үтә-үтә лә бит
Чөрәгәй тизлегендә.
Саф, самими чакларыбыз
Хәтернең иң түрендә!

Их, кайтырга иде берчак
Яшьлекнең шул көненә!
— Кызың коч та шунда кал,— дип,
Сиңа әйтәсем килә.

# Еланны кысам да

Бу кышның бураны
Ни эзләп килгәндер:
Туздырды болынның
Ничәмә кибәнен.

Туң карда күрәмен
Туң елан йомгагын;
Чирканмый-нитмичә,
Куенга тыгамын.

Коткарыйм әле дип,
Йөгерәм авылга;
Кирәгер әле дип,
Дошманны чагарга.

Кешеләр янында
Күкрәгем кыймылдый.
Шаркылдап көләмен —
Елан бит кытыклый.

Көлүдән аумаска,
Дошманга тотындым.
Шунысы әкәмәт:
Бар үчне оныттым.

Бушанып көлгәнем
Юк иде күптәннән.
Байрактай болгатып
Еланны күтәрәм.

Әгәр дә агуы
Чәчелсә еланнан,
Куеныма кысам да
Туң җиргә капланам.

Ә тышта заманның
Бураны котыра.
Тели күк еланны
Куенымнан йолкырга.



# Эчтәлек

Җирсү. *Р.Әхмәтҗанов* . . . . . 5
Урманда . . . . . 12
Мөгездәге ярык . . . . . 13
Йөз яшьлек аучы . . . . . 14
«Бер урамда...» . . . . . 15
Ике халәт . . . . . 17
«Әти миңа...» . . . . . 18
Яшь карчыга . . . . . 21
Сазлык . . . . . 22
«Көзнең киеренке минутлары...» . . . . . 23
«Орынды да яфрак миңа...» . . . . . 24
«Авыру чебеш күк боегып...» . . . . . 25
«Ике ярдан...» . . . . . 26
«Әй, язмышым, кызып килә торгач...» . . . . . 27
Җиде торна . . . . . 28
«Ботаксыз наратны...» . . . . . 29
Болан көзе . . . . . 30
Март төне . . . . . 31
Аучы зары . . . . . 32
«— И Вәлиш, Вәлиш...» . . . . . 34
«Авылдашларым җылым тарта...» . . . . . 36
«Болан баскан эзләргә...» . . . . . 37
«Улы карт анасына хат язды...» . . . . . 38
«Еракта болынга мин...» . . . . . 39
«Кинәт кенә купты давыл...» . . . . . 40
Язның бер көне . . . . . 41
«Пышылдый Себердә...» . . . . . 42
«Элек тә бит, самолетлар очса...» . . . . . 43
Язгы көндә . . . . . 44
Тундра кызы җыры . . . . . 45
«Мин үстердем бер үрдәк...» . . . . . 46
«Мин сине сөям, дип...» . . . . . 47
Көзге төндә . . . . . 48
Күп сөйләнсәң . . . . . 49
«Сердәшләр булганга...» . . . . . 50
Күз буяу . . . . . 52
Балык шулпасы . . . . . 53
«Җилгә элгән ятьмәләрем...» . . . . . 54
Хәтер . . . . . 55

Аучы җыры . . . 56
Таңын ауда азан ишеттем . . . 62
«— Офыктагы әтәч...» . . . 63
«Яфрак бүген коела да коела...» . . . 64
«Язмышымның дәрьясы...» . . . 65
«Минем караш, кеше булсаң...» . . . 66
«Урман шәрә, җил туңдыра...» . . . 67
«Тук ялкаулык яшелләнеп...» . . . 68
«Көчәнеше өметнең...» . . . 69
«Бик зур шәһәр, төн уртасы...» . . . 70
«Сорап куйгалый иде...» . . . 71
Карурманда . . . 72
Рухыма . . . 75
Ачу чыкты . . . 76
Күршем . . . 77
«Күпме хата, гөнаһларым...» . . . 78
Яккан идем елан кабыгы . . . 79
Пошы аткач . . . 81
Ядрә тигән . . . 84
Яңа уй . . . 85
Ышык җирләрдә . . . 91
Балыкчы хатын . . . 94
Туң чуртан . . . 96
Язгы кар . . . 97
Йолдызга менимме? . . . 98
Сагая карт урман . . . 99
Белмим нигә . . . 100
Күл йөрәге . . . 101
Черкине сагынам . . . 103
Язның бер көне . . . 104
Хет үл . . . 105
Ашыкма . . . 107
Аккошларым . . . 108
Бәхет . . . 109
Беренче китабымдагы портретыма . . . 110
Аңлый төшәрсең . . . 111
Каен — яшел шар . . . 112
Кайт туган ягыңа . . . 114
Айда әрләннәр . . . 115
Беренче кар . . . 116
Черек каек . . . 119
Аллам ишетмәгән . . . 120

Нинди корттыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Себер татары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Исәнлегем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Саескан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Мәхәббәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Мин поши куалыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Кунакка кайткач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Әүхәт энемә хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Сыерчыклар яратмаган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Нарат һәм мин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Кояш качты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Йөзне кыйнатасы килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Телем тешләдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Ала карга сайрар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Ишкәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Кикрикүк тә кикрикүк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Нигә аттым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Басмада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Чытырдап ябыштым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Бал корты йөземдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Тозак кора идем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Моңым ага . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Ак болытка карыйм да . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Яшьтәшем Фатихка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Көнем — упкын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Картаюны тойгач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Нинди Төмән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Госман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Озын җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
«Сусарларны куып булмый...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
«Ишеттерәләр колагыма...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Язмыш шуа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Әле була яшәргә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Бөрлегән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
«Инешем, кайгы бар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
«Сазда ике селәүсен...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
«Җирдә йолдыз, күктә йолдыз...» . . . . . . . . . . . . . . . 176
Кайгыларым бар-барын... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
«Картаела...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
«Барып кайтып йөримен...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
«И табигать, бүген мин...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Урманнарга кабам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182

Бозны чукыма . . . . . 184
Капкан ята аргы кырда . . . . . 185
Туа ният . . . . . 186
Карчык зары . . . . . 187
Улыма . . . . . 189
Чәчәк иснәсәм . . . . . 190
«Көн кояшлы, җилсез булса...» . . . . . 191
Куркам җырларымнан . . . . . 192
Заман агачлары . . . . . 193
«Елганы елга йота...» . . . . . 194
Буйсын язның җиленә . . . . . 195
«Чак кына аңлый алсам мин...» . . . . . 196
Аю хәлендә калам . . . . . 197
Уян! . . . . . 198
Тагын улыма . . . . . 199
«Күл өстендә аккошкай...» . . . . . 200
«Сибелешеп чумды суга...» . . . . . 201
«Җырлый да белмим...» . . . . . 202
Пошы ите . . . . . 203
«Тигәнәккә бәрелеп...» . . . . . 205
Бер танышым зары . . . . . 206
Исерекбаш . . . . . 207
«Күндәм бер колы мин...» . . . . . 208
«Эт шикелел өрә беләм...» . . . . . 209
«Ерак качмый шатлык...» . . . . . 210
«Кайвакытта язмышым...» . . . . . 211
Кайсы чык авыр? . . . . . 212
Үрдәккә . . . . . 214
Кичен . . . . . 215
«Чыбылдык булып...» . . . . . 216
Сусар хәле көнләштерә . . . . . 218
Озак кайтмый кайткач . . . . . 219
«Тирә-ягым баткаклык...» . . . . . 220
Ят бию биегән . . . . . 221
Тансыкка ук аттым . . . . . 222
Яр буенда . . . . . 224
«Ничәнче көн күкнең йөзе...» . . . . . 225
«Уятмыйм улымны...» . . . . . 226
«Аллам рәхмәтеннән иңгән...» . . . . . 228
Им-томнар гына . . . . . 229
«Көзге төн, аяз төн нигәдер...» . . . . . 231
Юк инде, юк... . . . . . 232

Кайбер чакта төннәрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
Комсыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
Кемгә икәнен үзе белә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Мин бүген хан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
Шик . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 239
И бөҗәк! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Ишарә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
«Кырт» тешләп куя . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
«Актарамын урманнарны...» . . . . . . . . . . . . . . . 243
«Юк, төнлә урманда...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
«Кайный печән, кайный капкан...» . . . . . . . . . . . 245
Мине каргама . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
«Йокы керми күзләремә...» . . . . . . . . . . . . . . . 248
«Күзнең сизгер болытлары...» . . . . . . . . . . . . . 249
«Талгынлыкмы?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
Бөкре имән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
«Туңуданмы, куркуданмы дерелди...» . . . . . . . . . 252
«Язмышымның ярында...» . . . . . . . . . . . . . . . 253
«Төкрә кояш бу заманга...» . . . . . . . . . . . . . . 254
Авылдаш хатынга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 255
«Чыкты буран, гүя акбүз...» . . . . . . . . . . . . . . 256
«Мин ятканда аю үткән...» . . . . . . . . . . . . . . . 257
Чалдун теле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
«Алла бирсә бирер икән...» . . . . . . . . . . . . . . . 259
Талчитән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 260
Суган арчыганда уйлану . . . . . . . . . . . . . . . . 262
Ничек томан аша үтәргә? . . . . . . . . . . . . . . . 263
Кабан күленә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264
«Карагайга кара кантар...» . . . . . . . . . . . . . . 265
Тешне кысып куйгалыйм . . . . . . . . . . . . . . . . 267
«Әнә карга: «Кар, кар» — ди...» . . . . . . . . . . . 268
«Калып томан асларында...» . . . . . . . . . . . . . . 269
«Мылтыгыңны астың...» . . . . . . . . . . . . . . . . 270
«Яшь наратка ни булган?» . . . . . . . . . . . . . . . 271
«Үлән изеп ятуымны...» . . . . . . . . . . . . . . . . 272
«Давыл җуймый хәтәрлеген...» . . . . . . . . . . . . 273
Кабан буенда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
«Каурыйлары коелган кош...» . . . . . . . . . . . . . 275
Яртыясак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 276
«Кинәт кенә кубарылып...» . . . . . . . . . . . . . . . 278
Хәзинә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
Күңел ельй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281

Ни диим? . . . . 282
Ат . . . . 283
Йолдызлы төндә . . . . 284
Тимә . . . . 285
Кошы кайсы чорның син? . . . . 286
«Кар төшкәләп, йөз сыйпаштыргалый...» . . . . 287
Себергә Корбан бәйрәменә кайткач . . . . 288
«Сукмактагы кортны изсәң...» . . . . 289
Булмас бүтән уңай вакыт . . . . 290
Мин сүгендем . . . . 291
Төмәнне көрткә төрә . . . . 292
Якташым . . . . 293
Бармы ирләр? . . . . 294
Ханчабыр авылы . . . . 295
Минем җирләр . . . . 296
Кысырыклау . . . . 297
Ашыкма дан яуларга! . . . . 298
«Туры килде күпме саз...» . . . . 299
И, ана! . . . . 300
Кыш килә . . . . 301
«Күрәсеңме яфракларны...» . . . . 302
«Олау-олау яфрак ява...» . . . . 303
Көчәнеш . . . . 304
«Биектән һушлары киткәнме...» . . . . 305
«Моңлы, үкенечле торышы...» . . . . 306
«Көн начар», — диюегезне...» . . . . 307
Эч пошканда . . . . 308
«Менә монда болан ауган...» . . . . 309
«Төлке баскан капкынга...» . . . . 310
Өнеңдә күргәннәрең төшеңә керә . . . . 311
«Моңаю — күндәмләнү генә ул...» . . . . 312
Каен . . . . 313
Сандугач . . . . 314
Тынлык . . . . 315
Энеләремә . . . . 316
Җилле көндә . . . . 317
Күләгәдә интегәмен . . . . 319
Тәрәзәдән карыйм . . . . 320
Елан . . . . 321
Үр-гүр . . . . 322
Саклый күрсен . . . . 323
Газинур Моратка . . . . 324

Бер халык шагыйренә . . . . . 325
«Сузыла алдымда...» . . . . . 326
Син тагы... . . . . . 327
Авылдаш . . . . . 329
Көнләшәм каргадан . . . . . 330
Ике шаман ымлаша . . . . . 331
Сай елгада . . . . . 332
«Җилсез-нисез шаулый урман...» . . . . . 333
Наиләгә . . . . . 334
Акчарлак һәм мин . . . . . 335
Кемне син яраттың? . . . . . 336
Бер читтәрәк утырсын . . . . . 337
«Урманда куяннар туң каер кимерә...» . . . . . 338
«Кар төшә... Алда әле...» . . . . . 339
Мәҗүси зары . . . . . 340
«Үлән булып үсәрме...» . . . . . 342
Ташландык йортта . . . . . 343
Үзең җырлап бетер . . . . . 345
Йотма . . . . . 347
«Бу арада ай-яй кыен...» . . . . . 348
Корыган агач . . . . . 349
«Чыраемда...» . . . . . 350
Яз . . . . . 351
Поши үлеме . . . . . 352
Кайда көчек? . . . . . 353
Тартар . . . . . 355
«Аллага шөкер!.. Тагын җәй...» . . . . . 356
Айлы төндә ауда . . . . . 357
Янә ту икән . . . . . 359
Син һаман да юк . . . . . 361
Төмән кызы Сачилә . . . . . 362
Гаҗәп авыл . . . . . 363
Кемнән ул качты? . . . . . 365
Яз, сеңлем! Яз! . . . . . 368
«Яңарыш» гәзите . . . . . 370
Киндерле инеше . . . . . 371
И, Фатих . . . . . 373
Еланны кысам да . . . . . 375

Литературно-художественное издание

*Шаукат Гадельша*
*(Сибгатуллин Шаукат Гадельшович)*

# *Песня охотника*

Стихи
(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *М.Я.Разногорская*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *М.Ш.Хәйруллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 10.12.2003. Форматы 70×108 1/32.
«Lazurski» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 16,80 + форз. 0,18.
Шартлы буяу-оттиск 17,85. Нәшер-хисап табагы 11,05 + форз. 0,24.
Тиражы 2000. Заказ Я-793.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.